ӘЛ-ФАРАБИ атындағы ҚАЗАҚ ҰЛТТЫҚ УНИВЕРСИТЕТІ

**ТИМЕР ЗАҺИТ**

# ТУФАНИАДА

Алматы
«Қазақ университеті»
2019

УФҚ 32
ББҚ 66.0
Т 41

**Тимер Заһит**

Т 41 Туфаниада / Т. Заһит. – Алматы: Қазақ университеті, 2019 ел. – 374 бит.

**ISBN 978-601-06-5741-0**

2010 елда Туфан Миңнуллинның «Тормышым-булмышым» исемле китабы басылган иде. «Туфаниада» атаклы татар әдибенең фикерләренә җавап рәвешендә язылган. Монда Тимер Заһитның (Гриф Хайруллинның) дөньяга карашы, туган халкының язмышы, милләтара мөнәсәбәтләр, җәмгыять һәм гаилә проблемалары хакындагы уй-фикерләре тупланган.

Киң катлам укучылар игътибарына тәкъдим ителә.

**Автордың редакциясымен шығарылды.**

**УДК 32**
**ББҚ 66.0**

ISBN 978-601-06-5741-0

© Тимер Заһит, 2019
© Әл-Фараби атындағы ҚазҰУ, 2019

## МОГҖИЗА

Күптән түгел миңа Алматы шәһәрендә яшәүче танылган галим, җәмәгать эшлеклесе, милләттәшебез Гриф Хайруллинның «Туфаниада» дип исемләнгән кулъязмасы белән танышу мөмкинлеге туды. Бу кызыклы шигъри язмага үз фикеремне белдерим дип язу өстәле артына утыргач, башыма нигәдер «могҗиза» дигән сүз килде. Туктап калып, уйландым. Ни өчен «могҗиза»?

Туфан Миңнуллин 2010 елда үзенчәлекле китап чыгарды. Шулай туры килде - үзе исән чакта чыккан соңгы китап та булды ул. Нәрсәсе белән үзенчлекле дисәгез... Аның формасы да, эчтәлеге дә укучы өчен көтелмәгәнрәк. Танылган каләм остасы исеме белән чыккан китап ниндидер бер шаяру кебек кабул ителә. Бәлки, ул чыннан да шулайдыр? «Тормышым-булмышым» китабында язучының үзе уйлап чыгарган афоризмнар басылган 365 бит. Көндәлек кебек. Ләкин бу кайчак шаярулы, кайчак шактый җитди сүзләр Туфан Миңнуллинның куен кесәләренә аның иҗади тормыш юлы буе язылып тупланып килгән, ул аларны бары тик үзенә билгеле бер тәртип, мантыйк белән бер-берартлы тезгән. Ни өчен шулай икәнен инде үзеннән сорап та булмый. Башта шаяру кебек кенә кабул ителгән китап уйландыра, караган саен уйландыра, кабат кабат кулга алып укыйсы килә, башта игътибарсыз гына актарып үткән китап битләрендә хәйран китеп, озакка туктап каласың. Шунысы да бар, кереш сүзендә язучы укучыны бергәләп иҗат итәргә чакыра. Һәм Туфан Миңнуллин үзе дә моңа куаныр иде — аның бу мөрәҗәгате җавапсыз калмады. Бик күп һәм төрле-төрле кешеләрдән китапка кергән афоризмнарга «җавап» язганнары турында ишеткәнем бар.

Гриф Тимерзаһит улы Хайруллин, төпле фикерле кеше бу китапка аерым җитди игътибар биреп, һәр афоризмга үз мөнәсәбәтен белдергән шигъри юллар язган, моны могҗиза димичә, нәрсә дип атарга соң? Татарның бер аксакалы фикерләренә икенче бер аксакалыбыз үз уйлануларын өстәгән... «Афәрин!» — дип хуплыйсы килә.

Рәхмәт, Гриф Тимерзаһит улы!

***Әлфия Юнысова – Туфан Миңнуллин кызы***

# КЕРЕШ СҮЗ

*Хөрмәтле укучым!*

*Синең кулыңда минем тормышым, булмышым турында фәлсәфи уйлануларымның нәтиҗәсе. Син аны игътибар белән укы һәм үзеңчә бәялә: көләсең килсә-көл, ачулансаң-ачулан.Тик гаепләргә генә ашыкма: һәркемнең үзе турында үзенчә уйларга хакы бар.*

***Туфан Миңнуллин***

Туфан исән чакта һәрвакыт мин
Аңа «Сез» дияргә күнеккән.
Яшем өлкән хәзер.
«Син» дип дәшәм,
Рәнҗемәстер, дигән өметтән...

Кыйммәтле бер бүләк булып килгән
Синең китап өстәл өстендә.
Сурәттәге күз карашы белән
Гүя:
Укы әле, дисең дә,
Уйга чумасың син үзең дә.

Мин дә уйга чумам,
Баштан уза
Үземнең дә озын гомерем.
Алдан беркем белми үз язмышын,
Бу дөньяда ниләр күререн.

Гомер үзгач кына уйланасың,
Йөргән юллар туры булганмы?
...
Синең китап белән бергә тагын
Бер кат үтәм күргән, булганны.
Рәхмәт сиңа!

# БЕРЕНЧЕ КӨН

*Тууың белән мактанма,*
*бу процесста синең бер*
*катнашың да юк.*
***Туфан Миңнуллин***

Мин дә шигырь язган идем,
Ярый әле, туганмын, дип,
Бу дөньяда минем дә бит
Бер кирәгем булгандыр, дип.

Әйе, дөрес, катнашым юк,
Урын да юк мактанырлык.
Ләкин туу- бер могҗиза,
Зур бәхет бит шатланырлык!

# ИКЕНЧЕ КӨН

*Кеше-мәхәббәт орлыгының кибәге.*
***Туфан Миңнуллин***

Килешәлмим,
Ләкин гаепләмим,
Булалмыйм мин Сиңа хөкемдар.
Синең кебек бөек әдипләрне
Гаепләргә нинди хакым бар!?

Ләкин уем үзгә:
Бар кешене
Кибәк дип уйламыйм бүген дә.
Кешеләр дә, әлбәт, төрле була,
Ләкин кибәк кенә түгел лә!

Кибәгеннән юньле нәрсә чыкмас,
Юк-бар кибәк түгел Туфаннар!
Туфаннар да, нәкъ башкалар сыман
Олы мәхәббәттән туганнар.

# ӨЧЕНЧЕ КӨН

*Мәхәббәтнең ачы дошманы-уйлану.*
***Туфан Миңнуллин***

Сөйсәң, мәхәббәтнең көчен сизәрсең дә,
Сөйгәнеңне фәрештәгә тиңләрсең дә.

Ләкин бар як камил адәм булмас җирдә,
Андыйлар юк кергәндә дә кара гүргә.

Күп уйласаң сөйгәнеңнең төрле ягын,
Кимчелекләр табылыр ул тагын, тагын.
Күп уйланма,
Чүп-чар басар мәхәббәтнең назлы багын.

## ДҮРТЕНЧЕ КӨН

*Кайвакытта кешенең күләгәсе үзеннән куркынычрак була.*

***Туфан Миңнуллин***

Кешеләрнең күләгәсе
Үзләренә охшап тора.
Яхшы көндә күләгәдән
Булмый һичбер бушап кына.

Кайберәүнең күләгәсе
Ни өчендер аерыла,
Кем икәнен белмәсәң дә,
Күләгәсе кара була.
Күңеле кара микәнни?

## БИШЕНЧЕ КӨН

*Синнән курыккан кеше синең дусың булалмый.*
***Туфан Миңнуллин***

Кешеләр дә, дәүләтләр дә, милләтләр дә
Тугры дуслар эзли үзләренә.
Куркытылган, бастырылган җан һичкайчан
Дус булалмый.
Ышаныч юк сүзләренә,
Ант итсә дә туры карап күзләреңә.

Кол милләт тә сиңа тугры дус булалмас,
Азатлык дип хыялланып түзәр генә.
Хак Тәгалә куәт бирсен түзәренә,
Юл күрсәтсен богауларын өзәренә.

## АЛТЫНЧЫ КӨН

*Көчле кешегә егылырга ярамый-*
*көчсезләр таптап үтерәчәк.*

***Туфан Миңнуллин***

Кем булсаң да, егылмаска тырыш,
Егылганны таптап китәрләр.
Көчлесе дә, көчсезе дә таптар.
Ыңгырашуың да бикәргә.

Гомер-газиз,
Егылсаң да, торып,
Аяк өсте кирәк үтәргә.
Торалмасаң, харап итәрләр,
Шулай башыңа да җитәрләр.

# ҖИДЕНЧЕ КӨН

*Мескеннәргә, җылакларга сәдака гына бирәләр.*
***Туфан Миңнуллин***

Мескенләнеп, яшьләр түгеп йөрсәң,
Бөтен бәяң булыр биш тиен.
Биш тиенлек шул сәдака белән
Рәтләнәме синең бар көең?

Бар максатың, хыялларың синең
Шул гынамы якты дөньяда?...
Олы шәхес горурлыгы белән
Яшәп кара бераз булса да.
Мескен, җылак булып яшәмәсен
Кеше,
Мескен булып туса да.

# СИГЕЗЕНЧЕ КӨН

*Без кыйнаганга түзәбез,*
*мактаганга юк.*
***Туфан Миңнуллин***

Күтәрәбез тукмаганны, орган-сукканны,
Каешын да, камчысын да, таяк, чукмарны.
Мактау гына чыгарадыр безне чыгырдан,
Башлар күккә тия мәгәр шыгырдап.

Белми бәндә башынниләр көтәрен,
Күктән җиргә тәгәрәпләр төшәрен.
Күп макталып, бик масайма күкләрдә,
Имгәнерсең егылып түбән төшкәндә.

# ТУГЫЗЫНЧЫ КӨН

*Үзе буйсына белгән кеше генә*
*бүтәннәрне буйсындыра ала.*
***Туфан Миңнуллин***

Буйсынуларын теләсәң,
Син буйсынырга өйрән,
Карышмыйча буйсынырга,
Нинди булса да түрәң.

Буйсынуның төп асылын
Аңлагач кына үзең,
Бүтәннәр дә буйсынырлык,
Үтемле булыр сүзең.

## УНЫНЧЫ КӨН

*Килгәнеңне күрмәсәләр,*
*киткәнеңне сизмәсләр.*
***Туфан Миңнуллин***

Сәлам бирү фарыз, диләр,
Килгәч, сәламләшә бел.
Киткән чакта рәхмәтеңне
Әйтеп,
Саубуллаша бел.

Шунда сине күрерләр дә,
Шунда сине сизәрләр.
Үзебезнең татарыбыз,
Әдәпле бит, диярләр.

## УНБЕРЕНЧЕ КӨН

*Итне тешле кеше генә ашый ала.*
***Туфан Миңнуллин***

Ит ашасаң тешкә керә,
Ашамасаң-төшкә керә.
Тешле кеше ашый итне,
Сөякне дә теш кимерә.

Тешсезләр ит ашый алмас,
Гүя аңа кирәкми дә.
Кирәктер дә тәм татырга,
Аңа бит ит эләкми дә.

Тешле булып яшә, кеше,
Тешсезләргә юл да бирмәс
Тешле халык.
Тешсез булсаң,
Үз өлешең сиңа тимәс.

## УНИКЕНЧЕ КӨН

*Татар булу өчен*
*Гаптери булу гына җитми.*
***Туфан Миңнуллин***

Гаптери ни, Мокамай ни-
Бу гына җитми икән.
Татар булу мәсьәләсе
Чынлап та җитди икән.

Әлмәндәрдәй бар дөньяны
Сөя белергә кирәк;
Халкың язмышы өчен дә
Көя белергә кирәк.

# УНӨЧЕНЧЕ КӨН

*Татарлар бөтен эшне җиренә*
*җиткереп эшлиләр.*
*Өйләнә һәм кияүгә чыга гына белмиләр.*
***Туфан Миңнуллин***

Татар егетләре, кызлары да
Чит милләткә бик еш пар була.
Үзләренә лаек татар тапмый,
Сөеп, башкаларга яр була.

Бүтән милләт кызы белән төзи
Гаиләсен татар уллары.
Башка милләт егетләре белән
Оя кора татар кызлары.

Уртак җимешләре татар түгел,
Инде башка милләт баласы.
Үз халкыңнан пар да табалмагач,
И татарым, кая барасың?

Күпме гасыр киң күңелле татар
Чит милләтнең канын яңарта.
Җирдә татарлар да яшәсенче,-
Дигән фикер юкмы татарда?!

# УНДҮРТЕНЧЕ КӨН

*Дөньяда юк нәрсә- хатын-кызның*
*«мин гаепле» дигәне.*

***Туфан Миңнуллин***

Юк, хатын-кыз «мин гаепле» димәс,
Андый сүзләр аңа туры килмәс.
Ни, дип, ул үз-үзен гаепләсен,
Ир-ат бар ләбаса гаеп өчен.

Ир буламын, дисәң, чыда инде,
Язмышың да менә шунда инде.
Өйрән баш ияргә хатыныңа,
Бер гаепсез җан- шул хатын гына.

# УНБИШЕНЧЕ КӨН

*Өйләнгәнче үзеңнең*
*ахмак икәнлегеңне белмисең.*
***Туфан Миңнуллин***

Егет чакта бөтенесе ачык,
Акыл барлыгын да беләсең.
Дөнья мәшәкате башка төшкәч,
Акыл саегадыр, күрәсең.

Элеккеге яшь кыз түгел хатын
(Сизелә шул еллар үткәне),
Сирәк-мирәк ул да искә ала
Акыл ягың бик сай икәнен.

## УНАЛТЫНЧЫ КӨН

*Сәдака оҗмахка арткы ишектән*
*керү өчен ришвәт түгел.*
***Туфан Миңнуллин***

Оҗмахларга керим дисәң, мөселманның
Биш фарызын даим үтәп яшәү кирәк.
Сәдакасын таратырга ашыгадыр
Җайбер гөнаһ ияләре тизрәк-тизрәк.

Шуның өчен генә Ходай ярлыкамас
Гөнаһларың.
Шуны аңлаучылар сирәк.
Оҗмахка да керер ишек бирәү генә,
Ришвәт өчен керәлмәссең, белсәң кирәк.

## УНҖИДЕНЧЕ КӨН

*Халыкка хезмәт итәргә кирәк дигән сүздә алдашу бар. Кешегә ярдәм итәргә кирәк.*

***Туфан Миңнуллин***

Туфан менә бик атаклы әдип иде,
Туган халкына күп хезмәт иткән кеше.
Ярдәм итүдән дә һич баш тартмый иде,
Ярдәмчелләр сирәк булыр аның ише.
Ярдәм белән хезмәтне шул кушкан кеше.

Андыйлар да була икән арабызда,
Шуңа өйрәнергә кирәк барыбызга.
Халкыңа да хезмәт итә белү кирәк,
Кешегә дә синнән ярдәм булсын, димәк.

# УНСИГЕЗЕНЧЕ КӨН

*Пыялага тигәнәк ябышмый.*
***Туфан Миңнуллин***

Үтәли күренә торган булсаң
Ачык, тигез генә пыяладай,
Тигәнәк күк һичкем ябышалмый,
Үрмәкүч тә сиңа ояламый.

Артык шома булуың да яман,
Беркем булмас сиңа ябышканы.
Чын дусларың, якыннарың булмас,
Читтә калыр хәтта танышларың.

## УНТУГЫЗЫНЧЫ КӨН

*Мие сыекның йөрәге каты.*
***Туфан Миңнуллин***

Кайберәүләрнең йөрәге
Нәрсәдән ката икән?
Әллә инде күңелендә
Бер хәсрәт ята микән?

Әллә мие сыек микән,
Шуңамы йөрәк каты?
Җавапларын табалмыйча
Күп утырдым шаккатып.

Катылыкның сәбәпләре
Бер төрле булмас инде.
Бар да гади генә булса,
Туфан уйланмас иде.

## ЕГЕРМЕНЧЕ КӨН

*Сөяркә-хобби, хатын-вазифа.*
***Туфан Миңнуллин***

Хобби үзгә, вазифа да үзгә,
Бергә кушалмыйм мин, бичара.
Хатын риза хобби булырына,
Ә сөяркә каршы, ни чара?

Ташларга да жәлке читләргә,
Бер хоббисыз үзем нишләргә...
Хатын булыр иде сөяркә,
Ничек сөяркәдәй сөяргә?

# ЕГЕРМЕ БЕРЕНЧЕ КӨН

*Дөньяда иң чибәр хатын-бала*
*җитәкләгән хатын.*
***Туфан Миңнуллин***

Сокланып та туялмассың мәгәр
Бала җитәкләгән хатынга.
Сипкән нуры — көмеш кенә түгел,
Алыштырмаслык бар алтынга.

Үз хатының, синең балаң белән,
Җитәкләшеп барса урамнан,
Шул чагында бөтен тирә-ягың
Бәхет нурларына уралган.
Зуррак бәхет юктыр, и Аллам!

# ЕГЕРМЕ ИКЕНЧЕ КӨН

*Бәхетсезлеккә чират тормыйлар.*
***Туфан Миңнуллин***

Чиратны да көтеп тормый бит ул,
Үзе килә, каһәр төшкере!
Үз колагың белән ишетмәсәң,
Беленә шул бик тиз, күз күреп.

Күрмәсәң дә, башка бер юл белән
Аңлата ул сиңа килгәнен.
Килеп баса, бигрәк ярата бит,
Шуңа башың түбән игәнең.

Тик иелсәң, тагын ныграк баса,
Бирешмә син, аңа баш имә!
Мәңгелеккә килмәгән ул, көрәш.
Нык бул, мин бәхетсез баш, димә.

## ЕГЕРМЕ ӨЧЕНЧЕ КӨН

*Җыларга да ике күз,*
*көләргә дә ике күз.*
***Туфан Миңнуллин***

Шул ике күз ике төрле шөгыльгә дә ярый икән,
Икәүләр бик дус булса да, ике якка карый икән.

Бөтенесе синнән тора-кайсы якка каратырга,
Көлдерергә телисеңме, әллә инде җылатырга.

Дөнья булгач, төрле чак бар, ике як та кирәк була,
Уйлап кара, белеп кара, шундый кеше зирәк була.

## ЕГЕРМЕ ДҮРТЕНЧЕ КӨН

*Язарга утырганда ике куркыныч нәрсә сагалап тора: берсе-үз көчеңә ышанмау, икенчесе- кирәгеннән артык ышану.*

***Туфан Миңнуллин***

Ике шул куркыныч сине
Сагалап тора,
Эшләреңне башлатмаска
Планнар кора.

Карап торма бусына да,
Тегесенә дә.
Бисмилла, дип, кереш тизрәк
Бу эшеңә дә.

Атлаганнар алга бара,
Туктаган- кала.
Эш башламый, туктап торсаң,
Сиңа ни кала?

# ЕГЕРМЕ БИШЕНЧЕ КӨН

*Пьесаны язып бетергәч кенә*
*ничек язарга кирәклеген төшенәсең.*
***Туфан Миңнуллин***

Диләфрүз дә, Миләүшә дә
Ярдәм итмәгән икән,
Гөргөри кияүләренең
Хәле җитмәгән икән.

Синең сүзләргә ияреп,
Мин бу эшне башладым.
Төшенсәм, төшенмәсәм дә,
Башлаганны ташламыйм.

Иң ахырда төшенәлсәм,
Бик шәп булыр иде ул.
Шул чакта да төшенмәсәм,
Гаеп миндә инде ул.

# ЕГЕРМЕ АЛТЫНЧЫ КӨН

*Минем адашасым килсә,*
*юл күрсәтмәгез.*
***Туфан Миңнуллин***

Җаны теләгән- елан ашаган,-
Дигән элек безнең бабайлар.
Һәркемнең дә җирдә үз юлы бар,
Ни кирәген үзе абайлар.

Адашасы килсә, адашсын,
Үзе атлап китсен юл башын.
Кыек-мыек китсә юллары,
Гаеп тик үзендә нибары.

# ЕГЕРМЕ ҖИДЕНЧЕ КӨН

*Хыял дөньясында яшәү-*
*ялкау кеше шөгыле.*
***Туфан Миңнуллин***

Хыял диңгезенә чумасың да,
Колачларың җәеп йөзәсең.
Хыял дөньясында гомер юлын
Тагын бер кат үтеп, гизәсең.

Ләззәт инде.
Ләкин бар гомерне
Хыял дөньясына күмәлмәм.
Ул дөньяда берни эшләмим бит,
Эш бәхетен анда күрәлмәм.

# ЕГЕРМЕ СИГЕЗЕНЧЕ КӨН

*Ходайның кешегә биргән*
*иң зур бүләге- уйлау ирке.*
***Туфан Миңнуллин***

Җанлыларның да иң бәхетлесе-
Адәми зат, бүләк иясе.
Ходай биргән аңа уйлау ирке-
Үзенчәлек, хосусияте.

Шул бүләкнең бәя, кыйммәтлеген
Адәми зат аңлап җитәме?
Әллә уйлау иркен, сәләтләрен
Юкка-барга сарыф итәме?

# ЕГЕРМЕ ТУГЫЗЫНЧЫ КӨН

*Кешенең кеше булуы-ояла белүендә.*
***Туфан Миңнуллин***

Кызара да, ояла да белмәгәннәр
Кеше исемен күтәреп йөрмәсеннәр.

Хәтта хайваннар да белә оялуны.
Бәндә өчен хайваннан да ким булудыр,
Белмәсә ул үзе өчен оялуны.

## УТЫЗЫНЧЫ КӨН

*Бер кәкрәйгән кадак,*
*турайтсаң да, кәкрәя.*
***Туфан Миңнуллин***

Кәкрәймә син, әгәр җанлы кеше булсаң,
Кәкрәергә ни хакың бар, милләт булсаң.

Бер кәкрәйгән тулысынча турыланмас,
Мондый милләтләргә җирдә урын калмас.

Кәкрәймә дә, бөкерәймә, алга кара,
Шундый милләт кенә үсә алга таба.

## УТЫЗ БЕРЕНЧЕ КӨН

*Бүгенге көндә намуслы булып калу*
*зур батырлык ул.*
***Туфан Миңнуллин***

Баш иябез сугыш батырына,
Ихтирамлы хезмәт батыры.
Шуларга тиң батырлык бит бүген,
Намусыңа булсаң син тугры.

Намуслы бер бәндә булыйм дисәң,
Күпме киртә, каһәр суккыры!
Киртәләрне үтеп, алга омтыл,
Намусыңа һәрчак бул тугры!

# УТЫЗ ИКЕНЧЕ КӨН

*Адәм баласы үзе уйлап тапкан хикмәтнең*
*шунда ук колына әйләнә.*

***Туфан Миңнуллин***

Күкәй салган тавык сыман кет-кет итә
Кайберәүләр,
Кечкенә бер эше бетсә.
Шуның белән көне үтә, төне үтә.
Туктар иде, әгәр акыллары җитсә.

Туктатып та булмый аны, туктамый да,
Көлке хәлгә калганын ул аңламый да.

# УТЫЗ ӨЧЕНЧЕ КӨН

*Һәрбер гамәл эшләнеп беткәч кенә эш була.*

***Туфан Миңнуллин***

Бетермәстәй булсаң, эшне
Башлама да.
Бер башласаң, ярты юлда
Ташлама да.

Юк мактаныр урын, тәүге
Адым йөреп.
Эшең бетә, борылгачтын
Соңгы шөреп.

## УТЫЗ ДҮРТЕНЧЕ КӨН

*Ярый әле бүксә пыяла түгел-*
*ни ашаганың күренми.*
***Туфан Миңнуллин***

Ярый әле, бүксә пыяладан түгел,
Оялмыйча чыгалам бит урамга.
Минем күпме, нәрсә тыгынганымны да
Һичкем белми хәтта янда торганда.

Нишләр идең, әгәр пыяладан булса,
Бөтен кеше «хәзинәңә» карап торса.

## УТЫЗ БИШЕНЧЕ КӨН

*Пеләш башта бет булмый.*
***Туфан Миңнуллин***

Булмас иде минем башым тап-такыр,
Әгәр аннан бөтен чәчем качмаса.
Башны кашырга да юк бит сәбәбе,
Берәр бет тә йөрми шунда, ичмасам.

Качар урын да табалмас бичара,
Нишләсен, ни ултара, ни пултара.

## УТЫЗ АЛТЫНЧЫ КӨН

*Кызлар теле-бәлеш төбе.*
***Туфан Миңнуллин***

Яшь кызларның нинди тәмле телләре,
Гел елмаеп тора алсу йөзләре,
Ялтыр-йолтыр яшь кызларның күзләре,
Йотып кына куярлык бит үзләре.

Хәзер алар керә төшләргә генә.
Эх, яшь кызлар!
Белмим нишләргә генә.

# УТЫЗ ҖИДЕНЧЕ КӨН

*Төбәлеп карама,кытыгымны китерәсең.*
***Туфан Миңнуллин***

Ник елмаеп карыйсың,
Әллә мине таныйсың?
Яшьлек хисен уятасың,
Җилә сиңа ярыйсым.

Әй чибәр кыз, алай миңа
Бик елмаеп карама.
Син елмаеп караганда
Зиһеннәрем тарала.

# УТЫЗ СИГЕЗЕНЧЕ КӨН

*Авылыңа сыерчыклар килсен дисәң,*
*башта сыерчык оялары ясарга кирәк.*
***Туфан Миңнуллин***

Яхшы тормыш кирәк, дигән кеше
Кул кушырып, көтеп утырмас.
Җиң сызганып, тирләр түгеп эшләр.
Яхшы тормыш килер, көттермәс.

Иркен тормыш белән ихатада
Сыерчыкка оя табылыр.
Сандугачлар синең бакчаларда
Сайрый-сайрый канат кагыныр.

# УТЫЗ ТУГЫЗЫНЧЫ КӨН

*Акыллылар ахмак кубызына*
*биегән илдә буза куба.*
***Туфан Миңнуллин***

Ыгы-зыгы туды әллә каян,
Тилергәндер дөнья, тилергән.
Баксаң, акыллылар төшкән икән
Ахмак кубызына биергә.

Биеп торгач ахмак кубызына,
Шуларда бит туксан тугыз гына,
Йөзгә берәү җитмәс акыл ягы.
Шуннан көчәя бит буза тагын.

# ҚЫРЫГЫНЧЫ КӨН

*Серен ачкан мизгелдән*
*хатын-кызның кызыгы бетә.*
***Туфан Миңнуллин***

Қызыгың да китте синең, хатын,
Нигә ачтың миңа сереңне?
Миндә дә юк серләр, синдә дә юк,
Нинди хәлгә куйдың иреңне?

Син ничек тә серле булып кара,
Сер-мазарлар тырыш табарга.
Хыянәт тә серле.
Әллә барасыңмы
Сөяркәләр эзләп базарга?

# КЫРЫК БЕРЕНЧЕ КӨН

*Хатын-кыз бөек зат, почти ирләр кебек.*
***Туфан Миңнуллин***

Ир-ат бөек, почти хатын-кыздай,
Бала таба гына белми ул.
Менә шуны бер өйрәнеп алса,
Хатын-кызга юл да бирми ул.

Пока хатын белән ир, -дибез,-
Бөтен яктан равный, бер тигез.

# КЫРЫК ИКЕНЧЕ КӨН

*Ярату турында акыл сатмыйча гына яратышу татлырак.*

***Туфан Миңнуллин***

Хатын-кызлар колак белән ярата, дип
Әйтүләре дөрестер ул, ялган түгел.
Ә шулай да аларны да ялкытыр бит
Тукып торсаң яратам, дип көнең-төнең.

«Яратам»ның тәме качар, төсе китәр,
Адым саен һаман шуны кабатласаң.
Ышанмый да башлар синең сүзләреңә,
Әгәр шул сүз белән аны ялыктырсаң.

# ҚЫРЫК ӨЧЕНЧЕ КӨН

*Бәхет өчен бәхетле була белү шарт.*
***Туфан Миңнуллин***

Нигә кирәк сиңа олы бәхет,
Бәхетле дә була белмәгәч.
Нигә кирәк сиңа озын гомер,
Кыскасына да син түзмәгәч,
Аның кадерен дә белмәгәч.

Гомер сөрү- үзе зур бәхет,
Яшә җирне бизәп, бизәтеп.
Шул бәхетне аңлый белү шарт,
Бик кадерләп саклый белү шарт.

# КЫРЫК ДҮРТЕНЧЕ КӨН

*Кәлтәгә пәлтә кирәкми.*
***Туфан Миңнуллин***

Кәлтәгә пәлтә кирәкми,
Кәҗәгә- баян,
Тик кешегә бар да кирәк,
Бу мода каян?

Кәлтәдән дә, кәҗәдән дә
Хуже булгансың,
Бер ярдәмсез торалмаслык
Булып тугансың.

Мактаныр җирең юк инде,
Син көчсез, мескен.
Бөтен гайрәт табигатьтә,
Аңларсың беркөн.

## ҚЫРЫҚ БИШЕНЧЕ КӨН

*Иң бәхетсез кар-*
*шәһәр өстенә яуган кар.*
***Туфан Миңнуллин***

Карның да бит бәхетлесе ява
Саф һавада, чиста җиргә.
Ә бәхетле бала туа, диләр,
Шат гаилә, тыныч илдә.

Карлар яусын таза җиргә гелән,
Сабый тусын бәхетләре белән.

## КЫРЫК АЛТЫНЧЫ КӨН

*Алабута аш булса,*
*әтрәк әләм баш була.*
***Туфан Миңнуллин***

Эшләр чатак,
Әгәр әтрәк әләм
Илләреңдә баш булса.
Алабута булыр идемени
Ашың,
Башлыгыңда баш булса.

Илдә күпме башлык- әтрәк әләм,
Шулар тулган бөтен дөнья, галәм.

# КЫРЫК ҖИДЕНЧЕ КӨН

*Кәҗәнең җыры кәбестә турында.*
***Туфан Миңнуллин***

Һәркемнең дә үз моңы бар, үз җыры да,
Һәркемнең бар ни хактадыр үз зары да.

Карганың тик «кар-кар» була бар җырласы,
Ә кәҗәнең кәбестәдер җыр темасы.

# ҠЫРЫҠ СИГЕЗЕНЧЕ КӨН

*Яшь кешегә яшь күренәсең дип әйтмиләр.*
***Туфан Миңнуллин***

Яшь чагымда бер кеше дә
Яшьсең, диеп әйтмәде.
Олыгайгач:
Яшь күрендең,-
Байтак шулай әйткәне.

Чынлыгында яшь күренмим,
Алар юри әйтәләр.
Ҡартлыгымны үзем беләм,
Ярый, әйтсен, әйтсәләр.

## КЫРЫК ТУГЫЗЫНЧЫ КӨН

*Тиз йөгерүең белән бик мактанма.*
*Бәлки син кемнедер узарга теләп түгел,*
*ә кемнәндер куркып чабасыңдыр.*

***Туфан Миңнуллин***

Белмим кайдан, кая, нигә чабасыңдыр,
Бу чабудан нинди ләззәт табасыңдыр.
Ашыкмале, монда туктап хәл ал әле,
Бәлки шулдыр гомернең иң күркәм мәле.

Бераз гына хәл алгачтын тагын йөгер;
Тик тормасаң, сизелми дә үтә гомер.
Вакыт җиткәч, башкаеңа килер уең:
Нигә чаптым икән, диеп, гомер буе?

# ИЛЛЕНЧЕ КӨН

*Телсезләр арасында сакауның сөйләшүе дә матур.*
***Туфан Миңнуллин***

Дөм сукырлар арасында
Ярым сукыр- юлбашчы,
Чукрак- юлдаш сиңа,
Юлың
Тавыш-тынсыз булганчы.

Телсезләргә тел остасы
Булып йөрер бер сакау,
Эштән качып йөрүчегә
Үрнәк булыр бер ялкау.

Сакау, ялкау, сукыр, чукрак
Әйди, ахры, безне туплап.

# ИЛЛЕ БЕРЕНЧЕ КӨН

*Салпы ягыма печән кыстыр,*
*саламга гына мин риза түгел.*
***Туфан Миңнуллин***

Өметләнү читен,Туфан,
Печән кыстырырлар дип,
Татарлар үз әдипләрен
Күккә очырырлар дип.

Урам тулы хәйләкәрләр,
Дөньясы да мут инде.
Кыстырырга печән түгел,
Саламы да юк инде.

## ИЛЛЕ ИКЕНЧЕ КӨН

*Хакимият аз биреп күп алыр өчен яратылган.*
***Туфан Миңнуллин***

Хакимият баскыч-баскыч, басма-басма,
Алу дисәң, хакимнәре бигрәк зирәк.
Күпләр үзе, һәр кешегә бер хакимдер,
Халык өчен эшләүчеләр генә сирәк.

Мыскаллыйлар сиңа тиеш бирәчәген,
Кумәртәләп - хакимнәргә керәчәге.

# ИЛЛЕ ӨЧЕНЧЕ КӨН

*Кешеләрдәге уртак сыйфат: министр итсәң,*
*үзен президент дип уйлый, президент итсәң,*
*Аллалыкка дәгъва кыла.*
***Туфан Миңнуллин***

Татар, диләр, түрә булса,
Чабатасын түргә элә.
Мин-мин микән, мин кем икән,
Дип масая гына белә.

Үзен бик югары куеп,
Күркә кебек кабарына.
Эзли кайдан, нәрсә табып
Авызына кабарына.

Хыялы бер- югарырак
Менәргә соң ничек кенә.
Гомер буе ятар иде
Бушка ашап, эчеп кенә.

Алла дип хис итә үзен
Гади халык күргән чакта...
Я Ходаем, шундыйлардан
Татарыңны үзең сакла!

## ИЛЛЕ ДҮРТЕНЧЕ КӨН

*Әгәр дә синнән көнләшмиләр икән,*
*димәк, синең потың бер тиен.*
***Туфан Миңнуллин***

Көнләшсеннәр әйдә, көнләшсеннәр,
Көнләшерлек сәбәп табылсын.
Шундый бер сәбәп тә табылмаса,
Сине җирдә кемнәр таныр соң?

Танымаслар сине, белмәсләр,
Кылгән- киткәнеңне сизмәсләр.

# ИЛЛЕ БИШЕНЧЕ КӨН

*Һәрбер көчек эт булырга,*
*һәрбер серкә бет булырга хыяллана.*
***Туфан Миңнуллин***

Һәрбер җанга нәсел якын,
Нигә хыялланмаска?
Җан иясе нәселенә
Килә аерылмаска.

Шуңа күрә эттән эт туа,
Ни әйтсәң дә, беттән бет туа.

# ИЛЛЕ АЛТЫНЧЫ КӨН

*Бәхетеңнән куркып яшәү-яшәүмени?*
***Туфан Миңнуллин***

Бәхетеңне юлга чыгарып куй,
Күрсен халык, бергә шатлансын.
Бәхетеннән куркып яшәүчеләр,
Качып-посып кына йөрүчеләр
Көнләшсен дә синнән, шаккатсын.

Бәхетеңнән качма беркайчан да,
Югалуы мөмкин син качканда.

## ИЛЛЕ ҖИДЕНЧЕ КӨН

*Үз күләгәсеннән башка*
*якын дусты юк аның.*
***Туфан Миңнуллин***

И син мескен бәндә, и бичара,
Иң якын дустың да кап-кара.
Дуслар иңен дә син күрмисең,
Дуслык җылысын да сизмисең.

Бәхетне дә, мескен, белмисең,
Кирәкме шул гомер,
Ни дисең?

# ИЛЛЕ СИГЕЗЕНЧЕ КӨН

*Исән шагыйрьгә караганда үтерелгән шагыйрь куркынычрак.*

***Туфан Миңнуллин***

Исәннәрнең белми кадерен,
Үлгәннәрнең белми каберен,
Шундый заман килде каршыга.
Җайберәүләр җирне тарсына,
Тартып алыр иде барысын да.

Тере шагыйрь, бәлки, баш ияр,
Үлгәннәр - үз сүзен хак дияр!

# ИЛЛЕ ТУГЫЗЫНЧЫ КӨН

*Кайбер язучының иҗаты*
*маймылы качкан*
*зоопаркны хәтерләтә.*
***Туфан Миңнуллин***

Бөекләр һәм даһилар күп түгел җирдә,
Кешелекнең күп даһие инде гүрдә.

Якты дөнья кешеләре хезмәт итә
Үз халкына
Күпме көч-сәләте җитә.

Арасында даһие бар, бөеге бар,
Бик яхшысы да, җан көеге бар.

Язучы да Ходай түгел, кеше генә,
Кайберләре терәлгәндер көрчегенә.

# АЛТМЫШЫНЧЫ КӨН

*Тилеләрдән башта көләләр,*
*аннары сагынып сөйлиләр.*
***Туфан Миңнуллин***

Тиле булып күзгә күренсә дә,
Син ашыкма көлеп калырга.
Соңрак, бәлки, туры килер аны
Бик сагынып искә алырга.

Тиле диеп мыскыллама беркемне дә,
Бәлки менә шул тилелек сөйкемле дә.

## АЛТМЫШ БЕРЕНЧЕ КӨН

*Безнең гомер-мең томлык тарих китабы битендәге черки эзе.*

***Туфан Миңнуллин***

И гомерем, бигрәк кыска булдың,
Сизмәдем дә, үтте-китте бит.
Таңнар аткач, торып чыккан идем,
Кичен китәр вакыт җитте бит.

Тарих белән сине чагыштырмыйм,
Тарих бөек, гомер- бер бөртек.
Шул бөртекне сакламадык һаман,
Алда әллә ниләр көтәр сыман
Тагын омтылдык, гел йөгердек.

# АЛТМЫШ ИКЕНЧЕ КӨН

*Вәт замана: әнисе урысча белми,*
*баласы татарча белми.*
***Туфан Миңнуллин***

Күз яшьләрем аша карыйм да мин
Язмышына туган телемнең,
Җаның чыдамаслык хәсрәт баса,
Тетрәтә бар кылын күңелнең.

Туган телем саклыйм, дигән уйлар
Килмимени, татар, башыңа,
Синнән башка аны кем сакласын?
Ана телем өчен ачынам.
Үлем түшәгендә яткан хәлгә
Килгән телем өчен ачынам.

Татар теле ерак нәселемә
Барып җитсен, диеп, борчылам.
Мөкатдәс шул телем яшәсен, дип,
Тезләнепләр кылам баш догам.
Анам телен сакла, и Ходам!

Ана телен белми баласы.
Эй, татарин! Куда барасың?!

## АЛТМЫШ ӨЧЕНЧЕ КӨН

*Татарның җыры, язмышы шикелле,*
*сагышлы һәм моңлы.*
***Туфан Миңнуллин***

Нинди генә татар сөйми икән
Үзәк өзгеч милли моңнарны?
Татар моңы кебек йөрәкләргә
Тирән эзләр салган моң бармы?

Хәсрәтләрен, тирән сагышларын
Татар моңнар аша белдергән.
Моңнар белән юаткан да үзен,
Авырлыгын баштан кичергән.

Шул моңнарда явыз гасырларның
Афәтләре тора чагылып.
Шунда язмышлары,
Үткән гомер
Ятлар орып-сугып, кагылып.

# АЛТМЫШ ДҮРТЕНЧЕ КӨН

*Тел тик тормаганга колакны боралар.*
***Туфан Миңнуллин***

Тартай теленнән таба, дип
Юкка әйтмәгән халык.
Телеңне тыя белмәсәң,
Ясарлар синнән балык,
Йөзәрсең телсез калып.

Колак борган гына түзәрлек,
Телне кисүләре үләрлек!

## АЛТМЫШ БИШЕНЧЕ КӨН

*Кайбер кешеләрнең вөҗданын*
*кычкырып кына уятып була.*
***Туфан Миңнуллин***

Вөҗданнары каты йоклап, уянмаган кеше була,
Бер карасаң, мәрткә киткән бәндәләрнең эше була.

Вөҗданнары уяналмый йомшак әйткән сүзләр белән,
Уяныр, акырсаң гына үтә ачы телләр белән.

# АЛТМЫШ АЛТЫНЧЫ КӨН

*Кайдадыр күргән дә кебек,*
*күрәсем дә килмәгән кебек.*
***Туфан Миңнуллин***

Теге бәндә никтер миңа таныш сыман,
Белмим, кайда, кайчандыр бер күргәнмен кук.
Бер күрүем бер гомерлек булган сыман,
Башка күрмәс өчен качып йөргәнмен кук.

Сине тагын күрерменме, белмим инде;
Күрмәсәм дә, эчем пошмас, димен инде.

# АЛТМЫШ ҖИДЕНЧЕ КӨН

*Күрсәтер нәрсәләре булганнар гына*
*күрсәтер нәрсәләрен күрсәтсеннәр иде.*
***Туфан Миңнуллин***

Адәми зат! Һич мактанма бөекмен дип,
Гималай тауларына тиң биекмен дип.

Биеклегең синең ике метрдан ким,
Бөеклегең бер тиенлек бакырга тиң.

Ниең белән масаймакчы булган идең,
Юк күрсәтер нәрсәң, ни уйлаган идең?

# АЛТМЫШ СИГЕЗЕНЧЕ КӨН

*Сатлык җаннар үзләренең бәяләрен яхшы беләләр.*

***Туфан Миңнуллин***

Сатлык җаннар базар хакын белә,
Алыш-белешне дә.
Саннарын
Тиз-тиз куша, елдам бүлә,
Белә кайда сатар җаннарын.

Артык бәя биреп очындырма,
Моңа тиз күнегә сатлык җан.
Аерылган бит ул намусыннан,
Күңелдәге пакьлек, сафлыктан.

## АЛТМЫШ ТУГЫЗЫНЧЫ КӨН

*Түрәләр башмагын чистартып дәрәҗәгә ирешкән*
*зат түрә булсамы?....*
*Алла сакласын!*

***Туфан Миңнуллин***

Чиста башмаклылар ярдәм итсә,
Бик тырышса түбән калмаска,
Ул да түрә була.
Табып ала
Башмак чистартучы алмашка.

Башмаклары чиста, йөзе кара,
Намус ифлас, юк бер изгелек...
Танылла ул:
Башмагына түгел,
Намусына кара иң элек.

# ҖИТМЕШЕНЧЕ КӨН

*Корсактан югары күтәрелә алмаган*
*мораль- кешелекнең иң әче дошманы.*
***Туфан Миңнуллин***

Ашар өчен яшәмим мин, яшәр өчен Ашыйм,-
Дигән борын заман бер даһи.
Шул сүзләрне тотса һәркем гомер буе,
Их шәп булыр иде җирдә, валлаһи!

Корсак икән үлчәү синең әхлакка-
Адәм исемен йөртүең нахакка.

## ҖИТМЕШ БЕРЕНЧЕ КӨН

*Эләк язучыны сүгәргә түгел,*
*кызганырга кирәк.*
*Чөнки ул гарип бәндә.*
***Туфан Миңнуллин***

Эләкчеләр — гарип, кызгану да
Гуманизмга бер билге шул.
Эләкчедән иза чиккәннәрне
Кем кызганыр?
Шуны белмим шул.

Без гуманист.
Әлбәт, кызганырбыз.
Икесен дә тиң саныйк микән?
Болар яман режим корбаны дип,
Уртак бер һәйкәл салыйк микән?

## ҖИТМЕШ ИКЕНЧЕ КӨН

*Ир белән хатын бәхәсләшкәндә*
*хакыйкать җиңелә.*
***Туфан Миңнуллин***

Ир-хатын бәхәсләшкәндә
Нинди хакыйкать булсын,
Талаш-бәхәсле өйләрдә
Нишләп бәрәкәт торсын!?

Бәрәкәт тә, бәхетләр дә
Килешми бәхәс белән.
Бәхәсчеләр торган өйдә
Хәтта хакыйкать үлгән.

# ҖИТМЕШ ӨЧЕНЧЕ КӨН

*Бирәүгә генә гашыйк кеше нәфесле булмый.*
*Аңа шул бирәүдән артыгы кирәкми.*
***Туфан Миңнуллин***

Бәхет бит ул- тик бирәүне сөя белсәң,
Бәхетне тик бирдәнбирдә күрә белсәң.
Бәхетсезләр нәфесен дә тыя алмый,
Бәхетленең тормышына сыя алмый.

Олы бәхет- мәхәббәткә кер тимәсә,
Ике гашыйк арасына чит кермәсә.

# ҖИТМЕШ ДҮРТЕНЧЕ КӨН

*Тыйнак кеше дә, артык мактасаң,*
*әрсезгә әйләнә.*

***Туфан Миңнуллин***

Күп мактама мине, нык мактама,
Әрсезләнәм, артык мактасаң.
Мактауның да үз нормасы бардыр,
Нормасыннан сайла урта сан.

Шушы саннан артып китмәсен ул
Миңа дигән мактау өлеше.
Нормасыннан бик түбәнгә төшмә,
Менә шундый мактау килешле.

# ҖИТМЕШ БИШЕНЧЕ КӨН

*Кирәгеннән артык ихлас булу*
*шәрә йөрү белән бер.*
***Туфан Миңнуллин***

Кирәгеннән артык ихлас булсаң,
Ихласланып үз башыңны җуйсаң,
Кеше көләр, бигрәк инде дивана дип,
Бар хатаңа кайберәүләр куана бит.

Ихлас булуның да нормасы бар,
Нормасына тәңгәл формасы бар.

## ҖИТМЕШ АЛТЫНЧЫ КӨН

*Яшьлек үтми, тән картая-шунда бәла.*
***Туфан Миңнуллин***

Яшьлек чагың үткән, дисәләр дә,
Никтер үтмәгән күк яшьлегем.
Артта калды, күпме еллар, юллар,
Ә күңелем һаман яшь минем.

Тәнем картайган дип уйламыйм да,
Күңел әллә кая ашкына.
Җиде кат күкләргә очар идем,
Көчем җитми, хәл юк чак кына.
Ахмак йөрәк һаман талпына...

## ҖИТМЕШ ҖИДЕНЧЕ КӨН

*Утка салсаң, карт агач та*
*яшь агач кебек яна.*
***Туфан Миңнуллин***

Салма мине сөю утларына,
Карт булсам да дөрләп янармын.
Көлләр булгач, ярсу йөрәгемә,
Бәлки, берәр дәва табармын.

Ходай бәндәсе бит син дә, мин дә,
Сөю килә хәтта картайгач.
Җимешләре дә юк,
Ә барыбер
Ел да яшелләнә карт агач.

# ҖИТМЕШ СИГЕЗЕНЧЕ КӨН

*Хакимгә нәфрәт аңардан курыккан мизгелдән башлана.*

***Туфан Миңнуллин***

Куркыттым да, буйсындырдым, димә,
Буйсынуы тыштан гына ул.
Курыкканның эче тулы нәфрәт,
Юри шулай куштан гына ул.

Хаким берәр кыек бастисә,
Бетә башы-
Куштан баш кисә.

## ҖИТМЕШ ТУГЫЗЫНЧЫ КӨН

*Дөньяда булмаганны табып бирәм дисеңме?*
*Бәхетлеләр генә яшәгән илгә алып бар мине.*
***Туфан Миңнуллин***

Булса иде җирдә берәр шундый дәүләт-
Һәркем зур бәхеткә төренгән.
Күрер өчен генә дә мин китәр идем
Яшәп торган илдән бүгеннән.

Юктыр андый илләр, булмастыр да, диеп,
Пошынкырап озак утырдым.
Бәхетлерәр илләрендә яшим, дигән
Хыялымны күккә очырдым.

Бәхет белән бәхетсезлек якын торыр.
Белмәссең дә, язмыш кайсы якка борыр.

# СИКСӘНЕНЧЕ КӨН

*Сөяркәлек ятак бүлешү генә түгел.*
***Туфан Миңнуллин***

Сөяркәне кемдер таба ятак бүлешер өчен,
Кемдер таба бер-береңне аңлап сөйләшер өчен.

Кемдер бара аңлаучыга эч серен ачар өчен,
Кемдер бара бер мизгелгә хатыннан качар өчен.

Кемдер эзли сөяркәне мактанып сөйләр өчен,
Кемдер- аның кочагында үз көен көйләр өчен.

Хатының иркәләмәсә, сине кемнәр иркәләр?
Әлбәттә, сөяркәләр!

## СИКСӘН БЕРЕНЧЕ КӨН

*Кайбер хатын-кызга надан, томана булу бик тә килешеп тора.*

***Туфан Миңнуллин***

Томана булу да килешә ул
Чибәр генә нәфис хатынга:
Наданлыгын үзе аңлап торса,
Санамаса үзен алтынга;
Охшамаса үзе тутый кошка,
Тиңләмәсә үзен даһи башка.

Томаналык ярыйдыр да берәренә,
Ләкин һич килешми күпләренә.

## СИКСӘН ИКЕНЧЕ КӨН

*Ахмакларның әмерен акыллылар*
*үти башлаган илдә*
*революцион вәзгыять туа.*
***Туфан Миңнуллин***

Революцияләр башлануның
Сәбәбе бик гади, туганнар:
Ахмакларның бөтен кушканнарын
Акыллылар үтәп торганнар.

Ышаналар ахмак әйткәннәргә
Ут төртәләр, үсә ялкыны.
Сүндерәлми алар шул янгынны,
Бергә бетә ахмак, акыллы.

# СИКСӘН ӨЧЕНЧЕ КӨН

*Якынның яты булмый.*
***Туфан Миңнуллин***

Якын булгач, ничек ят булсын, ди,
Ул бит күңелемә якыным.
Аңлый бит ул минем хәлләремне,
Тоеп тора йөрәк ялкынын.

Мин дә тоям ялкыннарын аның,
Шунда бар тормышым, шунда җаным.

## СИКСӘН ДҮРТЕНЧЕ КӨН

*Ир хатыны булу өчен, мадам,*
*башта ирең булу кирәк.*
***Туфан Миңнуллин***

Сүзен тота белгән, ышанычлы иргә
Тиң хатынның бу дөньяда терәге бар.
Әгәр ире ахмак, ышанычсыз булса,
Ир хатыны булуның ни кирәге бар?

Шулай, мадам, башта ирең булу кирәк,
Ир түгелне лучше йөрмә син өстерәп.

# СИКСӘН БИШЕНЧЕ КӨН

*Кеше гомере тоташ кайгы,*
*я тоташ бәйрәм түгел.*
***Туфан Миңнуллин***

И тәкъдирем- узмышы юк язмыш,
Рәхмәт, аз булмады биргәнең.
Соравын да бик күп сорадың шул,
Еш-еш ордың-суктың, тиргәдең.

Синең усал давылларың дулап,
Башларыма яуды ташларың.
Сирәк-мирәк кызгандың да бугай-
Шатлыкларга күмеп ташладың.

Күрсәттең син миңа бу дөньяның
Яхшы-яман төрле кырларын.
Ярый әле, шуңа чыдасын дип,
Бирдең миңа моңлы җырларын.

## СИКСӘН АЛТЫНЧЫ КӨН

*Үзен үзе хөрмәт итмәгән кеше чүп ул,*
*үзен үзе хөрмәт итмәгән халык-чүп өеме.*
***Туфан Миңнуллин***

Үзен хөрмәт итмәс зат көтмәсен
Башкалардан хөрмәт табасын.
Үзен хөрмәт итми торган халык
Чит халыкның ялый табагын.

Кешеме син, әллә бер милләтме,
Кирәк башта хөрмәт итәргә
Үз үзеңне.
Менә шунда гына
Сине хөрмәт итәр читләр дә.

# СИКСӘН ҖИДЕНЧЕ КӨН

*Азга канәгать булган халык*
*бөек эшләр эшли алмый.*
***Туфан Миңнуллин***

Бөек эшкә сәләте бар халык
Һич утырмас кулын кушырып.
Җитте, димәс, һаман ашкыныр ул
Җибәрмәскә үзен уздырып.

Ә канәгать булса бар нәрсәгә,
Ходай биргән миңа җитте, дисә,
Бөек эш юк.
Вагы онытылыр,
Бүгенге көн үтеп кенә китсә.

## СИКСӘН СИГЕЗЕНЧЕ КӨН

*Кешегә кайчан акыл керә?*
*Үзенең дивана икәнлеген аңлаган мизгелдә.*
***Туфан Миңнуллин***

Үземне мин акыллы дип йөргән идем,
Эчтән генә ахмаклардан көлгән идем.

Диваналык үземдә җитәрлек икән,
Уйлап-уйлап торсаң, ис китәрлек икән.

Акыл керү, үсү шуннан башланадыр,
Диваналык үзе шуңа ашламадыр.

# СИКСӘН ТУГЫЗЫНЧЫ КӨН

*Акыллы кешеләр бергә җыелса,*
*җүләр сатып утыралар.*
***Туфан Миңнуллин***

Акыллылар җыелсалар, барма,
Алар анда акыл сатмыйлар.
Пүчтәк нәрсәне дә күперттереп,
Диваналыкларын саклыйлар.

Акыллысы акыл сатмагачтын,
Җүләре дә кулын сузмасын.
Шулар арасында яшәр өчен
Үз акылың җитсен, үз башың.

## ТУКСАНЫНЧЫ КӨН

*Тамчының көче еш тамуында.*
***Туфан Миңнуллин***

Сокланам су тамчысына,
Өстән очып төшә ул.
Очып кына килеп төшә,
Хәтта бозны тишә ул.

Үзе йомшак кына болай,
Йомшак кына, су гына.
Арымастан тамулары
Бер ноктага сугыла.

Бер ноктага сугыла да,
Кыяларны кыйрата.
Су тамчысы гына үзе,
Ә никадәр көч ята!

Кеше!
Тамчы күк бул үҗәт,
Сук бер генә ноктага.
Максатыңа ирешерсең,
Ирешмәслек булса да.

## ТУКСАН БЕРЕНЧЕ КӨН

*Ялгышлар күп, хакыйкать берәү генә.*
***Туфан Миңнуллин***

Мин бердәнбер хакыйкатьне эзләп йөрдем,
Юлларымда ялгышларны бик күп күрдем.

Үземнең дә хаталарым байтак булды,
Вакыт бетте.
Гомер янчыгым да тулды.

Соңрак башка буын жиргә килер әле,
Ул да хакыйкатьне эзләп йөрер әле.
Хакыйкать тик берәү, бәлки, белер әле.

# ТУКСАН ИКЕНЧЕ КӨН

*Гаилә балаларың бабаларының*
*кем икәнен белгәндә генә гаилә була.*
***Туфан Миңнуллин***

Шулай итеп тәрбиялә
Гаиләдә балаларың,
Онытмасын, кемнәр булган
Җиде буын бабалары.

Белмәсәләр - тамырсызлар,
Читләр колы, имансызлар.
Кирәге юк милләтеңә
Һәм мөселман өммәтенә.

# ТУКСАН ӨЧЕНЧЕ КӨН

*Синең бәхетең- минем бәхетем,*
*синең хәсрәтең-минем хәсрәтем.*
*Мәхәббәт шул инде ул.*
***Туфан Миңнуллин***

Мәхәббәткә табынасың, әлбәт, син дә,
Асылы нидәдер, бәлки, белмисең дә.
Асылы шул: уртак сагыш, уртак бәхет,
Уртак кайгы, уртак хәсрәт, уртак тәхет.

Юк хисапта уртак учак, уртак таган,
Искә алмаган аларын Туфан агаң.

## ТУКСАН ДҮРТЕНЧЕ КӨН

*Өстәгеләр кушканга эшләнгән яхшылык яхшылык түгел.*

***Туфан Миңнуллин***

Мин яхшылык эшләдем дип,
Масаеп йөрмә тагын.
Үзең белеп эшләмәдең,
Кылдың түрә кушканын.

Яхшылыклар эшләмичә
Гомерең үтеп бара.
Үз бәямне белим, дисәң,
Яхшылык эшләп кара.

## ТУКСАН БИШЕНЧЕ КӨН

*Пәйгамбәр булмаса, Мөхәммәт дигән*
*исемгә дә исем китмәс иде.*
***Туфан Миңнуллин***

Исемеңә туры килә микән
Шушы җирдә хәят җисемең?
Исемнәре горур яңгырыймы
Яшәп киткән һәрбер кешенең?

Тик бер исем генә юллар ачмас
Биеклеккә менеп җитәргә.
Тик үзеңә бәйле
Исемеңне
Җирдә бөек исем итәргә.

## ТУКСАН АЛТЫНЧЫ КӨН

*Сайлау вакытында скрипкада уйнамыйлар, барабан кагалар.*

***Туфан Миңнуллин***

Сайлаудамы, парадтамы-
Барабаннар кагалар.
Ә кешеләр көтү-көтү
Куган җиргә баралар.

Җырлаганда, моңланганда
Скрипкада уйныйлар.
Менә шуның белән бергә
Барабанны куймыйлар.

Һәрберсенең үз моңы бар, үз җыры бар,
Барабан тукылдатканда
Скрипкага юк иркенлек, урыны тар.

# ТУКСАН ҖИДЕНЧЕ КӨН

*Кануннар күбәйгән саен тәртипсезлек арта бара.*

***Туфан Миңнуллин***

Һәр канунга яңа тәртипсезлек
Бәйләп куелгандыр, мөгаен.
Яңа тәртипсезлек алга баса
Яңа канун чыккан көн саен.

Депутатлар,таралыгыз әле!
Ял итсәгез йоклап ятып та,
Тәртип бозулар хет кимер иде
Сез ял итеп яткан вакытта.

Кануннар көннән- көн арталар,
Ничекләр шул йөкне тартадыр
Халкыбыз.
Ул инде кул селтәп канунга
Уйлыйдыр: ансыз да барырга
Хаклыбыз.

# ТУКСАН СИГЕЗЕНЧЕ КӨН

*Бармагыңа шырпы кергәнгә*
*кешелек дөньясының ни гаебе бар.*
***Туфан Миңнуллин***

Ник дулыйсың кыек басканыңа,
Кемдә табар идең гаепне?
Үзең юньләп атлый белмәгәнгә,
Әйтерсең лә, дөнья гаепле.

Синең аяк, синең гәүдәң бит ул,
Синең куллар, синең бармагың.
Үзең үзеңне дә тоталмагач,
Кем гаепле булсын соң тагын?

# ТУКСАН ТУГЫЗЫНЧЫ КӨН

*Ахмакның белмәгәне юк!*
***Туфан Миңнуллин***

Ахмакларның юк бер белмәгәне,
Алар өчен бар да билгеле.
Үз -үзеннән берәү әсәрләнеп,
Ача бу дөньяның бар серләрен,
Шундый бәндә бигрәк көлкеле.

Шапырынма, бик күп беләм дип,
Кеше көләр, менә җүләр дип.

# ЙӨЗЕНЧЕ КӨН

*Күңелендә җыр йөртмәгән кеше*
*иген игә белми.*

***Туфан Миңнуллин***

Кемгә кирәк җырың,
Туган илең,
Халкың, сөйгән ярың булмаса?
Басуыңда иген үсмәс иде,
Күңелеңдә җырың булмаса.

Җыр тудыра җирдә яшәеш,
Җырың булса, алга бара эш.

# ЙӨЗ БЕРЕНЧЕ КӨН

*Кешедән изге ясау өчен башта*
*аның башына җитәләр!*
***Туфан Миңнуллин***

Адәм бөек булса,
Тәүге адым итеп
Аның барыр юлын кисәләр.
Һаман алга барыйм, дип тырмашса тагын,
Газиз башкаена җитәләр.

Тик соңыннан гына менә шул шәһитне
Изге диеп игълан итәләр.
Нәрсә булыр икән,
Шуны баштан таныл,
Изге бит бу, бөек дисәләр?

## ЙӨЗ ИКЕНЧЕ КӨН

*Хәерченең туган-тумачасы булмый.*
***Туфан Миңнуллин***

Хәерчегә җил дә каршы өрә,
Ора-суга усал давыллар.
Туган -тумачасы танымый да,
Куа аны шәһәр, авыллар.

Кечкенә бер телем ипи тапса,
Шуңа да шат, мескен, карын тук.
Беркемгә дә кирәге юк аның,
Аңа беркайда да урын юк.

И Ходаем, үзең яраткансың
Баен, хәерчесен, ярлысын.
Ник куясың бәндәңне шул хәлгә,
Тигезлек бу җирдә бармы соң?

# ЙӨЗ ӨЧЕНЧЕ КӨН

*Баеган саен югалтырлык нәрсәләрең*
*күбәя бара.*

***Туфан Миңнуллин***

Кайгысы бар икән байларның да,
Баш кагуы мөмкин маллардан.
Бу кайгыдан ярлы читтә:
Мал юк,
Аны күптән тартып алганнар.

Күпме маллар тапса, бичара бай
Шул кадәрле күбрәк кайгыра.
Мал артыннан көн-төн куа торгач,
Була бәндә шундый аңгыра.

# ЙӨЗ ДҮРТЕНЧЕ САН

*Хатыннар гөнаһ кылучы азгын ирне*
*гаепләп сөйлиләр, гөнаһ кыла белмәгән*
*тәкъва адәмнәрдән мыскыллап көләләр.*

***Туфан Миңнуллин***

Әгәр мирдә имеш-мимеш чыкса,
Кайсыдыр бер иргә карата,
Кырык эшен ташлап кырык якка,
Хатын-кызлар гайбәт тарата.

Аның азгынлыгын бәйнә-бәйнә
Сөйләп бирә бөтен кешегә.
Хатын-кыз үпкәле тыйнакларга,
Тиңләмиләр дә ир ишенә.

# ЙӨЗ БИШЕНЧЕ КӨН

*Чибәр хатын-кызны күргәч:*
*«И-их!»-дип куярга онытма.*
***Туфан Миңнуллин***

Чибәр хатын күргән җирдә
Яшьлек хисе тоярсың;
«Вәт мне б такую» — диеп,
Авыр сулап куярсың.

Суласаң, суламасаң да,
Вакытың үткән инде.
Үткәнне сагына торган
Вакытың җиткән инде.

...Ә шулай да чибәрләрне
Бер читкә типмәм инде.

## ЙӨЗ АЛТЫНЧЫ САН

*Чын сәнгатьне ялганыннан аерасың килсә,*
*аңа түләнгән акчага кара.*
*Чын сәнгатькә һәрвакыт әзрәк түлиләр.*
***Туфан Миңнуллин***

Күбрәк-күбрәк сатылсын, дип, ялган сәнгать,
Телевизор ләчтит сата күпме сәгать.

Ялган сәнгать, оялмыйча, үзен сата,
Ә чын сәнгать горурланып, йоклап ята.

Аз түли, дип нигә инде үпкәләргә,
Кирәк хәзер рекламаны җиккәләргә.

# ЙӨЗ ҖИДЕНЧЕ КӨН

*Пьесадагы персонажга исем:*
*Иванов Фәсхетдин Соломонович*
***Туфан Миңнуллин***

Балаларга милли исем
Бирер көн җитәр микән?
Исемен югалтып,
Татар
Үзе дә бетәр микән?

Уйлап торсаң, исең китәр:
Бар татар Светланасы,
Фердинанды, Ленасы,
Индирасы һәм Альфреды,
Гансы бар, Ларисасы;

Артур белән Эдуарды,
Ирина һәм Марина;
Элеонора, Эмилия,
Изольда һәм Карина.

Роберт, Альберт, Рудольфы бар,
Жаннасы, Борис, Вадим...
Бер генә татар исеме
Юктыр,
Валлаһел газим!

## ЙӨЗ СИГЕЗЕНЧЕ КӨН

*Хатын-кызга алдатмадым дигән ирнең*
*ирлегенә мин шикләнеп карыйм.*
***Туфан Миңнуллин***

Хатын-кыздан үзен алдатмаган
Ир-ат җир йөзендә тормый ул.
Үзе теләп тә бер алданмаса,
Ир исәбенә дә керми ул.

Шикләнерлек урыны бар, Туфан,
Алданмаслык ир-ат кайда туган?!

# ЙӨЗ ТУГЫЗЫНЧЫ КӨН

*Дан- чибәр хатын-кызлар затыннан,*
*ул сиңа якын килсә, сак бул.*
***Туфан Миңнуллин***

Даннар яулап алсаң, бик масайма,
Йоклап ятма, данга таянып.
Көйсезлеге, тотрыксызлыгы бар,
Дан вә шөһрәт булмас таяныч,
Ташлап китәр, шунысы аяныч.

Мәңгелек бу даным, дип уйлама,
Җилбәзәк ул, шуңа сайлана.
Бүген синең белән,
Ә иртәгә
Бүтән биргән аны бирнәгә.

# ЙӨЗ УНЫНЧЫ КӨН

*Син, улым, тик тор, яме. Мин*
*синең әниең белән йоклаган кеше!*
***Туфан Миңнуллин***

Шундый сүзләр белән туктатмасаң,
Бүген ахырзаман баласын,
Колагына да сүзеңне элмәс,
Полный дүрәк булып каласың.

Җырлары да безнекечә түгел,
Биюләре башка, бүтәнчә.
Гадәт, тәртипләре дә чит сыман,
Сүзләре дә юк без белгәнчә.

Гасырлардан гасырларга шулай килгән,
Яңа буын үзенчәләп гомер сөргән.

# ЙӨЗ УНБЕРЕНЧЕ КӨН

*Күз яшен бушата торган савыт-*
*бүтәннәр күңеле.*
***Туфан Миңнуллин***

Әле дә бар дуслар, таныш-белешләрем,
Алар китсә, җирдә ялгыз мин нишләрмен.

Кәеф төшсә, акса кайнар күз яшьләрем,
Юатучы алар — якын дус-ишләрем.

Ярый әле, дусларның киң күңелләре,
Озын булсын дусларымның гомерләре.

## ЙӨЗ УНИКЕНЧЕ КӨН

*Гаҗәеп мәгънәле бу татар теле-*
*сәясәт белән сөрген икесе дә*
*бер хәрефтән башлана.*
***Туфан Миңнуллин***

И мөкатдәс изге ана телем,
Синдә күп мәгънәле серләр тулы.
Милләт, мәңге, мәчет һәм мөстәкыйль-
Барысы да безнең тарих юлы.

Бер хәрефтән Себер белән Сембер,
Гыйлем- гайрәт, туу белән тузу.
Ипи белән ислам бергә килә,
Ант һәм аркан, гөл һәм гомер узу.

Юкка гына шулай түгелдер ул,
Бардыр без белмәгән тирән мәгънә.
Адәм артист кына бу дөньяда,
Ә дөньясы- нинди олы сәхнә!

# ЙӨЗ УНӨЧЕНЧЕ КӨН

*Һәр империянең гомере кеше гомере кебек-*
*кыска да була, озын да була, әмма барыбер үлә.*
***Туфан Миңнуллин***

Бетсен тизрәк бар империяләр,
Азат булсын бөтен халык,
Хокуклы бит.
Җирдә һәрбер милләт
Даһи да, ул көчле, алып.

Һәр милләткә үсәр юл ачылсын,
Татыдылар коллык ачысын.

# ЙӨЗ УНДҮРТЕНЧЕ КӨН

*Ике икең дүрт дигәнгә ышанып яшәүчене*
*депутат итеп сайламагыз!*
*Нигә кешене күрәләтә харап итәргә?!*
***Туфан Миңнуллин***

Сайламагыз аны, сайламагыз,
Ике икең аңа дүрт кенә.
Ә тегендә исәп-хисап башка,
Моның эше булыр хөрт кенә.

Намуслыны харап итмәгез,
Гаепсез бер башка җитмәгез!

# ЙӨЗ УНБИШЕНЧЕ КӨН

*Закон бозар өчен языла.*
***Туфан Миңнуллин***

Законнарны язалар,
Үзләре үк бозалар.
Кайда бозу мөмкин,
Шуны
Алдан белеп язалар.

Язган кеше өчен түгел,
Гади халыкка закон.
Бозу юлын тапсаң, пүчтәк,
Боза белмәсәң- закон.

# ЙӨЗ УНАЛТЫНЧЫ КӨН

*Ичмасам, түрә итеп куймыйлар,*
*котылыр идем шигырь язудан!*
***Туфан Миңнуллин***

Котылулар булмас шигырь язудан,
Ул каныңа сеңгән инде, синең җан.

Шигырь язу- үзе бер чир, бер хаста,
Күп шагыйрьләр язган иде бу хакта.

Ярый әле, байтак шундый чирең,
Аннан котылсаң, син нишләр идең!?

# ЙӨЗ УНҖИДЕНЧЕ КӨН

*Бүтәннәр ташлаганга ташланма.*
***Туфан Миңнуллин***

Ач эт түгелбез бит ташланырга
Берәү атып бәргән кисәккә.
Ташланмыйбыз аны күрсәк тә,
Шул кисәксез калып үлсәк тә.

Шуңа ташланырдай бичарага
Ярдәм күрсәтик без тиз арада.

# ЙӨЗ УНСИГЕЗЕНЧЕ КӨН

*Әллә кайчан асылынып үләр идем инде,*
*элмәк кияргә генә иренәм.*

***Туфан Миңнуллин***

Асылынып үләрдәй көн була икән,
Башкаеңа кайгы-хәсрәт тула икән.
Шул чакта да: тукта, үлмим әле бүген,
Ирендерә, элмәкне дә кимим, диген.

Иртәгәсен башка бер көн, башка хәлләр,
Начар гына түгел, килер яхшы хәбәр.
Яхшы хәбәр белән яшәү күңеллерәк,
Дөнья матур.
Кирәк түгел хәзер элмәк.

# ЙӨЗ УНТУГЫЗЫНЧЫ КӨН

*И, Ходай! Биргәнеңне кире ала күрмә.*
***Туфан Миңнуллин***

Байтак бирдең миңа, и Ходаем,
Кире ала күрмә биргәнне.
Яшим әле тагын күпме бирсәң,
Үз кулымда калдыр тирмәмне.

Тирмәм булсын, икмәк, якыннар.
Мин дә бәндәң,
Яшәр хакым бар.

## ЙӨЗ ЕГЕРМЕНЧЕ КӨН

*Халыкка ни кирәген халык үзе түгел,*
*өстәгеләр белә имеш- ха, ха-ха!*
***Туфан Миңнуллин***

Син нәчәлник-мин дүрәк,
Мин нәчәлник-син дүрәк.
Шушы тәртип белән генә
Бу илдә яшәү кирәк.

Ничек инде, гади халык
Кирәген белсен, имеш,
Яшәсенмени нәчәлник
Синең кук гади килеш.

Яратмыйлар өстәгеләр
Хәтта шул килешеңне.
Нишләр, алалмаса
Сиңа
Тиешле өлешеңне?!

# ЙӨЗ ЕГЕРМЕ БЕРЕНЧЕ КӨН

*Ну, перестройка гына үтсен,*
*күрсәтәм әле мин сезгә.*
***Туфан Миңнуллин***

Шундыйрак бер үзгәрешне
Көткән идек көтүен,
Мул заман килер, дип,
Өмет
Иткән идек итүен.

Перестройкага чыдадык,
Түздек башкаларына.
Күрмәгәнне күрдек,
Язмыш,
Тимә балаларыма!

Хет алар яшәсен инде,
Матур тормыш күрсен иде.

# ЙӨЗ ЕГЕРМЕ ИКЕНЧЕ КӨН

*Сугыш коралының ниндие дә*
*үтерер өчен ясала.*
***Туфан Миңнуллин***

Ничек кенә ясасаң да сугыш коралын,
Уртак сыйфатлары да бит бар аның:
Корал-мазар кирәк үтерергә кешене,
Синдәй җан иясен, синең ишеңне.

Кайбер илләр яши, эшли сугыш өчен,
Кеше үтерүгә сарыф итә көчен.

# ЙӨЗ ЕГЕРМЕ ӨЧЕНЧЕ КӨН

*Белеп тор: мин чыгарган закон*
*синең файдага түгел.*
***Туфан Миңнуллин***

Ник тиргисең законнарны бик яман дип,
Алар кеше файдасына чыкмаган дип.
Депутатлар сиңа кеше түгелмени,
Закон алар файдасына түгелмени?

Депутат бул, шулчак синең файдага да
Закон чыгар.
Югалмассың бер кайда да.

# ЙӨЗ ЕГЕРМЕ ДҮРТЕНЧЕ КӨН

*Минме сине дошман күрәм?*
*Юк, агай-эне, минем дошманым булу*
*бәхетенә ирешергә кирәк әле сиңа.*

***Туфан Миңнуллин***

Син дошманым түгел әле минем,
Синең «размер» пока кечерәк.
Соңрак дошман булырсыңмы, юкмы,
Тик акыллырак бул, көчлерәк.

Акылларың җитсә, дошман булмассың,
Акылың гына түбән булмасын!

# ЙӨЗ ЕГЕРМЕ БИШЕНЧЕ КӨН

*Тормышта җайлы урынны күп эзләмә, урынсыз калырсың.*

***Туфан Миңнуллин***

Күп эзләнеп йөрмә бу дөньяда,
Синдәй эзләнүче күп булыр.
Күп эзләнгән буш кул белән кала,
Синең бар тапканың чүп булыр.

Эзләмәссең җайлы урынны,
Җайлый белсәң тирә-кырыңны.

# ЙӨЗ ЕГЕРМЕ АЛТЫНЧЫ КӨН

*Альтернатива булмаган илдә*
*бердәмлек була алмый.*
***Туфан Миңнуллин***

Нигә кирәк альтернативасы,
Алмаш булмас аңа, юк та, -диләр.
Һич ышанма андый кешеләргә,
Алдакчылар, я шук, яки юләр.

Күнеккәннәр инде шушы хәлгә,
Нинди бердәмлек, ди, булсын монда.
Тик берәүнең уе гына дөрес,
Ә бүтәннәр ялгыз.
Һәркем үз юлында.

# ЙӨЗ ЕГЕРМЕ ҖИДЕНЧЕ КӨН

*Акылың адашса,*
*йөрәгеңнән юл сора.*
***Туфан Миңнуллин***

Йөрәгең туры юл күрсәтер
Акылың адашып калганда.
Адашу куркыныч түгел ул,
Йөрәккә ышаныч булганда.

Ышан, ышан йөрәгеңә,
Йөрәк ачык күрә белә.

# ЙӨЗ ЕГЕРМЕ СИГЕЗЕНЧЕ КӨН

*Күзләремә эленеп калырлык*
*бернисең дә юк шул,бәгырькәем.*
***Туфан Миңнуллин***

Калыр идем, карар идем
Мин синең күзләреңә.
Берниең дә эз салмады
Ачык күңелләремә.

Үпкәләмә, күземә дә
Берниең эленмәде.
Борылып карарлык берни
Бөтенләй күренмәде.

## ЙӨЗ ЕГЕРМЕ ТУГЫЗЫНЧЫ КӨН

*Чамаң нинди, чанаң шундый.*
***Туфан Миңнуллин***

Юрганыңа карап аягың суз,
Чамаң белән сайла чанаңны.
Җирдә яшәү шактый күңеллерәк
Дөрес анықласаң чамаңны.

Утырма да башкаларның
Чанасына, арбасына.
Чама белән киләчәккә
Юл ач татар баласына.

# ЙӨЗ УТЫЗЫНЧЫ КӨН

*Уянып китсәм, йокламый ятам икән.*
***Туфан Миңнуллин***

Йоклыйм бугай диеп яттым,
Күземне дә ачмадым.
Йокламаган икәнмен шул,
Торыйм әле, ач карын.

Әллә ятыйм микән ач корсак,
Уянырмын инде, бер торсам.

# ЙӨЗ УТЫЗ БЕРЕНЧЕ КӨН

*Селкенсәң селкен, ава гына күрмә.*
***Туфан Миңнуллин***

Селкенсәң дә, селкен бик сак кына,
Сак булмасаң, авып китәрсең.
Аусаң, торалмассың, тик ятырсың,
Ярдәм итмәсәләр, нишләрсең?

Селкенәем дисәң, уйлап кара:
Авар җирең ничек, йомшакмы;
Торырыңа ярдәм итүчеләр
Бармы шунда, булса — ничаклы.

# ЙӨЗ УТЫЗ ИКЕНЧЕ КӨН

*Әгәр дә кеше маймылдан килеп чыкса,*
*син бу чаклы дуңгыз булмас идең.*
***Туфан Миңнуллин***

Маймылдан да килеп чыккан кеше бардыр,
Кайберәүнең нәсел башы дуңгызлардыр.
Кемнәр никтер этләргә бик охшап тора,
Эттән алып эткә салып әрләп тора.

Бардыр башка хайваннардан чыгучылар,
Бигрәк сирәк коштай күктә очучылар.

# ЙӨЗ УТЫЗ ӨЧЕНЧЕ КӨН

*Мин алда дип мактанма,*
*ат һәрвакыт кучердан алда була.*
***Туфан Миңнуллин***

Алдан бару яхшы ла ул,
Ат булып җигелмәсәң.
Күктә йөзү дә күңелле,
Тамчылап түгелмәсәң.

Җигелүләр, түгелүләр-
Була шундый чаклар да,
Кирәк булса үз илеңне,
Үз халкыңны якларга.

# ЙӨЗ УТЫЗ ДҮРТЕНЧЕ КӨН

*Эшләгәндә киемең кеше көлерлек булсын,*
*бәйрәмдә кеше көнләрлек.*

***Туфан Миңнуллин***

Вазгыятькә карап кием сайларга да
Акылларың җитсен, йөрсәң кайларда да.

Эшкә барсаң, җиң сызганып тирләп эшлә,
Киемең дә туры килсен шушы эшкә.

Ыспай да бул, көяз дә бул бәйрәмнәрдә,
Игътибар ит менә шушы әйткәннәргә.

# ЙӨЗ УТЫЗ БИШЕНЧЕ КӨН

*Алдыңда ашың,*
*кулыңда кашыгың булса,*
*мыжгылдама.*
***Туфан Миңнуллин***

Һәрвакыт та рәхмәтле бул
Ходайның шул биргәненә.
Бар гомерең, бар бәхетең
Менә шушы җирдә генә.

Риза булып ашыңа да кашыгыңа,
Син онытма югарыга ашкынырга.

# ЙӨЗ УТЫЗ АЛТЫНЧЫ КӨН

*Галәмең-кылган гамәлең.*
***Туфан Миңнуллин***

Яшәешең тик үзеңә бәйле,
Ниләр кылсаң, синең дөньяң шул:
Ялкауланып ятсаң – бер күренеш,
Эшчән, тырыш булсаң – дөньяң мул.

Сөекле эш галәм хасил итә,
Аны тапкан кеше бәхетле.
Эшләреңә нәфрәт кенә туса,
Эзләмә дә, таптың ләхетне.

# ЙӨЗ УТЫЗ ҖИДЕНЧЕ КӨН

*Хакыйкать-утлы күмер,*
*учыңа алма-пешәрсең.*
***Туфан Миңнуллин***

Җирдә гел хакыйкать хөкем сөрсә,
Яхшы булыр иде булырын.
Янмый, пешми куллана да белсәң,
Хакыйкатькә һәрчак бар урын.

Хакыйкатьне таныйсыңмы, күрәсеңме?
Таныр булсаң, куллана да беләсеңме?

# ЙӨЗ УТЫЗ СИГЕЗЕНЧЕ КӨН

*Бер иргә түзмәсәң,*
*меңенә түзәргә туры килә.*
***Туфан Миңнуллин***

Түземлегем җитми иремә дип,
Бигрәк алама дип зарлансаң,
Ирсез, ялгыз хатын булып кара,
Бер аңларсың шулчак, аңласаң.

Үзең ир дә, үзең хатын да булырсың,
Мең чит иргә ничек түзеп торалырсың?
Сагынырсың үз иреңне, сагынырсың.

# ЙӨЗ УТЫЗ ТУГЫЗЫНЧЫ КӨН

*Үлеп гашыйк булган хатын-кыздан саклан.*
***Туфан Миңнуллин***

Үтә кызыл тиз уңа, дип
Юкка гына әйтмиләр.
Сөю кайнарлыгын түгел,
Озынлыгын үлчиләр.

Сайламый тор үлеп гашыйк булганын,
Бик тиз генә сүрелүе бар аның.

# ЙӨЗ ҖЫРЫГЫНЧЫ КӨН

*Кендек әбисе: адәм баласы бу дөньяга*
*чыраен сытып туа.*

***Туфан Миңнуллин***

И сабыем, сытма чыраеңны,
Дөнья гел кайгыдан тормый ул.
Шатлыгы да, бәхете дә бар бит,
Тоташ сагыш кына булмый ул.

Тормышыңны ничек кора белсәң,
Шулай булыр синең дөньяң да...
Гамәленә карап галәме дә,
Бәхете дә килер бу җанга.

# ЙӨЗ КЫРЫК БЕРЕНЧЕ КӨН

*Алга баручылар артыннан чап,*
*артта калганнарны көтмә.*
***Туфан Миңнуллин***

Көтеп торма артта калганнарны,
Килерләр дә узып китәрләр.
Туктамыйча алга гына йөгер,
Елгырлары куып җитәрләр.

Артка калма, тырыш, йөгер, алга чап,
Шунда күпләр синең арттан барачак.

## ЙӨЗ КЫРЫК ИКЕНЧЕ КӨН

*Мескенләнмә, югыйсә шәхес була алмыйсың.*
***Туфан Миңнуллин***

Бу дөньяда гарип чебеш булма,
Кешеме син,
Яки милләтме.
Зур кикрикле әтәч булып яшә,
Танысыннар синең кодрәтне.

Әтәчмен дип, масайма да,
Тирә-якка лаф орма син.
Ләкин үзен чукытмас, дип,
Тисәң, чокып ташлар бу, дип,
Күршеләрең белеп торсын.

Шәхес булыйм дисәң, мескенләнмә,
Ничек шәхес булсын мескен бәндә?!

# ЙӨЗ КЫРЫК ӨЧЕНЧЕ КӨН

*Тәлинкә ялыйсың килсә,*
*тәлинкә куелган өстәлгә сукма.*
***Туфан Миңнуллин***

Өстәленә суга күрмә,
Тәлинкәсен ялыйм дисәң.
Бернәрсә дә тимәс сиңа,
Ялыйм әле диеп килсәң.

Ашап туймаганны, ялап туймассың инде;
Бер ялап күнексәң, шуны куймассың инде.

# ЙӨЗ КЫРЫК ДҮРТЕНЧЕ КӨН

*Ике кеше сөйләшкәнне качып тыңлап торма.*
*Бәлки алар синең турыда дөресен сөйлидер.*
***Туфан Миңнуллин***

Качып тыңлап торма,
Икәү
Торса нидер сөйләнеп.
Синең хакта сөйлиләрме,
Бик беләсең киләме?

Кайчагында белгәнеңнән
Белмәгәнең яхшырак.
Сөялер җир табалмассың,
Ишеткәнгә аптырап.

## ЙӨЗ КЫРЫК БИШЕНЧЕ КӨН

*Күп казынма, каза казып чыгаруың ихтимал.*
***Туфан Миңнуллин***

Казынырга кирәктер ул,
Ләкин белеп чамасын.
Чамасыннан узып китеп,
Каза чыгып калмасын.

Иң элек бел, нигә соң казынасың;
Уйлап кара нәрсәләр табыласын.

# ЙӨЗ КЫРЫК АЛТЫНЧЫ КӨН

*Хатын-кызның кем икәнен беләсең килсә,*
*аның кемне яратканына күз сал.*

***Туфан Миңнуллин***

Кемне яратадыр бу хатын-кыз,
Кемгә тартыладыр күңеле,
Хатын-кызга нәрсә кирәклеген
Шуннан белеп була түгелме?

Ярый әле, күңеле сиңа тартылса,
Чын күңелдән тартылуы хак булса.

## ЙӨЗ КЫРЫК ҖИДЕНЧЕ КӨН

*Хатының эшләп тапкан акчаны эчеп бетермә,*
*беренче хатыныңдагы балаларыңа*
*алимент түләргә дә калсын.*

***Туфан Миңнуллин***

Чуртымамы эчеп бетерәсең
Тапкан бар акчасын хатынның?
Синең тегендәге балаларың
Инде алиментсыз калсынмы?

Уйлап кара бераз башың булса,
Син алкашны кемнәр сөяр соң?
Тегендә дә монда балаларың,
Үскәч сиңа нәрсә дияр соң?

# ЙӨЗ КЫРЫК СИГЕЗЕНЧЕ КӨН

*Тәнкыйтьне күтәрә алмасаң,*
*товарыңны базарга чыгарма.*
***Туфан Миңнуллин***

Тәнкыйтьчеләр табар кимчелекләрен дә,
Уйлама да, товарның, дип, тиңе юк.
Табыла ул синекеннән яхшыраклар-
Камиллекнең бер яктан да чиге юк.

Күрсәтмә дә әйбереңне башкаларга,
Кеше сүзләренә чыдый алмасаң.
Мактанма да кылган гамәлләрең белән,
Тыйнак кеше дигән данны дауласаң.

# ЙӨЗ ҚЫРЫК ТУГЫЗЫНЧЫ КӨН

*Дөньяга күзеңне кысып карама,*
*кытай түгелсең.*
***Туфан Миңнуллин***

Кытай, япон, корей түгелсең бит,
Хәтта монгол, чукча түгел син.
Ник күзеңне кыстың әле болай,
Йөзең кемгә охшап күренсен?

Күзләреңне ничек кыскалама,
Татарлыгың чыккан төсеңә.
Маташма да,
Татар икәнлегең
Очраган бер кеше төшенә.

Татар!
Күзләреңне ачып кара,
Ачык күзләр генә алга бара.

## ЙӨЗ ИЛЛЕНЧЕ КӨН

*Яшисе килмичә муенына элмәк салганны*
*коткарырга алынма,*
*яшисе килгәннең*
*кулына элмәк тоттырмаска тырыш.*

***Туфан Миңнуллин***

Бу дөньядан бизеп, чыдамының
Иң чигенә җиткән бәндәгә
Сүзең үтмәс.
Кара башкаларны,
Калмасыннар шундый хәлгә дә.

Дөнья бит ул, агы була, карасы да,
Менү, төшү, туктау, алга барасы да.

# ЙӨЗ ИЛЛЕ БЕРЕНЧЕ КӨН

*Күрергә теләмәгәнне үбәргә үрелмә.*
***Туфан Миңнуллин***

Күрергә дә теләмәсәң,
Үрелмә үбәргә дә.
Үрелмә
Сине күрәсе
Килмәгән чибәргә дә.

Шушы гынамыни сиңа
Бәхете бар дөньяның,
Бер үбүдән башка да бит
Бәхетләре бар аның!

## ЙӨЗ ИЛЛЕ ИКЕНЧЕ КӨН

*Әгәр дә черки икәнсең,*
*сытып үтерәчәкләрен белеп яшә.*
***Туфан Миңнуллин***

Бар белгәнең кан суыру булса,
Үпкәләсе дә юк язмышка.
Барыбер бит сытып үтерәләр,
Калдырмыйлар сине бу кышка.

Түгелсең бит эшчән кырмыска,
Шуңа гомерләрең бик кыска.
Белсә шуны «көчле» милләтләр,
Көчем бар-мин хуҗа, димәсләр.

# ЙӨЗ ИЛЛЕ ӨЧЕНЧЕ КӨН

*Арыш чәчелгән басудан*
*бодай эзләп маташма.*
***Туфан Миңнуллин***

Ни чәчсәң, урырсың шуны,-диеп
Борынгылар дөрес әйткәннәр.
Алар бездән акыллырак булган:
Ни урасын уйлап чәчкәннәр.

Бала баккан алар тәрбияләп, сөеп,
Ышанычлы булсын балам, диеп.

## ЙӨЗ ИЛЛЕ ДҮРТЕНЧЕ КӨН

*Әле дә ярый фәрештәләр күзгә күренеп*
*очып йөрми. Әллә кайчан атып төшереп,*
*канатлары белән идән себерерләр иде.*
***Туфан Миңнуллин***

Башка нәрсә күтәп булмый шушы халыктан,
Бер-берсенә охшаш, барысы бер калыптан.

Фәрештәме бу зат, даһи микән, ерунда,
Үлсен.
Сөйләрләр әле шул адәм турында.

# ЙӨЗ ИЛЛЕ БИШЕНЧЕ КӨН

*Түрәлек- үзгәрми торган гадәт*
*һәм үтми торган чир.*
***Туфан Миңнуллин***

Нинди гадәт, нинди үтмәслек чир,
Йогышлы да үзе, зарарлы.
Егет, кызмы, түрә генә булсын,
Тиз оныта таныш-мазарны.

Борын күккә чиксез чөелә дә,
Үз-үзенә корсак күренми.
Бүтән түрә югарырак булса,
Бусы тезен чүгеп дерелди.

Түрәләрне һич күрсәтмәс идем,
Бала-чага, яшь кыз, егеткә.
Өйрәнмәсен иде шул гадәткә,
Иярмәсен түрә кебеккә.

# ЙӨЗ ИЛЛЕ АЛТЫНЧЫ КӨН

*Дошманыңны җылатасың килсә,*
*көлеп яшә.*

***Туфан Миңнуллин***

Җылама син, дошман шатланмасын,
Җырлап-көлеп яшә, көнләшсен!
Шулчак дошманыңның көлү түгел,
Елмаюын да һич күрмәссең.

Көнләшүдән дошман җыласын,
Онытыр да этлек кыласын.

# ЙӨЗ ИЛЛЕ ҖИДЕНЧЕ КӨН

*Оятыңнан кызарырга өйрән,*
*каралуың ихтимал.*
***Туфан Миңнуллин***

Оятыңнан бит кызарса, ярый,
Җан каралса, ничек яшәрсең.
Каралган җан кемгә кирәк булсын,
Менә шундый хәлдә нишләрсең?

Кешеләргә җирдә оят кирәк,
Оятсызлар күбәйделәр бигрәк.

# ЙӨЗ ИЛЛЕ СИГЕЗЕНЧЕ КӨН

*Джинс чалбарның тезләре тишелсә,*
*салып ыргыт.*
*Ыштансыз заманда чалбарның кирәге юк.*
***Туфан Миңнуллин***

Джинсы чалбарымның тезе тишек,
Тезләр генә түгел, арты да.
Мода шундый:
Ертык джинсы чалбар
Кия хәзер яше, карты да.

Ыштансыз да йөрер идем әле,
Ул да килешле бу заманга.
Бетә җенес аерымлыгы, ди,
Шәрәлек тә килер таманга.

# ЙӨЗ ИЛЛЕ ТУГЫЗЫНЧЫ КӨН

*Төн уртасында яман төш күреп уянсаң,*
*карчыгыңның да кабыргасына төртеп уят,*
*рәхәтләнеп йоклап ятмасын.*

***Туфан Миңнуллин***

Мин йокламаганда ничек инде
Йоклап ятасың син, карале!
Төшемдәге чибәр син түгел бит,
Күзге каршысына барале:
Анда карчык.
Монда ята картлач...
Син бит миңа һаман яр әле.

Миңа кара, җаным, уянчы,
Йокларсың мин киткәч, туйганчы.

## ЙӨЗ АЛТМЫШЫНЧЫ КӨН

*Йокың тәмле булсын дисәң,*
*чиста намусыңны кочаклап йокла.*
***Туфан Миңнуллин***

Намусы чиста кешенең
Борчылуы аз була.
Йокысы да тәмле, татлы,
Уянуы наз гына.

Чиста намус саклар йокыңны,
Төшләрең дә булмас шаукымлы.

# ЙӨЗ АЛТМЫШ БЕРЕНЧЕ КӨН

*Акылыңны сыныйсың килсә,*
*ахмак кеше белән сөйләш.*
***Туфан Миңнуллин***

Бәхәсләшмә ахмак белән.
Тик сөйләшеп кара гына:
Акыллыдан ахмаккача
Миллиметр ара гына.

Бер-берсенә якын торамы-
Үтеп китмә шушы араны.

# ЙӨЗ АЛТМЫШ ИКЕНЧЕ КӨН

*Иртән чәй эчәргә шикәрең булмаса,*
*югалып калма, ананас согына*
*«Наполеон» коньягы тамызып эч.*
***Туфан Миңнуллин***

Ананас та, «Наполеон» да бар,
Ләкин шикәрең юк өстәлеңдә.
Крокодилдан каеш билләреңдә,
Ләкин ыштаның юк өсләреңдә.

Модалары, бәлки, шулайдыр,
Ыштансыз йөрүе кулайдыр.
«Наполеон» булса җитә бит,
Шикәрсез дә чәең үтә бит.

Коньяк исе килеп торсын синнән,
Шикәрең дә юк дип кемнәр белгән?!

## ЙӨЗ АЛТМЫШ ӨЧЕНЧЕ КӨН

*Язмыш яңагыңа сукканда күзеңнән*
*утлар күренә икән,*
*югалып калма-шул уттан*
*тәмәке булса да кабызып калырга тырыш.*

***Туфан Миңнуллин***

Язмыш орган-суккан чаклар була:
Күздән чаткы оча, «тамызса».
Тәмәке тот учта.
Хет бер файда-
Тәмәкеңне шул ут кабызса.

Бәлки, өйрәнеп тә карарсың,
Тукмалганнан файда табарсың.

# ЙӨЗ АЛТМЫШ ДҮРТЕНЧЕ КӨН

*Язучы буласың килсә, иң элек*
*Язучылар берлегенә әгъза булып кер.*
*Аннан, язарга өйрәнерсең.*
***Туфан Миңнуллин***

Әйбәт киңәш!
Керер берәү шул Берлеккә,
Ләкин анда кемгә сөялер икән?
Барысы да аның күк өйрәнчек булса,
Язу эшен кемнән өйрәнер икән?

Берлек әгъзасы булгачтын шушы бәндә
Тиздән масаер да, мактаныр микән?
Чын шагыйрьләр, язучылар арасында
Мәшәкатьсез генә картаер микән?

## ЙӨЗ АЛТМЫШ БИШЕНЧЕ КӨН

*Пьеса ничек языла дип сорама:*
*нәрсә турында һәм ничек язарга белсәң,*
*пьеса язу бик җиңел.*

***Туфан Миңнуллин***

Рәхмәт Сиңа, Туфан чордаш, пьеса язу
Пүчтәк кенә икән ләбаса.
Бүгеннән үк яза башлыйм әле мин дә,
Шушы эштә Синнән калмаска.

Язуын мин, әлбәт, язармын.
Ни турында һәм ничекне
Кайдан эзләп табармын?!

# ЙӨЗ АЛТМЫШ АЛТЫНЧЫ КӨН

*Поездда барганда купедашларыңның*
*кайсы милләттән икәнен беләсең килсә,*
*татарча сөйләшеп кара.*
*Сиңа сырты белән борылып*
*утырганы татар булыр.*

***Туфан Миңнуллин***

Ике татар, гәп урысча,
Татар булуга карамый.
Җыр тыңларга булса берсе,
Татар җыры һич ярамый.

Ике татар көрешкәч тә,
Көрмәкләшә үзара:
Дошман итеп бер-берсенә,
Төзеп куя икесенә
Өч партия тиз ара.

Ничек урыс булырга дип,
Бахырларның башы ката.
Сез барыбер татар инде,
Башка сүзләр- бер сафсата.

# ЙӨЗ АЛТМЫШ ҖИДЕНЧЕ КӨН

*Халкыңның кем икәнен беләсең килсә,*
*илеңнең законнарын укып чык.*
***Туфан Миңнуллин***

Һәр халыкның бар яраклы иле,
Илендә бар төрле законнар.
Үтәлмәслек булса законнарың,
Кемгә үпкәләргә хакың бар!?

Яшәгәчтен начар закон белән,
Килешерсең яманатың белән.

## ЙӨЗ АЛТМЫШ СИГЕЗЕНЧЕ КӨН

*Хатының сөяркә кебек мәхәббәтле күренсен дисәң, аерыл да янына барып йөр!*

***Туфан Миңнуллин***

Аерылам, аерылам,
Хатын булсын сөяркә!
Куркам гына, нишләрмен дип,
Бүтән иргә сөялсә,
Башкаларга иярсә.
Әллә өйдә генә калыйм микән,
Хатынымны сөяркә дип атыйм микән?

# ЙӨЗ АЛТМЫШ ТУГЫЗЫНЧЫ КӨН

*Ун муллага ялынганчы, бер Алладан сора.*
***Туфан Миңнуллин***

Үтенечең булса, ялынма син,
Күпме булсалар да, муллага.
Алар сиңа ярдәм итәлмәсләр,
Ялвар тик бердәнбер Аллага.

Мулла ачмас җәннәт капкаларын,
Бу эш килми аның кулыннан.
Ул тик юл күрсәтә тайпылмаска
Изге ислам дине юлыннан.

Бөтен кодрәт, бөтен мөмкинчелек
Бер Аллада, юк ул адәмдә.
Ходай ихтыяры белән яши
Тере җаннар, бөтен галәм дә.

# ЙӨЗ ҖИТМЕШЕНЧЕ КӨН

*Хатының, туңам, җылыт әле, дисә,*
*тун алып бир- күңеле булсын.*

***Туфан Миңнуллин***

Ярый, күңелләре булса бер тун белән генә,
Бик тиз үсә кызның нәфесләре, өйлән генә.

Беләлмәссең, аңа нәрсә кирәк булырын да,
Ирен кайсы якка, ничек итеп борырын да.

Ничек булыр икән кочып җылытсам,
Үбеп, күз яшьләрен корытсам?

# ЙӨЗ ҖИТМЕШ БЕРЕНЧЕ КӨН

*Хатыныңның кадерен бел.*
*Белмәсәң, аның күңелен ятлар күрер.*
***Туфан Миңнуллин***

Гаиләсен хөрмәт иткән ир-ат
Үз хатынын сөеп, кадерләп
Яшәр иде.
Шул сөеклесенә
Җирәк бөтен шартлар хәзерләп.

Булмый гына, дөнья шактый кырыс,
Көтмәгәндә давыл кубадыр.
Хатыныңны гел кадерләп кенә
Яшәп булмавы да шуңадыр.

# ЙӨЗ ҖИТМЕШ ИКЕНЧЕ КӨН

*Эт булуың җиткән,*
*дуңгыз да булма инде,*
*пажалыста.*
***Туфан Миңнуллин***

Этләрнең күп яхшы яклары,
Байтак була матур чаклары.
Дуңгызларның гына нибары-
Киң таралган яманатлары.

Әгәр булса бер үк кешедә
Эт һәм дуңгызга хас сыйфатлар,
Маймыл нәселеннән адәм дип,
Кемнәр, ничек итеп исбатлар?

# ЙӨЗ ҖИТМЕШ ӨЧЕНЧЕ КӨН

*Маймыч белән маймыч булганчы,*
*чуртан белән кода бул.*
***Туфан Миңнуллин***

Маймыч белән маймыч буласым юк,
Андый вакытларым үткән бит.
Нигә чуртан белән кодалашыйм,
Аның йөзәр көне беткән бит,
Аңа кармак килеп җиткән бит.

Баш та ватасым юк нишләргә,
Якын дус булыйм мин тиңнәргә.

# ЙӨЗ ҖИТМЕШ ДҮРТЕНЧЕ КӨН

*Әниеңнең пенсия акчасын алып киткәч,*
*радио аша әниләр турында җыр*
*бүләк итәргә онытма.*

***Туфан Миңнуллин***

Алып киттем әнкәемнең пенсиясен,
Ярый әле әнкәй исән, күз тимәсен.

Акча аңа нигә?
Йоклар, торыр, ятыр,
Әнкәй өчен радио җыр яңгыратыр.

# ЙӨЗ ҖИТМЕШ БИШЕНЧЕ КӨН

*Атаң-анаң телен белмәү гаепме, оятмы?*
***Туфан Миңнуллин***

Космополит бит мин, атам-анам теле
Киртә була миңа үсәргә,
Дигән идең.
Ахмаклыгың, гаебең дә,
Оятсызлык та шул сүзләрдә.

Яшә белеп газиз атаң-анаң телен,
Менә шунда синең кешелегең.

# ЙӨЗ ҖИТМЕШ АЛТЫНЧЫ КӨН

*Йорт хуҗасыннан курыкма,*
*аның ишек төбен саклаучы эттән курык.*

***Туфан Миңнуллин***

Йорт хуҗасы сүз дә әйтмәс, бәлкем,
Хуҗасыннан усал эте бар.
Начальникка керер йомыш булса,
Секретарьга күрсәт игътибар.

Фикерләмә хуҗасына гына карап,
Бик еш хуҗасыннан эте усалрак.

# ЙӨЗ ҖИТМЕШ ҖИДЕНЧЕ КӨН

*Акыллы буласың килсә, акыллы кешеләр белән генә аралаш.*
***Туфан Миңнуллин***

Дусларың кем булса, син дә шундый,
Дигән акыллы сүз бар икән.
Акыллылар белән йөргән адәм
Үзе шуларга охшар икән.

Күчмәсә дә бүтән кеше акылы,
Аңлый башлый акыл асылын.

# ЙӨЗ ҖИТМЕШ СИГЕЗЕНЧЕ КӨН

*Ачуың кайнаганда пешәсең килмәсә, дәшми түз.*

***Туфан Миңнуллин***

Әйтмә бер сүз,
Дәшмә дә түз,
Ачуың кайнаса да.
Пешмәссең син,
Бетмәссең син,
Җил-давыл дуласа да.

Эчеп җибәр салкын суың,
Кайнап чыкса ачуың.

# ЙӨЗ ҖИТМЕШ ТУГЫЗЫНЧЫ КӨН

*Үзеңне күпмегә бәяләсәң, мин дә
сиңа шул бәяне бирәм.*
***Туфан Миңнуллин***

Үз бәяңне үзең белсәң кирәк,
Шуннан артык бәя бирмәм, димәк.

Турсайма, үз бәяң бит, аппагым,
Саубуллашып ни әйтим соң тагын?

Синең бәяң менә шундый икән,
Артыгын мин ничек бирим, иркәм?

# ЙӨЗ СИКСӘНЕНЧЕ КӨН

*Шәрәне чишендереп азапланма.*
***Туфан Миңнуллин***

Шәрә- шәрә инде ул,
Чишендерәсе дә юк.
Китәм, әйдә үкенсен,
Үкендерәсе дә юк.

Чишенмичә үкенсен,
Чишендермәде диеп.
Килер әле бервакыт
Матур күлмәген киеп.

# ЙӨЗ СИКСӘН БЕРЕНЧЕ КӨН

*Балыкны йөзәргә өйрәтергә алына күрмә.*
***Туфан Миңнуллин***

Өйрәтеп маташма останы,
Барыбер ул синнән остарак.
Оятка каласың килмәсә,
Өйрәнеп ал эшне баштарак.

Син тыңдаш булганчы остага
Җитмеш кат тирләрең түгәрсең.
Остадан остарак булырга
Кулыңнан килерме, сизәрсең.

Өйрәтеп маташма останы,
Өйрәнчек бул үзең остага.
Шул эшне тырышып өйрәнгән,
Эшләгәннәр генә остара.

# ЙӨЗ СИКСӘН ИКЕНЧЕ КӨН

*Үз гәүдәңне үзең күтәререгә иренеп,*
*аны кеше җилкәсенә салырга тырышу-*
*оятсызлыкның беренче билгесе.*

***Туфан Миңнуллин***

Оятсызлар белән дөнья тулды хәзер,
Күтәрәсе килми хәтта үз гәүдәсен.
Башка кеше җилкәсендә утыралар,
Әллә оныттымы Ходай үз бәндәсен.

Онытмаса, бер чарасын табар иде,
Оятсызларга бик кырын карар иде.

# ЙӨЗ СИКСӘН ӨЧЕНЧЕ КӨН

*Колагыңа киртләп куй:*
*бер алманы бишкә бүлеп бирсәң,*
*рәхмәт әйтәчәкләр,*
*мең алманы икегә бүлеп бирсәң,*
*ызгыш чыгачак.*

***Туфан Миңнуллин***

Бер алманы бишкә бүләек,
Сәламәтлек, байлык теләек.
Тик булмасын байлык чиктән тыш,
Шунда чыга күптән -күп ызгыш.

Саклана күр ызгыш-сүгештән,
Ныклап уйла, әгәр бүлешсәң.

## ЙӨЗ СИКСӘН ДҮРТЕНЧЕ КӨН

*Күпне вәгъдә итмә, ышанмыйм.*
***Туфан Миңнуллин***

Ышаныч юк күпне вәгъдә итүчегә,
Колак салмыйм күпне ишетүчегә.

Тыңламыйм бик күпне сөйләүчене дә,
Якын тотмыйм юха көйләүчене дә.

Чамалы сүзләр генә дөрес, яхшы,
Чамасыннан узган кеше- алдакчы.

# ЙӨЗ СИКСӘН БИШЕНЧЕ КӨН

*Базардан гаделлек таләп итеп*
*ахмаклык эшләмә.*

***Туфан Миңнуллин***

Ахмак булдыңмыни, ник базарда
Гаделлекләр эзләп йөрдең син?
Гаделлек хәтта базарда барын
Кайда, кайсы илдә күрдең син?

Базар — базар инде: кем сата,
Ә кем үзен шунда алдата.

# ЙӨЗ СИКСӘН АЛТЫНЧЫ КӨН

*Ахмак икәнсең, акыллы булырга тырышма,*
*зуррак ахмаклык кылып ташлавың бар.*
***Туфан Миңнуллин***

Ахмак икәнлегең үзең белсәң,
Артык зыянлы да түгелдер.
Акыл сатарга да маташмасаң,
Бераз акыллысы үзеңдер.

Акыллы булам, дип тырышма да,
Акыллы зат белән ярышма да.

# ЙӨЗ СИКСӘН ҖИДЕНЧЕ КӨН

*Яшьлектә эшли алмаган егетлекне*
*картайгач эшләп маташма.*

***Туфан Миңнуллин***

Егетлек ул яшь чакларда гына,
Тирән акыл керә картлыкта.
Үкенмә син, егетлегем юк дип,
Яшь кыз түгел инде карчык та.

Ояты юк көч җитмәсә хәзер,
Ярдәм өчен оныкларың әзер.

## ЙӨЗ СИКСӘН СИГЕЗЕНЧЕ КӨН

*Сынап кара: хатын-кыз*
*ялындырганда гына үбешү тәмле.*
***Туфан Миңнуллин***

Ялындырганда да тәмле була,
Ялындырмаса да татлы ул.
Син өзелеп сөйгән хатыныңны
Үбү- куаныч та шатлык ул.

Сынадым мин моны ничаклы-
Сөйгән ярым һәрчак бик татлы.

# ЙӨЗ СИКСӘН ТУГЫЗЫНЧЫ КӨН

*Өйләнгәндә онытма:*
*кияүгә чыккач та кыз булып калуына*
*хәләлең гаепле түгел.*

***Туфан Миңнуллин***

Өйләнгәчтен син ир була белсәң,
Хәләлең дә сиңа хатын булыр.
Үз акылың шуңа җитми икән,
Хатын бүтән иргә якын булыр.

Хәләлеңне сөйсәң хатын ул, дип,
Ул да сине сөяр алтын ул, дип.

## ЙӨЗ ТУКСАНЫНЧЫ КӨН

*Рәхәтләнеп җыла,*
*иң тиз кибә торган сыеклык-*
*күз яше.*

***Туфан Миңнуллин***

Әгәр җылап алсаң кирәгендә,
Күңелләр дә бушап кала ул.
Сагышларны бераз таратырдай,
Бераз җиңеләйтер чара ул.

Җыла-җыла һәрчак, димим сиңа,
Җылауның да бардыр чамасы.
Җыласаң да, җыла белеп кенә
Күз яшьләрең кая тамасын.

# ЙӨЗ ТУКСАН БЕРЕНЧЕ КӨН

*Егылудан курыксаң, шуыш-*
*шуышканнар егылмый.*
***Туфан Миңнуллин***

Җирдә генә шуышучы бер дә
Егылмый шул, бу сүз дөрес тә,
Ләкин тик шуышып яшәгәндә
Алга бармас бит көнкүреш тә.

Текә басып йөрү хәвефлерәк,
Бик ихтимал була егылу.
Егылгачтын син тора да белсәң,
Менә шулдыр алга омтылу.

# ЙӨЗ ТУКСАН ИКЕНЧЕ КӨН

*Сукыр кулына шәм тоттырма,*
*таяк бир.*

***Туфан Миңнуллин***

Ярдәм итим дисәң бичарага,
Утыртма да аны буш чанага.
Теләкләре аның, бәлкем, башка,
Ни мохтаҗлык барын бел син башта.

Кемгә ни кирәген беләсеңме,
Иң кирәген генә бирәсеңме?
Сусаганнар суга мохтаҗ була,
Өшегәннәр тунга бик шат була.

Сукырларга кирәк була таяк,
Адашканнар өчен яса маяк.

# ЙӨЗ ТУКСАН ӨЧЕНЧЕ КӨН

*Тумыштан диванаsuccessionаны укытып харап итмәгез.*
***Туфан Миңнуллин***

Тумышыннан ук дивана
Яши башка дөньяда.
Анда беркемгә юк урын,
Сиңа да юк, миңа да.

Аның дөньясын җимермә,
Безнең дөнья чит аңа.
Бәхетле үз дөньясында,
Шунда торсын дивана.

# ЙӨЗ ТУКСАН ДҮРТЕНЧЕ КӨН

*Кәҗә яшь агачның каерысын*
*яратып кимерә.*
***Туфан Миңнуллин***

Кәҗә генә түгел, төрле кортлар
Яшь каерыны күбрәк ярата.
Менә шунда бит ул чын хакыйкать
Хәтта кешеләргә карата:
Кешеләр дә яшьне ярата.

Картмын, яшьнең кирәге юк, диммени,
Адәми зат кәҗәләрдән киммени?

# ЙӨЗ ТУКСАН БИШЕНЧЕ КӨН

*Теше төзек матур күлә.*
***Туфан Миңнуллин***

Теше төзек матур күлә,
Төз аяклар атлап килә
Килештереп.
Көлеп атла,
Шушы матурлыкны сакла.

Явыз булма кешеләргә,
Ачуланма көнчелләргә.
Изгелегең башкаларга
Артып кайта сиңа бар да.

# ЙӨЗ ТУКСАН АЛТЫНЧЫ КӨН

*Сараннан әйбер алу йоннан*
*тигәнәк аралау сыман.*
***Туфан Миңнуллин***

Тигәнәкне була йоннан аралап,
Берәр нәрсә алып кара сараннан!
Булдыралсаң, менә дигән егет син,
Даның булыр бөтен миргә таралган.

Исе китәр бар күргән, бар караган,
Нинди нәселдән икән, дип, яралган
Синең кебек шундый акыл иясе.
Син маладис!
Тагын нәрсә диясе?

## ЙӨЗ ТУКСАН ҖИДЕНЧЕ КӨН

*Үләсең килсә-үл,үләсең килмәсә-көл.*
***Туфан Миңнуллин***

Ятып үләсеңме, торып көләсеңме,
Кемнең синдә нинди эше бар?
Кайчагында үләсең дә киләдер ул,
Яшәү яме китсә, дөнья тар
Тоелганда.
Тик үлемгә ашыкмагыз,
Чакырмасаң да килә бит шушы явыз.

Үлмим дисәң, көлеп яшәргә тырыш,
Синең өчен дөнья булса да кырыс.

# ЙӨЗ ТУКСАН СИГЕЗЕНЧЕ КӨН

*Мулла, сәдака бирегез, ди,*
*нигә үзе бирми?*
***Туфан Миңнуллин***

Аптырыйм мин муллаларга,
Ник сәдака бирмиләр?
Сәдака бирмәсәң, сине
Үзләре бик тиргиләр.

Әй имансыз син, диләр,
Ник үзләрен белмиләр?

# ЙӨЗ ТУКСАН ТУГЫЗЫНЧЫ КӨН

*Калҗаң булса, марҗа табыла.*
***Туфан Миңнуллин***

Калҗаң булса, марҗа табыладыр,
Марҗаң булса, калҗа табарсыңмы?
Калҗаң белән бергә марҗаң барда
Шул калҗаны үзең кабарсыңмы?

Әллә авызыңны ябарсыңмы,
Тизрәк качу ягын карарсыңмы?

## ИКЕ ЙӨЗЕНЧЕ КӨН

*Ант итмәгәннәр антын боза алмый.*
***Туфан Миңнуллин***

Ант итмәгән кеше рәхәт яши,
Аңа һичкем гаеп тагалмый
Антын боза диеп.
Исеме дә
Һәрчак ап-ак була, каралмый.

Ярый, каралмаса, каралса да,
Антны яратмаса, яратса да,
Кемгә кызык шушы антсыз бәндә,
Кайда качып торган ант иткәндә?

# ИКЕ ЙӨЗ БЕРЕНЧЕ КӨН

*Хыянәтче башта кемне сата-*
*үзенме, бүтәннәрнеме?*
***Туфан Миңнуллин***

Хыянәтче җанын сата,
Җаны белән тәнен сата.
Бер сатылып киткән бәндә
Гел хыянәт көтеп ята.

Тынычлык юк бу дөньяда
Сатлык җанга бер кайда да.
Сатса да ул башкаларны,
Җаны тыныч урын бармы?

## ИКЕ ЙӨЗ ИКЕНЧЕ КӨН

*Ялагай «ялау» сүзеннән алынмады микән?*
***Туфан Миңнуллин***

«Ялау» сүзеннәндер ялагай,
Ә сул кулга бәйле сулакай.
«Сука» дигән сүздән -сукалый,
«Юха» дигән сүздән -юхалый.

Ялагайлар оста юхалыйлар,
Шуңа укыганнар шикелле.
Кемдә юха белән ялау бергә,
Анда вөждан булу икеле.

Юхалау да ялау төшемле,
Яшәве тик шуның өченме?!

# ИКЕ ЙӨЗ ӨЧЕНЧЕ КӨН

*Эт белән йокларга ятсаң,*
*борча тешләп уятыр.*
***Туфан Миңнуллин***

Кемнәр белән эчәр, ашарыңны,
Кемнәр белән йоклап ятарыңны
Бел син.
Юкса бетләп чыгарсың,
Борча тешләп эттәй уларсың.

Аермассың агын, карасын,
Бер каралган ничек агарсын?

# ИКЕ ЙӨЗ ДҮРТЕНЧЕ КӨН

*Үз-үзеңне күтәреп караганың бармы?*
***Туфан Миңнуллин***

Үз-үзеңне күтәрүе авыр,
Гомер буе күпме җыелган.
Маташмыйм да,
Дөнья мәшәкате
Болай да бит инде муеннан.

Ә шулай да кызык:
Мин авырмы икән;
Үз-үземне күтәрә
Алырмын микән?

# ИКЕ ЙӨЗ БИШЕНЧЕ КӨН

*Дөнья- аучы, без -бүре.*
***Туфан Миңнуллин***

Бар кеше дә бүре була алмас
Бүре сыман дөнья каршында.
Бүре генә түгел, аюлар да,
Куян, төлке, балык һәм кошлар да,
Дуңгызлар да, сыер һәм атлар да,
Этләр, кош-кортлар да бар монда.

# ИКЕ ЙӨЗ АЛТЫНЧЫ КӨН

*Байның хәерчесе буламы?*
***Туфан Миңнуллин***

Байларның бар бае, хәерчесе,
Була баеганы, бөлгәне.
Бай да- адәм, үксеп елаган бар,
Була кычкырыплар көлгәне.

Миллиарды булса, маллы ул,
Юкмы- бер хәерче, ярлы ул.

Кайберәүләр байлар миллионсыз да;
Акчалы, тик ярлы - имансызлар.

# ИКЕ ЙӨЗ ҖИДЕНЧЕ КӨН

*Чебен ачык авызга керә.*
***Туфан Миңнуллин***

Авызыңны ачма, чебен керер,
Эзли чебен ачык авызны.
Ифлас аяк белән килеп керер,
Ничек туктатырсың явызны?

Ачык авызлардан чыккан сүзләр
Эт тә җыймас сүзләр була ул,
Нәҗес керә, нәҗес килеп чыга.
Авызына әсир була ул.

# ИКЕ ЙӨЗ СИГЕЗЕНЧЕ КӨН

*Тычканны эләктергәнче мәче дә*
*үлгәнгә сабышып ята.*
***Туфан Миңнуллин***

Хәтта мәчеләр дә бигрәк оста
Кулланалар хәрби хәйләне.
Ә кешенең мең кат артык булыр
Шундый хәйләләрне белгәне.

Сак булырга кирәк һаман да,
Хәйләкәрләр күп бу заманда.

## ИКЕ ЙӨЗ ТУГЫЗЫНЧЫ КӨН

*Түрдәге мәчене кусаң,*
*ишек төбендәгесе*
*үзе чыгып шыла.*
***Туфан Миңнуллин***

Кызым, сиңа әйтәм, диләр,
Киленем, син тыңла, дип.
Мәче аңлый:
Икенчесе
Шундук чыгып шыла бит.

Мәчеләр дә аңлаганны,
Кеше булып, аңламамы?!

# ИКЕ ЙӨЗ УНЫНЧЫ КӨН

*Түрәләргә ярарга тырышуның*
*иң кыен ягы- алар сөйләгән*
*тозсыз мәзәкне хуплап көлү.*
***Туфан Миңнуллин***

Тозсыз мәзәк өчен дә ул
Мәҗбүр була көлергә.
Көлмәс иде, түрә сөйли,
Кирәк шуны белергә.

Көлми кара, нишләтер?
Күрмәгәнең күрсәтер!

# ИКЕ ЙӨЗ УНБЕРЕНЧЕ КӨН

*Байлар икмәген ашаудан саклан.*
***Туфан Миңнуллин***

Читнең икмәген ашама,
Бигрәк тә, байларныкын.
Меӊ мәртәбә арттырып ул
Чыгарыр синнән хакын.

Байның икмәге кыйбат,
Бирсә дә сине сыйлап.

## ИКЕ ЙӨЗ УНИКЕНЧЕ КӨН

*Кәҗә койрыгы кебек кыска гомерне*
*сыер шикелле күшәп уздырма.*
***Туфан Миңнуллин***

Мин яшәмим ашар өчен,
Ашыйм тик яшәр өчен,-
Дигән, ди, акыл иясе.
Килә шуңа иярәсе.

Кыска гына гомердә дә
Байтак ыгы-зыгылар.
Күшәп кенә үтсә гомер,
Аның ни кызыгы бар?

# ИКЕ ЙӨЗ УНӨЧЕНЧЕ КӨН

*Кәкре аяклы челән чапырыш булмый.*
***Туфан Миңнуллин***

Һәр нәрсәдә үзгә табигать,
Һәр җанварда үзгә хакыйкать.
Кәкре аяк җайлы челәнгә:
Чапыр-чопыр йөрмәс,
Бер бака да сизмәс
Сазда челән ауда йөргәндә.

Чапыр-чопыр, төз аяклы йөргәндә,
Кайда, ничек атлауны белмәгәндә.

# ИКЕ ЙӨЗ УНДҮРТЕНЧЕ КӨН

*Мәхәббәт ул мәче шикелле-башыннан*
*сыйпасаң гына мыраулый.*
***Туфан Миңнуллин***

Сыйпаганда гына мыраулаcа,
Күрсәң, күрмәсәң дә мәче бит ул.
Сыйпамасаң да сырыла торган
Ярың
Мәче түгел, кеше бит ул.

Сыйпамаганда да сизелә
Мәхәббәте,
Баксаң йөзенә.

# ИКЕ ЙӨЗ УНБИШЕНЧЕ КӨН

*Татар китабын укымаган өчен*
*ишәк белән сарыкны*
*сүгеп булмый ич инде.*
***Туфан Миңнуллин***

Әлбәттә, бик яхшы булыр,
Бар да
Китап укый-укый үссәләр,
Башка китаплары белән бергә
Татар китабына җитсәләр.

Күп төрле шул бәндә: сарык, эт тә,
Ишәк, дуңгызы да бар аның.
Болар китап тәмен беләмени,
Ник укысын татар китабын.

## ИКЕ ЙӨЗ УНАЛТЫНЧЫ КӨН

*Әй, бозау, син кем бәрәне?*
***Туфан Миңнуллин***

Бозау яки бәрән сыйфатында
Яшәп буламыни бу җирдә?
Сыер яки сарык булганда да
Кеше түгелсең бу гомердә.

Сыер, сарык түгел, кеше бул,
Кирәк шөгылеңне, эшең бел!

# ИКЕ ЙӨЗ УНҖИДЕНЧЕ КӨН

*Кәҗә буласың килсә,*
*сарыклардан алда йөр.*
***Туфан Миңнуллин***

Кеше көтүендә кәҗә булыйм дисәң,
Сарык кебекләрдән алда чап.
Шунда көтү башы син булырсың,
Бөтенесе арттан чабачак.

Кәҗә булуның бер яхшы ягы-
Бар сарыклар артта, син алдагы!

## ИКЕ ЙӨЗ УНСИГЕЗЕНЧЕ КӨН

*Арысланнарга патша итеп этне куйсаң,
арысланнар да өрә башлый.*

***Туфан Миңнуллин***

Этне арысланга патша итмә,
Арысланнар үзе патшалар.
Һәр арыслан эттәй өреп йөрсә,
Бөтенесе үләр ач алар.

Этләр берни аулый белми хәзер,
Этләр өчен өйдә ризык әзер.
Арыслан этләнгән дөньяның
Канун, тәртибе дә юк аның.

# ИКЕ ЙӨЗ УНТУГЫЗЫНЧЫ КӨН

*Балык, сарык, халык-нинди шәп рифма!*
***Туфан Миңнуллин***

Балыкка, сарыкка халыкны
Тиң куя югары түрәләр.
Бер ахмак сарыкка, балыкка
Охшатып түрәне күрәләр
Түбәннәр,
Нәкъ шуңа көләләр.

Ике як та туган бер халыктан,
Ахмаклыклар бигрәк охшап чыккан.

# ИКЕ ЙӨЗ ЕГЕРМЕНЧЕ КӨН

*Чебенне нигә чебен дип атадылар икән?*
***Туфан Миңнуллин***

Чебен булган өчен шул исемен
Алган чебен безнең халыктан.
Язын, җәен, көзен бөтен халык
Бетмәс шул чебеннән ялыккан.

Җәйләрне дә кышлар итәр идем
Бераз чебеннән ял итәргә.
Ләкин чебен җаен табар сыман
Шундук очып килеп җитәргә.

# ИКЕ ЙӨЗ ЕГЕРМЕ БЕРЕНЧЕ КӨН

*Чебен чебен инде ул-*
*балга да,*
*тизәккә дә куна.*
***Туфан Миңнуллин***

Чебен генә балны тизәкләрдән
Аералмый килеп куна ул.
Адәми зат үз бәясен белсен,
Кунсын урын сайлап кына ул.

Бичара бит шуны аңламаса,
Тизәктән соң балга куна калса.

# ИКЕ ЙӨЗ ЕГЕРМЕ ИКЕНЧЕ КӨН

*Бүре туенган җирдә төлкеләр дә ач булмый.*
***Туфан Миңнуллин***

Туярлык туй бүре урманында,
Бер як- шатлык, бер як -кайгыдыр.
Туйда төлке тамак ялгап алса,
Туйга калҗа булган кайсыдыр.

Зур ерткычлар ашап туйганда
Иярченгә дә туй урманда.

# ИКЕ ЙӨЗ ЕГЕРМЕ ӨЧЕНЧЕ КӨН

*Бүре картайса,*
*эт көлкесенә кала.*
***Туфан Миңнуллин***

Ходай гомер бирсә, картаясың,
Хәлләр мөшкелләнә тагын да.
Карт бүрегә охшап калмас өчен
Бүре булма син яшь чагыңда.

Картларга бул терәк, көлмә син,
Бел үзеңә картлык киләсен.

# ИКЕ ЙӨЗ ЕГЕРМЕ ДҮРТЕНЧЕ КӨН

*Карт кешенең гәүдәсе-*
*сорау билгесенең өлгесе.*
***Туфан Миңнуллин***

Минем гәүдәмме бу, түгелме,
Әллә сорау өчен билгеме?
Мондый түгел иде бит гәүдәм,
Бик үзгәрә икән карт бәндәң.

Гәүдәм гүя сорау билгесе,
Минмени бу адәм күлкесе!

# ИКЕ ЙӨЗ ЕГЕРМЕ БИШЕНЧЕ КӨН

*Кашыңны сызгансың икән,*
*кершән белән иннек ягарга да онытма.*
***Туфан Миңнуллин***

Бит-йөземне яшәртәмен әле, дисәң,
Кирәк каләме дә, иннек белән кершән.
Кулланмасаң кирәкнең хет берсен генә,
Хур буласың, сине берәү күрсен генә.

Ни башласаң, шуны тулы итеп эшлә,
Ни файда бар ярты-йорты кылган эштә.

# ИКЕ ЙӨЗ ЕГЕРМЕ АЛТЫНЧЫ КӨН

*Этнең бете дә эт.*
***Туфан Миңнуллин***

Үзе бер эт булса, бете дә эт,
Хуҗасы чит күрсә, эте дә чит.
Сырылма син шундый бәндәләргә,
Башың, акылың да үзеңдә бит.

Эт белән эт булма, адәмсең-
Җир йөзендә Ходай бәндәсе!

# ИКЕ ЙӨЗ ЕГЕРМЕ ҖИДЕНЧЕ КӨН

*Эше юк эт оят җирен ялый.*
***Туфан Миңнуллин***

Йөрмә әле эткә печән чабып,
Адәм булсаң, башла бер эш табып.

Яшәүмени, тырай тибеп кайтсаң,
Кешеме син, эттәй ялап ятсаң.

# ИКЕ ЙӨЗ ЕГЕРМЕ СИГЕЗЕНЧЕ КӨН

*Хәтта тынычлык күгәрчене дә кәкәй итә.*
***Туфан Миңнуллин***

Бөтен яктан камил, кимчелексез-
Яшьлегеңдә сөйгән яр, диләр.
Дөрес түгелдер ул.
Кимчелекләр
Хәтта фәрештәдә бар, диләр.

Һәркемдә дә бардыр кимчелек,
Шуны аңлап ал син иң элек.

# ИКЕ ЙӨЗ ЕГЕРМЕ ТУГЫЗЫНЧЫ КӨН

*Колорадо коңгызы да үзен*
*чибәр дип уйлыйдыр инде.*
***Туфан Миңнуллин***

Коңгыз өчен коңгыз чибәр була,
Күгәрченгә чибәр күгәрчен.
Дөнья шундый.
Мәхәббәтең төшсә,
Чибәр диеп шайтан сөярсең.

Сиңа чибәр күңелеңнең кәгъбәсе,
Ә миңа ул- гади, Ходай бәндәсе.

Керпе өчен сөйгән яры йоп-йомшак,
Гиенага сөйгән яры-нәкъ курчак.

# ИКЕ ЙӨЗ УТЫЗЫНЧЫ КӨН

*Диңгызга рәхәт -өстәниләр*
*эшләнгәнен күрми.*
***Туфан Миңнуллин***

Бәлки шулай җиңелрәктер тормышыңда:
Югарыда ниләр бардыр, кызыксынма.

Шуңа якын түгел микән үзебез дә,
Өстәгеләр ниләр кыла, белмибез дә.

## ИКЕ ЙӨЗ УТЫЗ БЕРЕНЧЕ КӨН

*Сарык аңгыра булмаса,*
*кәҗә акылының*
*бәясе төшәр иде.*
***Туфан Миңнуллин***

Ярым дивана да -даһи
Җыен ахмак каршында.
Акыллылар барда,
Ахмак
Йөрмәс көтү башында.

Түрәләрем ахмак, дисең,
Ярый.
Кемгә үпкәлисең?

## ИКЕ ЙӨЗ УТЫЗ ИКЕНЧЕ КӨН

*Кияүгә чыкканда яшең кызларныкы,*
*акылың әбиләрнеке булсын.*
***Туфан Миңнуллин***

Һәрбер эшне акыл белән башла,
Үкенергә туры килмәсен.
Яңа тормыш башлап җибәргәндә
Алдыңда тот акыл чишмәсен.

Яшь булсаң да, өлкән яшьтәгечә
Булсын синең акыл, зиһенең.
Гомер сөрү — уен-көлке түгел,
Бөтен киләчәгең бит синең.

## ИКЕ ЙӨЗ УТЫЗ ӨЧЕНЧЕ КӨН

*Дөньяның ни икәнен беләсең килсә,*
*явыз хатынга өйлән.*

***Туфан Миңнуллин***

Кәләшеңнең холыкларын
Белми торып өйләнмә.
Өйләнгәч, бер явыз булса,
Зарланма да, сөйләнмә.

Гаеп синдә.
Явыз хатын
Сине әллә нишләтер.
Дөньяның гел артын ачып,
Күрмәгәнең күрсәтер.

## ИКЕ ЙӨЗ УТЫЗ ДҮРТЕНЧЕ КӨН

*Күселәр дә күп үрчи,*
*ләкин үзләрен*
*бөек дип атамыйлар.*
***Туфан Миңнуллин***

Күп үрчегән халык бөек диеп
Нигә, кемнәр әйткән икән соң?
Аз үрчегән халык бөеклеккә
Берчак менеп җитәр микән соң?

Нормалары бармы бөеклекнең,
Бөек халык саны күпмелекнең?

# ИКЕ ЙӨЗ УТЫЗ БИШЕНЧЕ КӨН

*33 ел эшләмичә мич башында яткан*
*Илья Муромецны кем эшләп ашаткан?*
***Туфан Миңнуллин***

Бер дә ашамаган микән,
Изге бәндә булгач ул;
Ашый башлады микәнни
Утыз өче тулгач ул?

Әллә бөтен авыл халкы
Аңа эшләде микән,
Бер баһадир булыр бу, дип,
Ашап-эчмәде микән?

Ашамый да эчми торса,
Ничек яшәгән халык?...
Юк җавап бер сорауга да,
Аптырарсың, таң калып.

# ИКЕ ЙӨЗ УТЫЗ АЛТЫНЧЫ КӨН

*Ана фил койрыгына кунган*
*ата черкине азгынлыкта гаепләр идегезме?*

***Туфан Миңнуллин***

Гаепләрбез, әлбәт, гаепләрбез,
Без бик гаепләргә өйрәнгән.
Тыштан күренгәнгә гаеп таксаң,
Беләсе юк эшне тирәннән.

Гаепләгәч гаепсезне, киттең,
Җулдан килсә, үзе аклансын.
Акланмаса, синең ни эшең бар,
Аңа азгын дигән дан калсын.
Булдың әхлак өчен көрәшүче,
Исемең пакь, үзең аппаксың.

# ИКЕ ЙӨЗ УТЫЗ ҖИДЕНЧЕ КӨН

*Ак калфак белән ак халат кисә,*
*бүредән дә шәфкать көтәм.*
***Туфан Миңнуллин***

Ак калфаклы, ак халатлы
Бүреләрдән шәфкать көтәм.
Бүреләрнең игелеге
Тияр диеп өмет итәм.

Белеп торам, бүреләрдән
Шәфкать көтү-диваналык.
Ләкин һаман бүреләрдән
Шәфкать көтә безнең халык.

# ИКЕ ЙӨЗ УТЫЗ СИГЕЗЕНЧЕ КӨН

*Биле сынган арысланның*
*утыз ике теше бар.*
***Туфан Миңнуллин***

Биле сынган моның диеп,
Арысланга якын барма.
Тешләр аның һаман үткер,
Аңа азык булып калма.

Гарип булсын, ләкин җанвар,
Дуамал баш, дошман, исәр.
Тиздән үләр,
Ләкин башта
Синең гомереңне кисәр.

Кешеләр дә җанвар сыман,
Теш бар, гәрчә биле сынган.

## ИКЕ ЙӨЗ УТЫЗ ТУГЫЗЫНЧЫ КӨН

*Иреңне сөяркәсеннән биздерәсең килсә,*
*аның сөяркәсе кебек булырга тырыш.*
***Туфан Миңнуллин***

Ирнең сөяркәсен күреп өйрән,
Нишләреңне шунда белерсең.
Ирем шуннан бизсен әле, дисәң,
Шул сөяркә кебек йөрерсең.

Шулай бизәнерсең, төзәнерсең,
Шулай сөеп, шулай түзәлерсең.

# ИКЕ ЙӨЗ КЫРЫГЫНЧЫ КӨН

*Авызына микрофон капса,*
*балык та җырлый хәзер.*
***Туфан Миңнуллин***

Җырламаган татар юктыр,
Җырсыз татар буламы?
Җырга аның сагышы да,
Моңнары да туладыр.

Хәзер инде дөнья тулган
Микрофонлы җырчылар.
Моңнары юк.
Әйтегезче,
Кайда моңлы җырчы бар?

# ИКЕ ЙӨЗ КЫРЫК БЕРЕНЧЕ КӨН

*Очарга омтылган йорт казларының*
*канат очларын кисәләр.*

***Туфан Миңнуллин***

Азат күккә очып китмәсен дип,
Кисәләр йорт казы канатын.
Үлмәсен дә, очалмасын өчен
Кисә хуҗа, белеп чамасын.

Кешеләрнең, хәтта милләтләрнең
Канатлары шулай киселә...
Үз канатым киселгәндәй,
Төшкәч
Милләт язмышлары исемә.

# ИКЕ ЙӨЗ КЫРЫК ИКЕНЧЕ КӨН

*Нишләтергә бу үгезне- алдына чыксам,*
*сөзә, артыннан кусам, тибә.*
***Туфан Миңнуллин***

Ну маладис икән шушы үгез,
Үз ирегe белән тормакчы.
Беркемгә дә буйсынмыйча гына
Үзенә хас тормыш кормакчы.

Маладис та, белми генә мескен,
Бер төшкәчтен хуҗа кулына,
Ирексез бар хайван.
Аркан бәйләп,
Җибәрмәсләр теләр юлыңа.

## ИКЕ ЙӨЗ КЫРЫК ӨЧЕНЧЕ КӨН

*Иң кутшы әтәч тә йомыркадан чыкканда чебеш була.*

***Туфан Миңнуллин***

Мактанма син әтәчлегең белән,
Күптән түгел чебеш идең бит.
Аягыңда басып торалмаслык
Мескен генә, юеш идең бит.

Һәрбер җан иясе бу дөньяга
Шәрә мескен булып килә бит.
Нигә масаясың?
Бу дөньядан
Киткәндә дә шулай китә бит.

# ИКЕ ЙӨЗ КЫРЫК ДҮРТЕНЧЕ КӨН

*Ничек кәҗә булырга икәнен*
*сарыклар өйрәтмәсен иде.*
***Туфан Миңнуллин***

Кәҗә эшен үзләштереп булмас,
Өйрәтүчеләр- гел сарыклар.
Шактый симезләре байтак кына,
Кайберләре бераз арыклар.

Тик барыбер сарык.
Бүтән эшне
Аңламый да, сарык башы бит.
Ләкин өйрәтергә килә, бу эш
Абруйлы да, чиста, яхшы бит.

# ИКЕ ЙӨЗ КЫРЫК БИШЕНЧЕ КӨН

*Кандаланы борча,*
*борчаны бет ашый торган заман.*
***Туфан Миңнуллин***

Берсен берсе ашый торган
Җитте бугай ахырзаман.
Туган белми туганнарын,
Кыргыйланды бар да тәмам.

Кешеләр дә әллә нинди-
Борча, кандала, бетмени.

# ИКЕ ЙӨЗ КЫРЫК АЛТЫНЧЫ КӨН

*Ояты булмасын өчен*
*Ходай сарыкка да койрык биргән.*
***Туфан Миңнуллин***

Ахмак сарыкка да койрык
Биргән Ходай.
Хәтта син дә ояла бел,
Дигән бугай.

Сарык күк тә оялмаса,
Кешемени?
Оятсызлык-ул кешенең
Эшемени?

# ИКЕ ЙӨЗ КЫРЫК ҖИДЕНЧЕ КӨН

*Яманлык яхшылыкка караганда әрсезрәк,*
*шуңа күрә еш кына яхшылык*
*яманлык алдында каушап кала.*
***Туфан Миңнуллин***

Яманлыклар әрсез, яхшылык – юк,
Әрсезлеккә һәрчак юл ачык.
Яхшылыклар каушап калмас өчен
Каршы ал син җәеп колачың.

Яхшылыкка кирәк баш ияргә,
Рәхим ит, хуш килдең, дияргә.

# ИКЕ ЙӨЗ КЫРЫК СИГЕЗЕНЧЕ КӨН

*Кыяр түтәлеңне саклый алмаганга*
*тавык гаепле түгел.*

***Туфан Миңнуллин***

Ни гаебе бар шул тавыкның,
Кыяр түтәленме туздырган?
Син кисәтү элеп куйдыңмы соң
Тавык телләрендә язылган?

Юкмы, син тавыкны тиргәмә,
Язма таләпне ул күрмәгән.

# ИКЕ ЙӨЗ КЫРЫК ТУГЫЗЫНЧЫ КӨН

*Мескен кешенең нәфрәтеннән саклан.*
***Туфан Миңнуллин***

Мескен бәндә юлын кисмә син,
Аннан нәфрәт, каргыш төшмәсен.
Аның каргышы да көчлерәк,
Бахырны рәнҗетү ник кирәк?

Кызгана бел мескеннәрне,
Мескен хәлдә йөргәннәрне.

# ИКЕ ЙӨЗ ИЛЛЕНЧЕ КӨН

*Шәраблы чәркәңә күз яшең*
*тама икән, эчмә.*
***Туфан Миңнуллин***

Шәрабыма тамса күз яшем,
Эчмим, читкә куям чәркәне.
Күз яшьләре тозлап ачыта
Шәраб дигән тәмле нәрсәне.

Чәркәгә күз яшем таммасын,
Яшьле тәкъдир миңа язмасын.
Татлы булсын гомер шәрабым,
Ялварам тик сиңа, и Раббым!

## ИКЕ ЙӨЗ ИЛЛЕ БЕРЕНЧЕ КӨН

*Аракы эчү-зур гөнаһ.*
*Әгәр дә инде шайтан котыртып,*
*артыгын эчеп егылсаң,*
*йөзеңне кыйблага борып аварга тырыш,*
*гөнаһысы азрак булыр.*

***Туфан Миңнуллин***

Әгәр дә исереп егылсаң,
Йөзеңне кыйблага борып ят.
Гөнаһың бер Алла кичерер,
Кешедән аз гына бар оят.

Исергәч, бар акчаң урланса,
Аңа да бик исең китмәсен.
«Хәергә булсын»,- дип әйтерсең,
Сәдака биргәндәй итәсең.

Күп итеп аракы эчүнең
Файдасы бар икән ләбаса.
Изге дин бик авыр тоелса,
Сәрхушлек кешене тиз баса.

# ИКЕ ЙӨЗ ИЛЛЕ ИКЕНЧЕ КӨН

*Дошманыңны хөрмәт ит, синең*
*чын бәяңне ул гына белә.*
***Туфан Миңнуллин***

Дошманың да белә бәяңне,
Аерган хатының да.
Белүчеләр тагын бардыр ул
Үткән гомер юлыңда.

Зур хөрмәт күрсәт син аларга,
Бу сереӊ таралмасын.
Бәяң аз икәне беленсә,
Күпкә сатылалмассың.

# ИКЕ ЙӨЗ ИЛЛЕ ӨЧЕНЧЕ КӨН

*Күзләр серен саклар өчен*
*сиксән сигез керфек бар.*
***Туфан Миңнуллин***

Күз серләрен күпме керфек саклый,
Күзнең серләре тирән.
Бөтен серләрең бер тел очында,
Телең тыярга өйрән.

Ике күзгә сиксән сигез керфек,
Телең бирәү, яса шуңа киртек.

# ИКЕ ЙӨЗ ИЛЛЕ ДҮРТЕНЧЕ КӨН

*Ленинга һөҗүм башланды.*
*Тора-бара аның милләтен*
*татар итәчәкләр.*
***Туфан Миңнуллин***

«Зур агай» ның үскән балалары
Аптыраган, белми нишләргә:
Берәр файдалы эш башларгамы,
Әллә дошман-мазар эзләргә.

Дошман эзләү болай рәхәт мәгәр,
Эшнең мәшәкате күп була.
Күп вакытта аның азагы да
Бер файдасыз нәрсә, чүп була.

Дошман табу җиңел, ерак түгел,
Янда гына бар ич татарлар.
Ленин татар булсын, Сталин да,
Илдә бөтен бәла- татарда.

Шундый бик шәп бер уй килде бугай
Иң хөрмәтле шул «зур агай»га.
Күптән калган гадәт бар бит-
Сылтау
Бар чатакны мәрхүм Мамайга.

# ИКЕ ЙӨЗ ИЛЛЕ БИШЕНЧЕ КӨН

*Йоклаганда гырласаң да, үзебезчә,*
*татарча итеп гырла.*

***Туфан Миңнуллин***

Гырла, гырла дип әйтәсең,
Ничек гырлыйм икән соң?
Гырлауларым татарчамы,
Ничек аңлыйм икән соң?

Гырлавымны ишетмим дә,
Хатын гына ишетә.
Карт пәридәй гырлыйсың, дип,
Тетә мине, и тетә.

Татарчасы нинди аның,
Мин дә өйрәнер идем;
Хатын белән аралар да
Бераз көйләнер иде.

## ИКЕ ЙӨЗ ИЛЛЕ АЛТЫНЧЫ КӨН

*Аңла: гашыйк булу җилле көнне*
*далада учак кабызу белән бер.*
***Туфан Миңнуллин***

Яшь чакларда гашыйк булу җиңел,
Кабынасың, дөрләп янасың.
Учагыңа бензин сипкәнмени,
Шушы ут эчендә каласың.

Кабынулар бик тиз,
Уттан
Бик хәвефле матдә буласың.
Олыгайгач шактый сүреләсең,
Акрын-акрын гына тынасың.

Картайганда -дала вазгыяте,
Шырпың да юк, бик аз утын да.
Кабынып та, дөрләп китүләр юк,
Янар-янмас кына утың да.

# ИКЕ ЙӨЗ ИЛЛЕ ҖИДЕНЧЕ КӨН

*Утка су язмышы теләмә.*
***Туфан Миңнуллин***

Һәрнәрсәнең үз язмышы,
Кемгә яну, кемгә агудыр.
Нәрсәләргә нәрсә кирәк,
Иң мөһиме шуны табудыр.

Кешеләр дә төрле: ут та,
Су да, тагын бүтәннәре бар.
Үзгә бүген халәте дә,
Артта калган үткәннәре бар.

Янмас кешене көйрәтеп,
Харап итә күрмә син.
Янардайга утыңны бир,
Гөрләп, дөрләп, сүнмәсен!

## ИКЕ ЙӨЗ ИЛЛЕ СИГЕЗЕНЧЕ КӨН

*Җыйган байлыгыңнан оялмаска язсын.*
***Туфан Миңнуллин***

Бәлкем, байтак туплангандыр
Төрле байлык кулларыңда.
Бөтенесен намус белән
Җыйдың микән юлларыңда?

Малларыңда берәүләрнең
Күз яшьләре түгелгәнме;
Кешеләрне рәнҗеткәнең,
Яман серең күмелгәнме?

Ходай күрсәтмәсен сиңа
Оялырга үз-үзеңнән.
Язсын бөтен гомереңне
Үткәрергә вөҗдан белән.

# ИКЕ ЙӨЗ ИЛЛЕ ТУГЫЗЫНЧЫ КӨН

*Мактанма яшьлегең белән,*
*бездән калган яшьлек ул.*
***Туфан Миңнуллин***

Һичшиксез, бик гүзәл яшьлегең,
Сиңа кадәр мин дә яшь идем.
Җирдә тәүге түгел яшь чагың,
Минем дә бит шундый яшьлегем.

Безгә кадәр күпме буыннар
Янган шулай яшьлек утында.
Бездән соң да янар яшь буын,
Былбыл булып сайрар, чутылдап.

## ИКЕ ЙӨЗ АЛТМЫШЫНЧЫ КӨН

*Сине бәхетле итәр өчен*
*үземнән көләргә рөхсәт итәм.*
***Туфан Миңнуллин***

Әйдә, көл, көләсең килсә,
Бик теләсәң, көл миннән.
Бәхетле бул, рөхсәт итәм
Көләм, дисәң, үземнән.

Җылама гына, җылама,
Сөйкемле көлүләрең.
Көлсәң, җиңеләя дөнья
Һәм гомер сөрүләрең.

# ИКЕ ЙӨЗ АЛТМЫШ БЕРЕНЧЕ КӨН

*Бәхетле хатын-кыз белән сөйләшү-
дөнья рәхәте.*

***Туфан Миңнуллин***

Чын бәхетле булса шул хатын-кыз,
Рәхәт аның белән сөйләшү.
Бер сөйләшү түгел, аралашу,
Аны хөрмәт итеп серләшү.

Ә шул хатын үз хәләлең булса,
Гомер сөрү- дөнья рәхәте.
Тик андыйлар бик еш булмый, диләр,
Сирәк, диләр, ир-ат бәхете.

# ИКЕ ЙӨЗ АЛТМЫШ ИКЕНЧЕ КӨН

*Ниһаять, әкиятләр чынга әйләнде.*
*Җен-пәриләре дә үзебез.*

***Туфан Миңнуллин***

Әкиятне шушы чынбарлыкка
Әйләндердек бугай инде без.
Һәркемгә дә бәхет табылмады,
Җен-пәриләр булдык үзебез.

Диванадай чиксез шатланабыз,
Гамәленә ашты хыяллар!
Җеннәр-пәриләрне уздык инде,
Тагын кемдә нинди хыял бар?

## ИКЕ ЙӨЗ АЛТМЫШ ӨЧЕНЧЕ КӨН

*Парламент утырышлары билеты*
*биш ел элек сатылып беткән*
*спектакльләр ул.*

***Туфан Миңнуллин***

Парламент ул, баксаң, бер театр,
Артист, тамашачы-тиңнәр бөтенесе.
Менә хәзер йоклый тамашачы залда,
Ә сәхнәдә кәмит куя бер-икесе.

Кайберәүләр залда уйный, көлешәләр,
Бер-берсеннән яңа хәбәр белешәләр.

Биш ел үтә тыныч кына менә шулай,
Вәгъдә бирер вакыт тагын җитә бугай.

Барысы да чыгар халык алларына,
«Мин депутат булыйм», диеп ялварырга.

# ИКЕ ЙӨЗ АЛТМЫШ ДҮРТЕНЧЕ КӨН

*Син алдадың, мин алдадым-*
*барыбер тәһарәт алмадым.*
***Туфан Миңнуллин***

Бик үзгәрде бугай заманалар,
Тәһарәтсез үтә гомерләр.
Бу бәндәләр көн-төн алдашмаса,
Яши алыр сыман түгелләр.

Ике як та булгач алдакчылар,
Нигә кирәк, дисең, тәһарәт.
Мөселман да түгел бит мондыйлар,
Юньле бәндә түгел, хәшәрәт.

## ИКЕ ЙӨЗ АЛТМЫШ БИШЕНЧЕ КӨН

*Юк чагында бүлешә идек,*
*булгачтын бүлешәсе килми.*
***Туфан Миңнуллин***

Хәерчеләр соңгы кисәк белән
Бүлешергә әзер күп вакыт.
Байлар булса, кышын карларын да
Бирер иде сиңа тик сатып.

Татар бае нишләп бозылгандыр,
Андый булмаган бит электән.
Кая киткән хәзер ярдәмчел дә,
Җәлләүче да татар,
Ник киткән?

Дөнья үзгәрдеме, әхлак микән,
Элеккеге әхлак кайтмас микән?

# ИКЕ ЙӨЗ АЛТМЫШ АЛТЫНЧЫ КӨН

*Ялкауның ялы бетми.*
***Туфан Миңнуллин***

Бетмәс инде бу ялкауның ял итүе,
Вөжданының булмас үсеп җитүе.
Тик бер генә чара аны кеше итәргә-
Карурманда ялгыз ташлап китәргә.

Тотынып бер эшкә, исән калса,
Ялкаулыгын шулай җиңә алса.

# ИКЕ ЙӨЗ АЛТМЫШ ҖИДЕНЧЕ КӨН

*Явызлык чәчелгән җиргә*
*яңгыр кан булып ява.*
***Туфан Миңнуллин***

И адәми зат!
Чәчәсең
Явызлыкны капчык тутырып.
Игелегең янчык белән генә,
Ул да бөртекләп, кул кушырып.

Яңгыр булып ява җиргә каннар,
Беләсеңме,
Тагын күпме түгәр кан бар?

## ИКЕ ЙӨЗ АЛТМЫШ СИГЕЗЕНЧЕ КӨН

*Надан түрәнең иң әче дошманы-*
*укымышлы хезмәткәр.*
***Туфан Миңнуллин***

Ничек инде надан түрә
Яратсын белемлене.
Курка:
Тартып алмасмы, дип,
Бу минем телемемне.

Этләр дә шул: көчле килсә
Көчсез эткә,
Кимереп
Яткан сөяген бичара
Куя тизрәк яшереп.

# ИКЕ ЙӨЗ АЛТМЫШ ТУГЫЗЫНЧЫ КӨН

*Баганага яулык бәйләсәң,*
*ул да матур булып күренә.*
***Туфан Миңнуллин***

Яулык бәйләгәндә багана да
Татар кызларына охшап кала:
Зифа буйлы, тыйнак кына үзе,
Саф күңелле, чиста җанлы бала.

Сөймәгәнне дә ул сөйдерәдер,
Мәхәббәткә чорнап көйдерәдер
Утларында.
Татар кызын
Төшләремдә күрәм мин төнозын.

## ИКЕ ЙӨЗ ҖИТМЕШЕНЧЕ КӨН

*Кирәк икән-төрмәгә ябармын,*
*кирәк икән-башыңны чабармын,*
*әмма демократик шартларда*
*яшәргә өйрәтермен.*

***Туфан Миңнуллин***

Демократияне уйлаганда
Ялгышканнар элек грекләр.
Халык хакимлеге дигән алар,
Халык өчен булсын ирекләр.

Хәзер демократия дә башка,
Идарәләнүче икән ул.
Өстән генә идарәләп торгач,
Демократияме икән ул?

Я төрмәгә ябам, я баш чабам,
Дигәч, нәкъ безнеңчә инде ул...
Аңладыңмы инде,
Шушы илнрең
Демократиясе нинди ул?

# ИКЕ ЙӨЗ ҖИТМЕШ БЕРЕНЧЕ КӨН

*Әгәр кемдер җинаять кылган икән,*
*анда минем дә гаебем бар.*
***Туфан Миңнуллин***

Җинаятьче миннән сорамады,
Кылмышына рөхсәт алмады.
Аның өчен ник мин гаепле, ди,
Миңа хәтта таныш булмады.

Ул да, мин дә үзгә язмыш белән
Олы юлдан үтеп барабыз.
Аның юлы минем юлым түгел,
Шактый ерак безнең арабыз.

Ләкин ныклап, тирән уйлап баксаң,
Туфан сүзләрендә хаклык бар.
Бөтен кеше яши шул бер Җирдә,
Гомер охшаш: яшьлек, картлык бар.

Кемнең дә булса бер кылмышы
Кыймылдата минем язмышны.

# ИКЕ ЙӨЗ ҖИТМЕШ ИКЕНЧЕ КӨН

*Өч категорияле яшәү бар:*
*түбән белеп яшәү, яшисе килми яшәү,*
*нигә яшәгәнеңне белми яшәү.*

***Туфан Миңнуллин***

Тәмен белеп яшәү яхшы ла ул,
Әгәр тәмен тапсаң яшәүнең.
Яшәүнең дә тәме калмаганда
Бу дөньяда тору- яшәүме?
Яшисе дә килми, тәме дә юк-
Шулчак исән булу- яшәүме?

Белми икән нигә яшәгәнен,
Ул-файдасыз басу тигәнәге.

# ИКЕ ЙӨЗ ҖИТМЕШ ӨЧЕНЧЕ КӨН

*Бәхет өелеп килгәндә егылмасаң,*
*кайгы килгәндә аягүрә каласың.*
***Туфан Миңнуллин***

Өелеп килгәндә бәхет, аны тота белсәң,
Баскан чакта сине кайгы, аны йота белсәң,
Ир-егетсең.
Юкка-барга гына бирешмәссең, егылмассың;
Егылсаң да сер бирмәссең торып, хур булмассың.
Кош-бөркет син!

Олы бәхет килгәндә дә егылмасаң,
Егылмассың кайгыдан да син һичкайчан.

# ИКЕ ЙӨЗ ҖИТМЕШ ДҮРТЕНЧЕ КӨН

*Тауның башы бар, йөрәге бар микән?*
*Бардыр.*
*Вулканнар шул йөрәкнең ярсуыдыр.*
***Туфан Миңнуллин***

Тауларның да, мөмкин, җаны бардыр,
Тауларның бит бар үз язмышы.
Тууы да, бәлигъ булуы да,
Үзенә хас гомер узмышы.

Мөмкин, йөрәге дә бардыр аның,
Безнекедәй ярсый торгандыр.
Кешеләрнең вәхши гамәленә
Йөрәге дә әрни торгандыр.

# ИКЕ ЙӨЗ ҖИТМЕШ БИШЕНЧЕ КӨН

*Ялган яктыдан курка.*
***Туфан Миңнуллин***

Яктылыкта дөнья күңеллерәк,
Дөреслек гел чыга яктыга.
Яктылыктан курка һәрбер ялган,
Караңгыга кача сак кына.

Караңгыда байтак әшәкелек
Кыла качып-посып кына ул.
Чыгарыгыз тартып бу яктыга,
Якты җирдә тыйнак кына ул.

## ИКЕ ЙӨЗ ҖИТМЕШ АЛТЫНЧЫ КӨН

*Үзенең тилелеген белгән кеше*
*тиле түгел инде ул.*
***Туфан Миңнуллин***

Тиле бәндә тилелеген белми бит ул,
Тилелеген белсә, тиле булмый бит ул.

Кирәктер бар тиленәрне өйрәтергә,
Очрашканда: «Мин тиле», -диеп әйтергә.

Шулай итсәк, җирдә тиле калмас иде,
Даһилар да болай бик аз булмас иде.

# ИКЕ ЙӨЗ ҖИТМЕШ ҖИДЕНЧЕ КӨН

*Яхшы кеше булу җиңел түгел ул.*
***Туфан Миңнуллин***

Әлбәт, дөрес:
Яхшы кеше
Булу җиңел һөнәр түгел.
Бер яхшылык эшлим, дисәң,
Кире якка тарта күңел.

Бер яманлык эшләп куйсаң,
Анысы да җиңел түгел.
Үкенерсең иртәгәсен,
Үкенмәгән булсаң бүген.

Вөҗдан тыныч булсын, дисәң,
Яхшылык кыл кичен, иртән.
Гүзәл булыр гомерең дә,
Якты-алда күререң дә.

# ИКЕ ЙӨЗ ҖИТМЕШ СИГЕЗЕНЧЕ КӨН

*Хайванның кешегә әйләнгәнен күргәнем юк,*
*кешенең хайванга әверелгәнен күргәнем бар.*
***Туфан Миңнуллин***

Кешеләрне күбрәк белгән саен
Этләрне мин күбрәк яратам,
Дигән икән бер акыллы адәм
Замандашларына карата.

Кешедән дә яхшы булса хайван,
Кешегә ул инде әйләнгән.
Адәм бер хайванга әверелү
Менә шундый хәлгә бәйләнгән.

# ИКЕ ЙӨЗ ҖИТМЕШЕ ТУГЫЗЫНЧА КӨН

*Зарланырга яратучы кешеләр*
*үзләренең бәхетсезлегеннән тәм табалар.*
***Туфан Миңнуллин***

Бәхетсезлек сорап килми,
Хаста белән бер бит ул.
Мактанырлык нәрсә түгел,
Бер бик яман чир бит ул.

Чирне мактап, зарланмыйлар,
Зарланудан ни файда?
Тәм таптыңмы зарланудан,
Ә горурлыгың кайда?

Зарлана бу бичара, дип
Кешеләр көлә инде.
Көлке хәленә калганың
Бик күпләр белә инде.

# ИКЕ ЙӨЗ СИКСӘНЕНЧЕ КӨН

*Артист һөнәре профессия түгел-диагноз.*
***Туфан Миңнуллин***

Артистлар да төрле-төрле,
Бар халкының сөйгәннәре,
Бар «Монысы артист түгел»,
Диеп бәя биргәннәре.

Бүтән хезмәттә дә шулай,
Кемдер -оста, сокланырлык.
Кемдер айлар, еллар буе
Тырай тибә, таң калырлык.

Чынлап белгеч булса кеше,
Бу -диагноз, һөнәр түгел.
Шундый хезмәтчәннәр никтер
Азлар гына менә бүген.

# ИКЕ ЙӨЗ СИКСӘН БЕРЕНЧЕ КӨН

*Алтмыш елга бер ахмак та акыллы сүз әйтә.*
***Туфан Миңнуллин***

Кайчагында ахмакның да
Башы бераз яктыра, ди.
Никтер караңгылык бетеп,
Башында таң аттыра, ди.

Саклап кына торырга, ди,
Кирәк икән шул мизгелне.
Берәр акыллы сүз әйтсә,
Аңларсың, ди, син үзеңне.

# ИКЕ ЙӨЗ СИКСӘН ИКЕНЧЕ КӨН

*Таңның атмый калганы юк әле.*
***Туфан Миңнуллин***

Төшермәле күңелеңне,
Төннәр кап-кара, диеп;
Кара төндә япа-ялгыз,
Йөрәгем -яра, диеп.

Таң атмыйча калганы юк,
Бүген дә атар әле.
Кояш аз-маз күренгәч тә,
Кара төн качар әле.

Күтәр башың, сөрт яшеңне,
Якты көннәр бар әле.
Бәхетләр дә, шатлыклар да
Алда булырлар әле.

# ИКЕ ЙӨЗ СИКСӘН ӨЧЕНЧЕ КӨН

*Сине күрергә килгән кеше*
*үзен дә күрсәтергә килә.*
***Туфан Миңнуллин***

Кайберәүнең фәкать үзен генә
Күрсәтәсе килә мактанып.
Күрсәтерлек берние дә юк ул,
Кылган эшләре дә вак аның.

Теге-бу як, бар эшләре ачык,
Бик яулыйсы килә ышаныч.
Чыда, түз аңа да,
Кеше бит ул,
Үткән вакыт кына кызганыч.

# ИКЕ ЙӨЗ СИКСӘН ДҮРТЕНЧЕ КӨН

*Яшисең килсә-үләргә өйрән.*
***Туфан Миңнуллин***

Белмим инде, бәлки, кирәктер дә,
Өйрәнергә ничек үләргә.
Миңа калса, иң мөһиме җирдә
Өйрәнергә ничек яшәргә.

Яшәү серләре дә бихисап шул,
Өйрәнергә вакыт җитәрме?
Өйрәнеп беткәнне көтми генә,
Үлем моннан алып китәрме?

Ярый, вакыт җитсә, җитмәсә дә,
Өйрәнергә кирәк яшәргә.
Теге дөньяларга китсәм әгәр,
Өйрәтерләр анда нишләргә.

# ИКЕ ЙӨЗ СИКСӘН БИШЕНЧЕ КӨН

*Үләсе бар дип пошынма,*
*монда синең бер гаебең дә юк.*
***Туфан Миңнуллин***

Һәркемнең дә бар бит соңгы бер ноктасы-
Җирнең куенында мәңге йокласы.

Шушы хакыйкатьне бөтен халык белә,
Ләкин һаман яши ул җырлый- көлә.

Алда күпме калгандыр, Ходай белә,
Яшик әле калганын җырлый-көлә.

# ИКЕ ЙӨЗ СИКСӘН АЛТЫНЧЫ КӨН

*Бер-береңнең тәкереген ялау*
*үбешү дип атала.*
***Туфан Миңнуллин***

Үбешкәнең бармы өзелеп сөеп,
Син мәңгелек ярым минем, диеп?
Сөеп үбү- тәнгә сихәт кенә,
Күңелләргә чиксез ләззәт кенә.

Туймам инде сөйгәнемне үбеп,
Рәхмәт сиңа, җаным-бәгърем, диеп.
Башын минем иңнәремә салыр,
Иреннәре тәме миндә калыр.

## ИКЕ ЙӨЗ СИКСӘН ҖИДЕНЧЕ КӨН

*Хатын-кызның «И, тиле!»*
*дигән сүзеннән дә матур сүз юк.*
***Туфан Миңнуллин***

Хатын-кызның байтак матур сүзләре бар.
Ирне кол итәрлек гүзәл йөзләре бар.

Башкаеңны югалтырлык төннәре бар,
Үз балаңны кулга биргән көннәре бар.

Бар «И, тиле!» диеп сине сөйгәне дә,
Кыен чакта синең өчен көйгәне дә.

# ИКЕ ЙӨЗ СИКСӘН СИГЕЗЕНЧЕ КӨН

*Үзендә булмаганны сорама,*
*хатын-кыз бит ул.*
***Туфан Миңнуллин***

Җәфалама хатын-кызны, баш катырма,
Интектереп, үзендә юкны таптырма.
Кайдан алып бирсен сиңа булмаганны,
Ул тик бала таба белә, тумаганны.

Бәяли бел алтыннан да артык итеп-
Синең балаларга аның күкрәк сөтен.
Шушы фигыльләре белән кыйммәтле ул,
Хатын-кызга ягымлы да һиммәтле бул.

## ИКЕ ЙӨЗ СИКСӘН ТУГЫЗЫНЧЫ КӨН

*Хатын-кызның милләтен мин кайсы халыкка*
*бала табып бирүенә карап билгелим.*

***Туфан Миңнуллин***

Ни өчендер гүзәл татар кызы
Башка, чит милләткә пар була.
Үзенә бер лаек татар тапмый,
Сөеп, бүтәннәргә яр була.

Сөю, мәхәббәт-ул бөек тойгы,
Аңа каршы торыр көч тә юк.
Тик җимеше аның -уртак бала-
Татар булсын, дигән хис тә юк.

Күпме гасыр киң күңелле татар
Чит милләтнең канын яңарта.
Җирдә татарлар да яшәсенче,
Дигән фикер юкмы татарда?

Татар кызы читкә килен булгач,
Теле башка, көне читләрдә.
Милләтенең кызы түгел инде,
Менә шунда, татар, нишләргә?

# ИКЕ ЙӨЗ ТУКСАНЫНЧЫ КӨН

*Яныңда әниең булганда ата каз чепуха ул.*
***Туфан Миңнуллин***

Кыю малай бит мин, курыкмыйм да
Ата каздан,
Әнкәй янда булса.
Әнкәй зарур кешеләргә һәрчак-
Кырык яшьтә, хәтта алтмыш тулса.

Курыйкмыйм мин кайгыдан да, шатлыктан да
Әнкәй булса, өркемәм мин картлыктан да.

## ИКЕ ЙӨЗ ТУКСАН БЕРЕНЧЕ КӨН

*Егылмас өчен тотынып торырга*
*иң ышанычлысы-*
*әниләрнең күлмәк итәге.*

***Туфан Миңнуллин***

Сабый чакта ни кирәксә,
Әнкәемне чакырганмын.
Куркып калсам, әнкәемнең
Итәгенә тотынганмын.

Мин бүген дә сабый булып
Калдым бугай,
Тотынырга итәк эзлим
Һаман шулай.

# ИКЕ ЙӨЗ ТУКСАН ИКЕНЧЕ КӨН

*Сабагы чәнечкеле матур чәчәкне*
*татарлар шайтан таягы,*
*урыслар татарник ди.*
*Мәгънә уртаклыгы бар бит,*
*чурт вәҗми.*

***Туфан Миңнуллин***

Татар — шайтан инде урыс өчен,
Бөтен бәласе шул татардан:
«Иго» ясаган да урысларга,
Туктатып, бер җирдә катырган.

Шул татардан килгән эчкечелек,
Урыска «мат» кергән татардан.
Шуңа күрә алга китеп булмый,
Бөтен бәла менә шулардан.

Гел чәнчешеп тора,
Үз телен дә
Ташламый бит, шайтан таягы...
Тыныч яшәр иде мәгәр бу ил,
Кайтса «иго» теге, баягы.

# ИКЕ ЙӨЗ ТУКСАНЫН ӨЧЕНЧЕ КӨН

*Бүлешергә кирәктер: кышы-урысныкы,*
*бураны татарныкы булсын.*
***Туфан Миңнуллин***

Бик бүлешер идек тә бит менә,
Риза булмас урыс, чукынган.
Бөтен тарих урысныкы, ди бит,
Шуны нигезләргә тотынган.

Башкаларның мәдәнияте дә,
Җире, тарихы да юк икән.
Тамаклары урыс баскач кына,
Шуңа күрә генә тук икән.

Бар сүзенә риза булыр идем,
Тик бүлешик кенә, бүлешик.
Урыс — болай, без тегеләй китик,
Сирәк-мирәк кенә күрешик.

## ИКЕ ЙӨЗ ТУКСАН ДҮРТЕНЧЕ КӨН

*Куып тоту белән көтеп тору-*
*икесе дә газап.*

***Туфан Миңнуллин***

Тотар өчен йөгерүнең
Мин дә сизмим рәхәтен.
Тотып алгач кына тоям
Тотканымның ләззәтен.

Көтеп тору-бигрәк газап,
Көтмәс идем һичкайчан.
Көтеп көтекләр булганчы
Йоклар идем, ичмасам.
Кайчан киләсең, кайчан?

## ИКЕ ЙӨЗ ТУКСАН БИШЕНЧЕ КӨН

*Без бит күп халыкларның биюен биибез,*
*безнең көйләргә генә биюче юк.*

***Туфан Миңнуллин***

Башкаларның кубызына биегәнгә
Синең көең мәгънәсездәй күренгән дә.

Көйлә үз көеңне, күр үз биюеңне,
Шунда таныр читләр синең үз көеңне.

Башкаларның кубызына күп биедең,
Кайчан кайгыртырсың икән үз көегең?

## ИКЕ ЙӨЗ ТУКСАН АЛТЫНЧЫ КӨН

*Кайда гаделлек- миннән сорамыйча тудырдылар,*
*үлгәндә дә миннән сорап тормаслар,*
*ә яшәү өчен мин җаваплы.*

***Туфан Миңнуллин***

Сорамыйлар, туган, сорамыйлар,
Тууны да, соңрак үлемне.
Сорасалар, тумас идең, бәлкем,
Белсәң алда килер үлемне.

Ә бер тугач инде, нишлисең соң,
Туры килә җирдә яшәргә.
Вакыт җиткәч, «утны сүндерәләр»,
Синең урын кала яшьләргә.

Әлбәттә, бу гаделлек тә түгел,
Игелек тә түгел, уйласаң.
Ләкин гомер үзе- бер зур байлык,
Яшәп калыйк әле, ичмасам.

## ИКЕ ЙӨЗ ТУКСАН ҖИДЕНЧЕ КӨН

*Заман ахырында ни уйласаң,*
*шул алга килә,ди.*
*Ашау турында уйлап ятам,*
*китереп куючы юк.*
*Яшиселәр бар икән әле.*
***Туфан Миңнуллин***

Ашарга да бирүче юк,
Әле гомер бар икән.
Әгәр соңрак китерсәләр,
Аны кем ашар икән?

Ашый алмам инде бит мин,
Җиткәч заман ахыры.
Ничек ташлап китәрмен соң,
Җалко, шайтан алгыры!

# ИКЕ ЙӨЗ ТУКСАН СИГЕЗЕНЧЕ КӨН

*Кешелекнең әхлакый кануны*
*матди һәм рухи байлыкның үзара*
*тарткалашуыннан гыйбарәттер.*
***Туфан Миңнуллин***

Ике байлык тарткалашса,
Кайсы җиңеп чыгар инде.
Берсе җиңсә, икенчесе
Ничек кенә чыдар инде.

Ике якка тарта торгач,
Нәрсә генә чыдар икән.
Тарткалашып карыйк әле,
Шуннан әхлак чыгар микән?

# ИКЕ ЙӨЗ ТУКСАН ТУГЫЗЫНЧЫ КӨН

*Кемнәр генә кешелек дөньясын*
*бәхетле итәргә алынмады.*
*Барысы да үтереш белән тәмамланды.*
***Туфан Миңнуллин***

Бәхетле булсын дип кешелек,
Күптәннән башланган хәрәкәт.
Әмма тик һичкайчан халыкка
Килмәгән көтелгән бәрәкәт.

Хәрәкәт башлыгы бәхеткә
Иң элек үз-үзен чумдыра.
Бүтәнгә бәхет юк.
Шуны да
Аңламый бу халык, аңгыра.

## ӨЧ ЙӨЗЕНЧЕ КӨН

*Борыныңны сузсаң, койрыгыңны кисәләр.*
***Туфан Миңнуллин***

Ярамаган җиргә
Сузма борыныңны,
Хур итәрләр сине
Кисеп койрыгыңны.

Койрыксыз бик кыен,
Чыгырдан чыгарсың.
Ялагайланганда
Нәрсәңне болгарсың?

# ӨЧ ЙӨЗ БЕРЕНЧЕ КӨН

*Үз гомеремдә мин дә бер ачыш ясадым: машинага утырып йөрү җәяү йөрүгә караганда рәхәтрәк икән.*

***Туфан Миңнуллин***

Ачыш бирәү генә түгел,
Бар бит башкалар да:
Туйганчы бер ашау яхшы,
Нигә капкаларга?

Утыру да яхшырак ул
Гел басып торудан;
Ятып тору җиңелрәк бит
Хәтта утырудан.

Ачыш ясап була икән
Сарыф итсәң көчең.
Тик бирәү дә мактамый шул
Мондый ачыш өчен.

# ӨЧ ЙӨЗ ИКЕНЧЕ КӨН

*Космополитизм дөнья белән үзе генә*
*идарә итәргә җыенучы милләт галимнәре*
*уйлап чыгарган мәкерле термин.*
***Туфан Миңнуллин***

Бик мактала космополитизм,
Кемгәдер бар аның кирәге.
Шушы термин башка милләтне
Юкка чыгаруның терәге.

Космополит мин дип йөрүче -
Милләтенә балта чабучы.
Файдасына бер зур халыкның
Менә шулай чаңнар кагучы.

# ӨЧ ЙӨЗ ӨЧЕНЧЕ КӨН

*Милли чикләнгәнлек дип сөйләнүче*
*татарлар космополитлар койрыгына*
*ябышкан тигәнәкләр ул.*

***Туфан Миңнуллин***

Милли чикләнгәнлек була
Үз халкын да белмәсә,
Читтә ялтыраудан башка
Бернәрсә дә күрмәсә.

Космополит койрыгына
Кайбер татар ябышкан,
Чикләнмим дип.
Тик үсәлми
Артыгын бер карыштан.

Халкын ташлап, керер иде
Чит милләт кочагына.
Кабул итми шул тегесе,
Мактый да коча гына.

## ӨЧ ЙӨЗ ДҮРТЕНЧЕ КӨН

*Халыклар дуслыгы өчен бердәнбер шарт-*
*хокуклар, бурычлар һәм гамәлләр тигезлеге.*
*Калганы сәяси ялган.*

***Туфан Миңнуллин***

Халыкара дуслыкның бар нигезлеге-
Хокук, бурыч һәм гамәлләр тигезлеге.

Нинди дуслык «өлкән агай» өстә булса,
Бар нәрсәне дә үзенчә бүлеп торса.

Бирсә, бирер бурыч, гамәл, хокукларны,
Бирмәсә- юк.
Синдә берәр хокук бармы?

# ӨЧ ЙӨЗ БИШЕНЧЕ КӨН

*Дошманнарыннан саклана-саклана*
*Рәсәй*
*«Татар бугазы»на барып җитте.*

***Туфан Миңнуллин***

Бигрәк авыр бу дәүләткә дөньяда,
Кругом враги,ниләр генә булса да.
Дошман юкмы, үзе китә сугышка,
Мал өстенә мал өстәлә табышка.

«Татар бугазы»на җитте уллары,
Мескен татар бугазында куллары.
Алда ниләр язган икән татарга:
Уянумы, я беткәнче йокларга?

## ӨЧ ЙӨЗ АЛТЫНЧЫ КӨН

*Мескен японнар урыс телен белмичә*
*ничек яшиләр икән?*
***Туфан Миңнуллин***

Урыс телен белмиләрме-
Якты дөнья күрмиләр.
Шуңа кысык күзләре дә,
Бездәй гомер сөрмиләр.

Ярый әле, Ходай безгә
Зур куаныч китергән:
Урыс телен белү дигән
Бәхеткә ирештергән.

Ахмак япон, мескен япон
Саклаган үз дәүләтен.
Безнең хәтле белми, мескен,
Дөньяның галәмәтен.

# ӨЧ ЙӨЗ ҖИДЕНЧЕ КӨН

*«Без Россияне яклап сугышларда кан койдык»,-*
*— дип әйттермәс өчен телебезне кисәләр.*

***Туфан Миңнуллин***

Кан койдык, дип әйтергә ни хакың бар?
Андый сүзгә тик урыслар хаклылар.
Шушы илне алар гына яклаган,
Алар гына каннар коеп саклаган.

Мич өстендә син бит йоклап яткансың,
Йокың туйгач кына монда кайткансың.
Бар батырлык әнә теге халыкта,
Сиңа тимәс, һәлак булып калып та.

Сөйләмәскә синең телең кисәләр...
Көн дә яңа кисүчеләр үсәләр.

# ӨЧ ЙӨЗ СИГЕЗЕНЧЕ КӨН

*Дөньяга бурычыбызны үлем белән түлибез.*
***Туфан Миңнуллин***

Мин бурычлы бу дөньяда торган өчен,
Башкалардай үз оямны корган өчен.

Ничек түлим бурычымны, кемгә түлим?
Белмәгәчтен, нихәл итим,
Ярый, үлим.

Теге дөньяларда хәлләр ничек икән,
Анда тагын бурыч түләттермәс микән?

## ӨЧ ЙӨЗ ТУГЫЗЫНЧЫ КӨН

*Акчаң булмаса да ярый ул-*
*кесәне ямыйсы юк.*
***Туфан Миңнуллин***

Акчаң булмаса, җиңел бу дөньяда,
Тик йөрисең, кесәң тишек булса да.
Акчам юк дип кайгырмыйсың берничек,
Акча куяр урын юк, кесә тишек.

Чуртымамы тишек, ямап тормыйсың,
Акча төшеп калыр дип борчылмыйсың.
Менә кайда бар рәхәте дөньяның,
Ярлы булсаң, яхшы ягы бар аның.

# ӨЧ ЙӨЗ УНЫНЧЫ КӨН

*Татарның күңеле киң: аңа «осел»*
*дип әйтсәләр дә, «асыл» дип ишетә.*
***Туфан Миңнуллин***

Күңел киңлегеннән булмас, димен,
Татар менә болай иткәндер:
Отпор бирәлмәгәч «осел»ларга,
Ишетүдән дә ваз кичкәндер.

Отпор бирсәң, үзең гаеплесең,
«Олы агай» га ник каршы син?
Сиңа кем биргән, ди, андый хокук,
Бөтен кеше түгел, ярты син.

Үз хәрефең белән язалмагач,
Укый алмагач үз телеңдә,
Ничек бөтен кеше буласың, ди,
Шушы хәлдә, шушы көнеңдә?

# ӨЧ ЙӨЗ УНБЕРЕНЧЕ КӨН

*Татар булып картаю әйбәтрәк-*
*татарда «маразм» дигән сүз юк.*
***Туфан Миңнуллин***

Бездә андый сүз булмагач, әйбәт,
Күршедә бар, монда йөрмәсен.
Сүзе таныш хәзер.
Сүзе белән
Шул хәл үзе килеп кермәсен.

Шушы күршедән күп нәрсә алдың:
Аракы да, мат та, явызлык.
Маразмысын алып килеп,
Сиңа
Кидертмәсен тагын авызлык.

# ӨЧ ЙӨЗ УНИКЕНЧЕ КӨН

*Дөньяга кунак булып киләсең,*
*муйнак булып үләсең.*
***Туфан Миңнуллин***

Һәркемгә дә муйнак туры килмәс,
Килешәлмим моңа, бигайбә.
Кайбер кешеләргә туры килер,
Шундыйларга бу сүз бик әйбәт.

Кунак булып килгәч, шундый хәлдә
Бу дөньядан китү -үкенеч.
Якты бер көн генә туры килә,
Бүтәннәре- кара ике кич.

Бик аз биргән, янып яшәү кирәк,
Якты көнең нурга күмдереп.
Кара кичләреңә, төннәреңә
Көннәр кебек якты нур биреп.

# ӨЧ ЙӨЗ УНӨЧЕНЧЕ КӨН

*Үз өеңдә хуҗа булмасаң,*
*кеше өендә кунак була алмыйсың.*
***Туфан Миңнуллин***

Үз өеңдә хуҗа булалдыңмы,
Синме хуҗа, башка берәүме?
Булалмасаң, йөрмә кунакка да,
Хуҗа бирмәс сиңа түр анда да,
Кунак итәр башка берәүне.

Кеше генә түгел, хәтта милләт
Хуҗа булалмаса өендә,
Кунакка да барып торасы юк:
Урыны тик ишек төбендә.

# ӨЧ ЙӨЗ УНДҮРТЕНЧЕ КӨН

*Әфәндем, карта уенында «Дама» уен булса,*
*уен булмаган тузны да баса ала.*

***Туфан Миңнуллин***

Үз юлыңда «дама» очрап калса,
Сак бул, тузны басып китә ул.
Пычагымамыни туз булуың,
Сине күрмичә дә үтә ул.
Ачык авыз булма, синдәйләрнең
Тетмәләрен генә тетә ул.

Йөрәк серләреңне «дама» ачмасын,
Шундый «дама»лардан саклан син!

# ӨЧ ЙӨЗ УНБИШЕНЧЕ КӨН

*Дарыны ут янында тотарга ярамаган кебек,*
*хатын-кызны да акчадан сакларга кирәк.*

***Туфан Миңнуллин***

Бүген хатын-кызны саклауның да
Кирәге юк инде акчадан.
Нәкъ хатын-кыз сине ерак тота
Акча салып куйган калтадан.

Үзе эшли бит ул җиң сызганып,
Үзе тота тапкан акчасын.
Бик көчәйде хатын-кызлар власте,
Ир-ат халкын Ходай сакласын!

# ӨЧ ЙӨЗ УНАЛТЫНЧЫ КӨН

*Дуңгызга башым иеп сәлам*
*бирдем дә, горурлыгыма сокланып,*
*киләчәккә атладым, ха-ха!*
***Туфан Миңнуллин***

Дуңгызга баш игәч, аңлаешлы
Нәрсә диеп горурлану да.
Шуңа бәйле инде киләчәк тә,
Монда тыныч яши алу да.

Дуңгыз юл бирмәсә, үтәлмисең,
Йөрсәң, йөрмәсәң дә зарланып.
Шушы хайван искә төшкән саен
Бер куясың тагын гарьләнеп.

# ӨЧ ЙӨЗ УНҖИДЕНЧЕ КӨН

*Сарык булсаң, бүре табыла ул.*
***Туфан Миңнуллин***

Сарык булып йөрмә җирдә,
Бүреләр дөнья тулган.
Кешене дә, милләтне дә
Ботарлап ташлый торган.

Ачмы бүре, тукмы бүре,
Туймас сарык суюдан.
Һичбер туймас үтерүдән,
Баш тартмас кан коюдан.

Милләт сарык булмасын,
Җирдә озак тормас ул.

## ӨЧ ЙӨЗ УН СИГЕЗЕНЧЕ КӨН

*Ишегалдында сыеры-сарыгы, дуңгызы-кәҗәсе,*
*тавыгы-казы бер-берсен аңлашып көн итәләр.*
*Берсе дә «мин бөек» дип кәпрәйми.*
*Федератив дәүләт өчен менә дигән үрнәк.*

***Туфан Миңнуллин***

Федератив дәүләткә- шул үрнәк,
Тик бу илгә туры килми ул.
Федератив монда исем генә,
Андый юллар белән йөрми ул.

Берсе «олы агай» булмагачтын,
«Агай»ларга нинди файда бар?...
Бер башлык, бер патша, тик бер «агай»,
Мондый хәлләр тагын кайда бар?

# ӨЧ ЙӨЗ УН ТУГЫЗЫНЧЫ КӨН

*Кишер түтәлендә чәчми тишелгән*
*иң матур чәчәк тә чүп үләне.*
***Туфан Миңнуллин***

Сабыеңны кечкенәдән карамасаң,
Аның аңын үстерергә ярамасаң,
Ата-ана булуың да кемгә кирәк?
Андый бала юньле булып үсә сирәк.

Бәлки, матур үсәр, ләкин бар белгәне
Тик ахмаклык.
Кеше түгел, чүп үләне.

## ӨЧ ЙӨЗ ЕГЕРМЕНЧЕ КӨН

*Татарны мыскыл иткәннәр җәзаларын*
*барыбер алалар-кайсын атып үтерәләр,*
*кайсы үзе асылынып үлә.*

***Туфан Миңнуллин***

Кайчан булса да барыбер
Явызлыкка җавап килә.
Явызларга Хак Тәгалә
Үз җәзасын бүлеп бирә.

Кызганычы шунда: никтер
Җәза шактый соңлап килә.
Явызларның кайберсенә
Җәза тими, алдан үлә.

Җавап бирергә явызга,
Бәлкем, бер өйрәнер әле
Татар.
Шунда үзенең дә
Хәлләре көйләнер әле.

## ӨЧ ЙӨЗ ЕГЕРМЕ БЕРЕНЧЕ КӨН

*Бу татар агасын әйтәм әле-татар булмаска*
*шуның хәтле дә тырыша, мескен, хәтта*
*татар кыяфәте биргәне өчен Ходайга үпкәли.*
***Туфан Миңнуллин***

Кыяфәте урыс түгел,
Шуңа рәнҗи Аллаһына.
Һаман өметләнә, мескен,
Татар булып калмасына.

Татар телен белми, ахры,
Белсә дә бит, сөйләшми ул.
Татар җырын тыңламый да,
Ишетсә дә, көйләшми ул.

Шундый имансызлар бүген
Татарча сөйләшү түгел,
Татарлыгын инкяр итә.
Китсен әйдә.
Татар түгел!

# ӨЧ ЙӨЗ ЕГЕРМЕ ИКЕНЧЕ КӨН

*Хатын-кызны Ходай ирләр башын*
*әйләндерер өчен яраткан.*
***Туфан Миңнуллин***

Кемнәр сиңа китап багышламый,
Кем атамый сиңа җырларын,
Сиңа шигырь язмаган ир бармы?...
Мин дә яздым.
Мин дә җырладым.

Башкалардай мин дә гел соклandым
Зифа буйга, нурлы йөзләргә.
Мәхәббәтең белән чорнап алып,
Син исерттең мине хисләргә.

Хатын-кызга табынмас ир-ат юк,
Синнән әйләнә шул башлары.
Ходай сине шуңа яраткандыр,
Тагын баш әйләнә башлады.

# ӨЧ ЙӨЗ ЕГЕРМЕ ӨЧЕНЧЕ КӨН

*Гаилә тормышында математика фәне кануннары бозыла: анда ике икең дүрт тә, бер дә, биш тә була ала.*

***Туфан Миңнуллин***

Математика- ул бөек гыйлем,
Буш баш төшенмәс тә асылын.
Гаиләдә кагыйдәләр бүтән,
Башка гыйлем белән ачылыр.

Ә шулай да гаиләдә яши
Сөелеп тә, сөеп карты, яше.

# ӨЧ ЙӨЗ ЕГЕРМЕ ДҮРТЕНЧЕ КӨН

*Хушлашканда һәрвакыт әйтелмәгән сүзләр кала.*
***Туфан Миңнуллин***

Хушлаштың да киттең, ә мин калдым,
Әйтелмәгән күпме сүзләрем.
Хисләремне телем генә түгел,
Төшендерер иде күзләрем.

Өлгермәдем, киттең. Ә шулай да
Очрашырбыз әле бу айда.
Әйтермен!

# ӨЧ ЙӨЗ ЕГЕРМЕ БИШЕНЧЕ КӨН

*Театр — чынны ялганнан*
*аерырга өйрәтүче фән үзәге.*
***Туфан Миңнуллин***

Театрның була бик яхшысы,
Анда барсаң, исең китмәле.
Күрсәтерләр сиңа чынбарлыкны,
Ә ялганнар монда чит әле.

Шундыйлары да бар театрның,
Монда хөкем сөрә ялганы.
Бүтәннәрен әйтеп торасы юк,
Булыр-булмас кына калганы.

Җирдә театрлар яшәсен,
Яхшы театрлар яшьнәсен!

# ӨЧ ЙӨЗ ЕГЕРМЕ АЛТЫНЧЫ КӨН

*Рәсәйдә аракы эчүчеләр барысы берьюлы*
*кинәт кенә эчүләрен ташласалар,*
*беләсезме ни буласын?*

***Туфан Миңнуллин***

Кызык булыр иде шундый илдә,
Алкашлар юк, йоклап ятмый җирдә.
Эчмәс икән халык бүгеннән, ди,
Аракылар беткән, түгелгән, ди.

Баеган, ди, бөтен халык кинәт,
Аракысыз яшәп була, димәк.
Бәргәләшеп йөрүче юк, диләр,
Исермәгәч, кем сугышсын, юләр...

Белмим, мондый халәт күпме булыр,
Күпме вакыт халык тыныч торыр.
Озак тормас, димен, күпме чыдар,
Урамнарга халык шаулап чыгар,
Самогонын яңабаштан куар.

# ӨЧ ЙӨЗ ЕГЕРМЕ ҖИДЕНЧЕ КӨН

*Урыс зиратына күмәргә дип әйтеп калдырганмыни?*
*Татар түгеллеген үлеме белән дә раслаган алайса.*

***Туфан Миңнуллин***

Үлгәндә дә башка бер милләткә
Кушыласы килсә, бичара,
Гомерендә тик бер якты көн дә
Күрәлмәгән,
Көн дә төн кара.

Яшәве дә булган бер мәгънәсез,
Бер файдасыз сөргән гомерен.
Бар ни дә ул, юк ни бу дөньяда,
Ярый, биргән Ходай үлемен.

Үз халкына да чит булса кешең,
Башкаларга нигә кирәк, дисең.

## ӨЧ ЙӨЗ ЕГЕРМЕ СИГЕЗЕНЧЕ КӨН

*«Мин сине яратам» дигәндә һәрвакыт*
*«Мин бик әйбәт» дигәнне күздә тотабыз.*

***Туфан Миңнуллин***

Дөрес, дөрес!
Менә әйтеп кара
«Мин бик начар» диеп бирәр кызга.
Шундук качар синнән һичбер сүзсез,
Карамас та ахмак син ялгызга.

Әйбәтлегең күренеп торсын,
«Яратам» дип, ярattыр син.

# ӨЧ ЙӨЗ ЕГЕРМЕ ТУГЫЗЫНЧЫ КӨН

*Мәхәббәт шаһитлар булуын өнәми.*
***Туфан Миңнуллин***

Юл расларга шаһит кирәкмени,
Икәвенә уртак юл инде.
Шаһит алдында ни мәхәббәт ул,
Уртак юлда киртә шул инде.

Шаһит барда сөю гөле сула ул,
Сөю түгел,
Ап-алама бер театр була ул.

# ӨЧ ЙӨЗ УТЫЗЫНЧЫ КӨН

*Кешегә «җаныңны алам», «иманыңны алам»,*
*дип яныйлар. Кайсы куркынычрак икән?*

***Туфан Миңнуллин***

Икесе дә куркыныч шул,
Җан да газиз, иман да.
Коткаручы да тапмассың
Бу законсыз заманда.

Җаныңны да иманыңны
Саклый белергә кирәк.
Җансыз, имансыз да бәндә
Дөньяда кемгә кирәк?!

# ӨЧ ЙӨЗ УТЫЗ БЕРЕНЧЕ КӨН

*Нигә, бөкерем чыкты дип, зарланасың?*
*Җир шарын күтәрергә алынмаска иде.*
***Туфан Миңнуллин***

Әгәр чыкса бөкерең,
Зарланма син, зарланма.
Җитеп шушы яшеңә,
Кирәк иде аңларга:
Бел көчеңне, хәлеңне,
Тотма белмәгәнеңне.

Тимә көч җитмәсенә,
Билеңне кузгатырсың.
Бөкереңдә чыгар ул,
Гарип булып ятырсың.
Үз-үзеңне бел башта,
Шуннан соң эшең башла.

# ӨЧ ЙӨЗ УТЫЗ ИКЕНЧЕ КӨН

*Тәмсез телле хатыннар*
*кайнар кочаклы була алмый.*
***Туфан Миңнуллин***

Тәмсез телле хатыннарда
Кайнар кочак булмыйдыр;
Кайнар кебек тоелса да,
Озакка сузылмыйдыр.

Тәмсез телләр тиз сүндерер
Кочакның бар ялкынын,
Шунда үзең дә тоярсың
Зәһәр котып салкынын.

## ӨЧ ЙӨЗ УТЫЗ ӨЧЕНЧЕ КӨН

*Тамыр аста, җимеш өстә.*
*Тамыр җимешсез яши ала, җимеш-юк.*
*Өстәгеләр моны белергә тиештер.*
***Туфан Миңнуллин***

Өстәгеләр моны аңламый да,
Алар башка уйга күнеккән:
Имеш, астагының кирәге юк,
Бөтен җимеш өстә җитешкән.

Бик ачуы чыкса, тамыр- халык
Өстәгене алып ташлый ул.
Шунда гына «җимеш асыллары»
Хакыйкатьне аңлый башлый ул.

# ӨЧ ЙӨЗ УТЫЗ ДҮРТЕНЧЕ КӨН

*Бала сөю рәхәт, шул баланы*
*кеше итүе генә михнәт.*
***Туфан Миңнуллин***

Җиңел түгел бала тәрбияләү,
Яхшы кеше итеп үстерү.
Ул җиде кат түгел, җитмеш кат та,
Миллион кат тирләр түктерү.

Тирләр генә түгел, җаныңны да
Бүлеп бирәсең син балага.
Аңа дисәң, аямыйсың барын,
Тик булмасын иде заяга.

# ӨЧ ЙӨЗ УТЫЗ БИШЕНЧЕ КӨН

*Кешенең гомере «Нәрсә бу?» дип*
*сорау биргән көннән башланадыр.*
***Туфан Миңнуллин***

Гомер башланмаган әле,
Күзләр
Дөнья гүзәллеген күрмичә;
Ниләр булса, бөтенесен танып,
Куллар тотып карап, белмичә.

Гомер башлангач та мәшәкать күп:
Беләсе бар яхшы-яманын,
Газиз ата-ана кадерләрен,
Шатлык, хәсрәт, йөрәк янганын.

Тик өйрәнеп беткәч барысын,
Кайтмас җиргә китеп барасың.

# ӨЧ ЙӨЗ УТЫЗ АЛТЫНЧЫ КӨН

*Юешләнсә әгәр абруең,*
*ник алтыннан булмый каурыең.*
***Туфан Миңнуллин***

Шундыйлар да бар бит:
Каурый гына
Тәэсир итә, диләр,
Абруеңа.

Ләкин бер тап төшсә
Абруеңа,
Агарталмый аны
Каурый гына.

# ӨЧ ЙӨЗ УТЫЗ ҖИДЕНЧЕ КӨН

*Печелгән үгезгә караганда*
*печелгән айгыр кызганычрак.*
***Туфан Миңнуллин***

Миңа бик кызганыч үгезе дә,
Бик кызганыч инде алаша да.
Җитерәлми алар бу дөньяга
Башка бернинди дә бала-чага.

Бала-чагасыз ни кызык җирдә,
Хатын-кызга да, юк иргә.

## ӨЧ ЙӨЗ УТЫЗ СИГЕЗЕНЧЕ КӨН

*Үзең көлгәндә миңа да төрт,*
*мин дә көләрмен.*
***Туфан Миңнуллин***

Икәү бергә көлик әле,
Бергә көлү күңеллерәк.
Ялгыз көлеп утыруың
Менә монда кемгә кирәк?

Көнләшсеннәр бар дошманнар,
Көлик әле, кызык булсын.
Ә аларга көлү үзе
Савап түгел, язык булсын.

## ӨЧ ЙӨЗ УТЫЗ ТУГЫЗЫНЧЫ КӨН

*Балыктан халык ясап булмый,*
*халыктан балык ясап була.*
***Туфан Миңнуллин***

Ясыйлар кешедән балык та,
Ясыйлар эт, дуңгыз, сарык та.
Автомат та була кешеләр,
Машина һәм шуның ишеләр.

Ә балык кешегә әйләнми,
Шул авыр тормышка бәйләнми.
Ул азат, йөзәдер диңгездә
Теләсә төнен дә, көндез дә.

Диңгез- тик бер хыял эшчегә,
Крестьян һәм башка кешегә.
Шуңадыр бик риза күп халык
Сарыкмы булырга, я балык.

# ӨЧ ЙӨЗ ҖЫРЫГЫНЧЫ КӨН

*Агачның тамыры өчен дә,*
*кәүсәсе өчен дә яфраклары шаулый.*
***Туфан Миңнуллин***

Агач яфраклары тамыр өчен,
Кәүсә өчен дә бер шаулыйдыр.
Яфрак шаулап кына алсын,
Кәүсә
Өстәмә зур хокук даулыйдыр.

Өске катлам мин, ди, минем өчен
Тигез хокук кына җитми, ди.
Күбрәк, зуррак кирәк;
Мин үземне
Тамырларга бертиң итмим, ди.

Хокукларын тартып алам, ди ул,
Тамырларда хокук калмасын...
Белми ахмак кәүсә бер тамырсыз
Җирдә хәтта яши алмасын.

# ӨЧ ЙӨЗ КЫРЫК БЕРЕНЧЕ КӨН

*Тамырларда кан уйный икән,*
*димәк, аның коеласы килә.*
***Туфан Миңнуллин***

Тамырларда кан уйнаса,
Бик сак булырга лазем:
Кан коелыргадыр инде,
Менә валлаһел газим.

Уйнаса,
Элек үзеңнең
Каныңны коеп кара.
Бүтәннең канын коймаска
Менә шул яхшы чара.

## ӨЧ ЙӨЗ КЫРЫК ИКЕНЧЕ КӨН

*Башның уен тел әйтә.*
***Туфан Миңнуллин***

Баш белән тел бердәм
Хезмәт итә.
Баш уйлаган уйны
Теле әйтә.

Ахмак булса башың,
Тел дә ахмак.
Гаепләмә телне,
Сукмә кат-кат.

## ӨЧ ЙӨЗ КЫРЫК ӨЧЕНЧЕ КӨН

*Кеше үлгәч, нигә үксергә,*
*исән чагында җыларга иде.*
***Туфан Миңнуллин***

Шул кешене исән чагында син,
Кызгансаң бер, аяп җыласаң,
Күңелендә үпкә калмас иде,
Тыныч китәр иде, ичмасам.

Хәзер аны жәлләп үксенү дә,
Кирәк түгел,
Аңа барыбер.
Үпкәләп тик бер үзеңә бүген
Үксеп җыларга да ярыйдыр.

# ӨЧ ЙӨЗ КЫРЫК ДҮРТЕНЧЕ КӨН

*Минем дошманнарым юк.*
*Ләкин күңел сурыкмасын өчен*
*аларны эзләп табам.*
***Туфан Миңнуллин***

Җирдә дошманың да булмаса,
Бик күңелсез икән ләбаса.
Тизрәк берәр дошман эзләп тап,
Гаугалашып, күңел ачып кайт.

Мондый гадәт дөнья тулы шул,
Кайбер илнең яшәү юлы шул.

## ӨЧ ЙӨЗ КЫРЫК БИШЕНЧЕ КӨН

*Без бүтәннәр ошатканны гына яратабыз.*
***Туфан Миңнуллин***

Башкаларга ошаган кыз булса,
Минем дә күз төшә шундыйга.
Тик үземә генә ошаганын
Никтер чынлап сөеп булмый да.

Монда нинди серләр бар икән,
Әллә минем күңел тар микән?
Юктыр, тар түгелдер шул чаклы,
Анда кызлар сыя ничаклы!

# ӨЧ ЙӨЗ КЫРЫК АЛТЫНЧЫ КӨН

*Учакны җилдән качып кабызалар,*
*җилләтеп дөрләтәләр.*
***Туфан Миңнуллин***

Җирдә һәр нәрсәнең үз җае бар,
Үз җае бар учак ягуның да.
Кыңгырау да шалтырамас җайсыз,
Үз җае бар чаңнар кагуның да.

Татар булуның да үз җае бар,
Татар бул син һәрчак, һәрбер эштә.
Сукыр бер тиен шул татарлыгың,
Булса тик син кигән кәләпүштә.

## ӨЧ ЙӨЗ КЫРЫК ҖИДЕНЧЕ КӨН

*Җавап бирүгә караганда*
*сорау бирү җаваплырак.*
***Туфан Миңнуллин***

Соравыңа карап җавап биреләдер,
Сорауларың булсын төплерәк.
Юк-бар сорау белән ватма башларыңны,
Андый чүп-чар кемгә, ник кирәк?

Соравыңа карап бәя биреләдер
Синең акылыңа, үзеңә.
Акылыңның тирән, яки бик сайлыгы
Биргән соравыңнан сизелә.

# ӨЧ ЙӨЗ КЫРЫК СИГЕЗЕНЧЕ КӨН

*Һәр сүземне җөпләгән дус миңа кирәкми.*
***Туфан Миңнуллин***

Үз башына хуҗа була торган
Кеше кирәк сиңа дус булып.
Аның белән сөйләшерлек булсын,
Бәхәсләшерлек тә кычкырып.

Бәхәсләшеп булсын үпкәләшсез,
Ике якның булсын үз башы;
Ихлас ихтирамлы бер-берсенә,
Ачык ике як күз карашы.

Бар кеше дә Туфанга тиң түгел,
Бүтәннәргә кирәк башкалар.
Ялагайлар: «Әйе, Сез бөек!»- дип,
Ахмак түрә йөген тарталар.

# ӨЧ ЙӨЗ КЫРЫК ТУГЫЗЫНЧЫ КӨН

*Җилфердәмә әле каршымда.*
***Туфан Миңнуллин***

Каршымда син җилфердәмә әле,
Җилфердәтердәй ни җирең бар.
Буйдак булсам, бәлки, карар идем,
Минем-хатын, синең ирең бар.

Синең -җилфердек, мин карар чаклар
Әллә кайчан үтеп киткәннәр.
Башка заман хәзер.
Җилфердәрләр
Һәм карарлар инде бүтәннәр.

# ӨЧ ЙӨЗ ИЛЛЕНЧЕ КӨН

*Мәхәббәттә кеше сүзе артык,*
*чөнки аның колагы чукрак, күзе сукыр.*
***Туфан Миңнуллин***

Колак чукрак, күзе сукыр,
Нинди бахыр гарип икән?
Шуңа ярдәм итәр өчен
Жыелышып барыйк микән?

Барганның да мәгънәсе юк:
Чукрак булгач, ишетмәс тә;
Ике күзе сукыр икән,
Килгәнебезне белмәс тә.

Дөрестер шул,
Артык монда
Бүтән кеше сүзләре дә.
Ачылыр әле бераздан
Колаклары, күзләре дә.

# ӨЧ ЙӨЗ ИЛЛЕ БЕРЕНЧЕ КӨН

*Мәхәббәт бары тик икәү булганда гына*
*бөреләнеп чәчәк ата.*

***Туфан Миңнуллин***

Яшьлек хисе белән мәхәббәтнең
Дөрләп кызып яна утлары,
Саф мәхәббәт билгеләре булып
Ачыладыр чәчкә чуклары.

Кызганыч шул, соңрак ут сүрелә,
Чәчкәсе дә җиргә коела.
Күпләр сизми шушы үзгәрүне,
Сөю элеккедәй тоела.

Чәчкәләре коелмасын, дисәң,
Башкаларны кушма арага.
Үзеңне дә, сөйгән ярыңны да
Ятлар сүзләреннән арала.

## ӨЧ ЙӨЗ ИЛЛЕ ИКЕНЧЕ КӨН

*Кия белмәсәң, купшы күлмәгең дә күрексез күренер.*

***Туфан Миңнуллин***

Кия белсәң генә
Кием була кием.
Һәрбер киемнең дә
Рәтен белеп киен.

Рәтен белмисеңме-
Әйдә, йөре шәрә.
Башка киңәшем юк
Сиңа,
И бичара.

# ӨЧ ЙӨЗ ИЛЛЕ ӨЧЕНЧЕ КӨН

*Яраттырасың килсә, үзең дә ярат.*
*Ярата алмасаң- хөрмәт ит.*
*Шул чакта үзең дә сөйкемле күренерсең.*
***Туфан Миңнуллин***

Яраттырасың киләме?
Әлбәттә, киләдер шул.
Шушы киңәшләрне тотсаң,
Сөйгәнең көйләнер ул.

Киңәшләрнең иң яхшысы-
Син башта үзең ярат.
Җәлләмә ихтирамыңны,
Шулай үзеңә карат.

Ярату да, ихтирам да-
Булса һәрчак коралың,
Сөйкемле булырсың аңа,
Тере җаны бар аның.

# ӨЧ ЙӨЗ ИЛЛЕ ДҮРТЕНЧЕ КӨН

*Татар булып туганыңа үкенәсеңме?*
*Мин дә синең милләттәшең булуыма оялам.*
***Туфан Миңнуллин***

Мин гарьләнәм шундый татар өчен-
Яманатын сатса татарның.
Үзем горурланам халкым өчен,
Татар булып тудым, татармын!

Үз милләтеннән ваз кичсә бәндә,
Китсен, монда нинди мәсьәлә?
Татар булганына үкендисә,
Аңа да һәм безгә мәсхәрә.

## ӨЧ ЙӨЗ ИЛЛЕ БИШЕНЧЕ КӨН

*Әдәбиятның иң беренче таләбе:*
*шигырь ятланырга, проза укылырга,*
*драматургия әсәре каралырга тиеш.*
***Туфан Миңнуллин***

Шагыйрь булмасам да, шигырь язу
Туры килде монда миңа да.
Ятланмаса, хет укылсын иде,
Риза булыр идем шуңа да.

Укымаслар, диеп куркам,
Проза
Язармынмы, юкмы, кем белсен.
Башкасын да пока язмыйм әле,
Драматургия дә ял итсен.

# ӨЧ ЙӨЗ ИЛЛЕ АЛТЫНЧЫ КӨН

*Дәртең сүнгәч-ясин чыгарга мулла чакырт.*
***Туфан Миңнуллин***

Дәрт сүнсә дә, ясин көтмим әле,
Ашыкмыйм да моннан китәргә.
Әмма дәртсез яшәп булыр микән,
Яшәп булмаса соң, нишләргә?

Әллә шундук мулла чакыртыйммы,
Миңа диеп ясин чыксынмы?
Китәсем дә килми бит әле,
Өметләрем сүнми бит әле.

## ӨЧ ЙӨЗ ИЛЛЕ ҖИДЕНЧЕ КӨН

*Чын цивилизация хатын-кызның*
*киндерәне бикини итеп киюеннән башланды.*

***Туфан Миңнуллин***

Цивилизация башларында
Хатын-кыз торганы билгеле.
Киндер бикинигә бәйлеме ул,
Юкмы, аңа җавап икеле.

Дөрес, бар ыруг пыр тузар,
Берәү
Киндер бикиниен кигәч тә,
Икенче бер хатын-кызы күреп,
«Абау, бигрәк модно!» дигәч тә.

Мөмкин, шуннан цивилизация,
Шуннан кергән төрле модалар.
Хатын-кызлар менә бүген дә бит
Мода диеп утта яналар.

# ӨЧ ЙӨЗ ИЛЛЕ СИГЕЗЕНЧЕ КӨН

*Кабаланма, сиңа насыйбы сиңа булыр.*
***Туфан Миңнуллин***

Кабаланма, чапма ава-түнә,
Сиңа язган булыр үзеңә.
Ашыга, дип Ходай шундук бирмәс,
Вакыт җиткәч бирер, түз генә.

Ашыкканннар утка пешкән, диләр,
Бик ашыгып утка пешмә син.
Бәлки үкенерсең.
Чыдамавың,
Ашыкканың искә төшмәсен.

# ӨЧ ЙӨЗ ИЛЛЕ ТУГЫЗЫНЧЫ КӨН

*Мәхәббәт колы булуның ояты юк,*
*чөнки мәхәббәт –*
*Алла биргән илаһи зынҗыр.*
***Туфан Миңнуллин***

Бәхетлеләр исәбенә керсәң,
Син дә бер мәхәббәт колысың.
Иң бәхетлеләргә кушылырсың,
Тапсаң мәхәббәтнең олысын.

Мәхәббәтнең тәмен татыганның
Дөньясы да гүзәл бер көй-җыр.
Мәхәббәт илаһи көчкә ия,
Тик барыбер ул да бер зынҗыр.

# ӨЧ ЙӨЗ АЛТМЫШЫНЧЫ КӨН

*Хатынның акыллысы, сөяркәнең*
*җилбәзәге яхшы. Яки киресенчә.*
***Туфан Миңнуллин***

Юкка алып бирдем бугай
Икесенә пар йөзек.
Хатыным да сөяркәдәй,
Сөяркәм хатын кебек.

Белмим кайсы акыллыдыр,
Кайсы бигрәк җилбәзәк.
Нишләргә соң, аптыраш бит,
Менә сиңа бер мәзәк!

# ӨЧ ЙӨЗ АЛТМЫШ БЕРЕНЧЕ КӨН

*Кеше олы хәсрәткә дә,*
*олы шатлыкка да*
*әзер булырга тиеш.*
***Туфан Миңнуллин***

Көтеп-көтеп көтек булдым инде,
Икәве дә бергә килмәде.
Олы хәсрәт сыманнары байтак,
Олы шатлык күпләп тимәде.

Әллә бизмәннәрем дөрес түгел,
Әллә юньләп үлчи белмәдем.
Барысына әзер торган идем,
Хәсрәтеннән файда күрмәдем.

Берсе килмәде, дип жалу язсам,
Яңа гомер бирмәс микән ул?
Хәсрәтләре бер дә кирәк түгел,
Олы шатлык тимәс микән ул?

## ӨЧ ЙӨЗ АЛТМЫШ ИКЕНЧЕ КӨН

*Бөтен бәла шунда: хәзерге заман*
*машиналарының тизлеге елдан-ел арта,*
*ә аларны йөртүчеләрнең тормозы тотмый.*

***Туфан Миңнуллин***

Машиналар җитез хәзер,
Кирәк бүтән тормозлар.
Йөртүчедә иске тормоз,
Кемдә яңа тормоз бар?

Яңа тормозлысы юк шул,
Йөртүчене үзгәртик.
Әгәр үзгәрә белмәсә,
Үзгәрергә өйрәтик.
Үзгәрер ул, гел тукысаң:
Үзгәр тизрәк, үзгәр!-дип.

## ӨЧ ЙӨЗ АЛТМЫШ ӨЧЕНЧЕ КӨН

*Ашатып-эчертсәләр, киендереп,*
*адәм рәтле фатирда яшәтсәләр,*
*акчаның бер тиенгә дә кирәге юк.*
***Туфан Миңнуллин***

Акча пычагыма кирәкмени,
Ашау-эчү, кием-мазар әзер торса;
Фатир бушка, менә дигән булса.
Атып кына бәрәм мин акчаны,
Ялгыш күз алдыма килеп чыкса.

Шулдыр коммунизм дигәннәре,
Тимәде бит шунда яшәүләре.

## ӨЧ ЙӨЗ АЛТМЫШ ДҮРТЕНЧЕ КӨН

*Кочаклап йоклатткансың икән,*
*үбеп уятырга да онытма.*
***Туфан Миңнуллин***

Йоклаттың син мине кочаклап,
Уяткач, оныттың үбәргә.
Көн буе кайгырып йөрим бит,
Нишләргә соң инде, нишләргә?

Ятыйм да йоклыймчы хәзер үк,
Уяткан чагыңда үбәрсең.
Ашыкма, йокымны бүлмәле,
Туйганчы йоклыймчы, түзәрсең.

# ӨЧ ЙӨЗ АЛТМЫШ БИШЕНЧЕ КӨН

*Өйрәтмә, Туфан, сиңа хәтлеләр*
*әйткәннәр инде.*
***Туфан Миңнуллин***

Әйткәннәр ул сиңа хәтлеләр дә,
Синнән соң да килеп әйтерләр.
Сүзләреңә бәя бүген түгел,
Айлар, еллар үткәч бирерләр.

Ә мин менә бүген әйтер идем:
Кирәк хәтта шундый көрешү,
Капма-каршы бергә утыргандай,
Серле уйларыңны белешү.

Рәхәт булды шушы китап аша
Бергә сүз алышкан чагымда...
Синең сүзләр кирәк татарларга,
Өйрәт әле тагын, тагын да!

# ЙОМГАКЛАУ СҮЗЕ!

*Кадерле укучым! Китапны зур түземлек белән укып чыгуыңа рәхмәт. Миңа да рәхмәт әйтергә онытма- мин бит сине озын һәм эчпошыргыч итеп язылган романымны укытып йөдәтмәдем. Әгәр дә язганнарымнан канәгать калмасаң, китаптагы буш битләргә минем өчен үзең яз. Гомер ул- еллар, айлар һәм көннәр тезмәсе. Бер елның көннәре ошбу китапка берәмтекләп тезелгән. Аларга ничек һәм ни язу синең иркеңдә. Минем турыда-мин язарга теләгәнне яза аласың, үз тормышың турында да уйларыңны теркәп куя аласың. Бәлки, синең тормышың минекенә караганда кызыклырак һәм мәгънәлерәктер. Уңышлар телим!*

***Туфан Миңнуллин***

Менә китабың да бетте, Туфан,
Сиңа рәхмәт әйттем укый-укый.
Синең фикер миңа хуш килгәндә
Кабат-кабат укыйм, туктый-туктый.

Кайберләре белән килешмәдем,
Никтер күп булмады алары.
Ике якны бергә куштым да мин,
Шигырь итеп яздым аннары.

Менә шул китапны укучыга
Килә хәзер тәкъдим итәсем.
Син язганны укыр,
Минекен дә
Бәлкем укыр, күрсә, нишләсен.

Сүзем йомгаклыймын рәхмәт диеп,
Шушы китап өчен, монда да.
Иман тулы җаның тыныч булсын
Җәннәтләрдә теге дөньяда.

# ЭЧТӘЛЕК


Миңнуллина-Юнысова Әлфия. Могҗиза ....................3
Кереш сүз ....................4
Унынчы көн....................14
Егерменче көн....................24
Утызынчы көн....................34
Кырыгынчы көн ....................44
Илленче көн....................54
Алтмышынчы көн ....................64
Җитмешенче көн ....................74
Сиксәненче көн....................84
Туксанынчы көн ....................94
Йөзенче көн ....................104
Йөз унынчы көн ....................114
Йөз егерменче көн ....................124
Йөз утызынчы көн ....................134
Йөз кырыгынчы көн....................144
Йөз илленче көн ....................154
Йөз алтмышынчы көн....................164
Йөз җитмешенче көн....................174
Йөз сиксәненче көн ....................184
Йөз туксанынчы көн ....................194
Ике йөзенче көн....................204
Ике йөз унынчы көн....................214
Ике йөз егерменче көн....................224
Ике йөз утызынчы көн ....................234
Ике йөз кырыгынчы көн ....................244
Ике йөз илленче көн ....................254
Ике йөз алтмышынчы көн....................264
Ике йөз җитмешенче көн....................274
Ике йөз сиксәненче көн ....................284
Ике йөз туксанынчы көн ....................294
Өч йөзенче көн....................304

Өч йөз унынчы көн........................................................314
Өч йөз егерменче көн....................................................324
Өч йөз утызынчы көн ....................................................334
Өч йөз кырыгынчы көн ..................................................344
Өч йөз илленче көн .......................................................354
Өч йөз алтмышынчы көн ...............................................364
Йомгаклау сүзе ..............................................................370

Тимер Заһит
(Гриф Тимерзаһит улы Хайруллин).
*(на татарском языке)*

# ТУФАНИАДА

Компьютерде беттеген
және мұқабасын безендірген *Ұ. Молдашева*

**ИБ №12840**
Басуға 30.05.2019 жылы қол қойылды. Пішімі 60x84 1/16.
Көлемі 23,17 б.т. Офсетті қағаз. Сандық басылыс. Тапсырыс №3766.
Таралымы 100 дана. Бағасы келісімді.
Әл-Фараби атындағы Қазақ ұлттық университетінің
«Қазақ университеті» баспа үйі. 050040,
Алматы қаласы, әл-Фараби даңғылы, 71.

«Қазақ университеті» баспа үйі баспаханасында басылды.

9 786010 657410